МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГАПОУ “МЕНЗЕЛИНСКИЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ”
РЕСУРСНЫЙ ЦЕНТР ПО ПОДГОТОВКЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КАДРОВ

80 ПОБЕДА!



# СБОРНИК МАТЕРИАЛОВ

## XIII РЕСПУБЛИКАНСКОЙ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОЙ КОНФЕРЕНЦИИ ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ

**Тема Конференции:**
**“Герои негромких профессий. Учитель”**

**Тематические направления:**

- **Учителя – ветераны Великой Отечественной войны**
- **Учителя в годы Великой Отечественной войны: фронт и тыл**
- **Учительский труд в годы войны**
- **Учителя – Герои сегодняшнего дня**
- **Учителя-фронтовики Мензелинского педагогического колледжа имени Мусы Джалиля.**

**г. Мензелинск, 2025**

г. Мензелинск

## УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ


БАБАБЫЗ - БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ *Шаяхметов Р.Р. (җитәкчесе:Миниханова Ә.Ә.)* ........ 10

БАТЫРЛЫК УЛ – МӘҢГЕЛЕК *Чернова Т.В. (фәнни җитәкче: Чернова И.Г.)* 13

БЕЗНЕҢ МӘКТӘП УКЫТУЧЫЛАРЫ-БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЧЫЛАР *Игдисанова Э.Р..* ........ 18

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ВЕТЕРАН УКЫТУЧЫЛАР *Галиева Р.М.* ........ 21

БӨЕК ҖИҢҮ ПАРАДЫНДА КАТНАШКАН УКЫТУЧЫ ГЫЙМАДИЕВ ВӘГЫЙЗ ЗАҺРЕТДИН УЛЫ – БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК! *Шәфигуллина Г.Р.* ........ 24

В БОРЬБЕ ЗА ЖИЗНЬ *Шамсутдинов Ф. (научный руководитель: Шамсутдинова Г.Г.)* ........ 28

ВЕТЕРАН ПЕДАГОГ МЕНЗЕЛИНСКОГО РАЙОНА - ГАТАУЛЛИН ХАСАН НАСРЕТДИНОВИЧ *Газизова З.Ф. (научные руководители: Каримова А.У., Якубова М.С.)* ........ 33

ГЕРОЙ НАШИХ ДНЕЙ И БЫЛЫХ ВРЕМЕН *Овчинникова В.А. (научный руководитель: Галиева Н.Н.)* ........ 35

ГЕРОЯМИ НЕ РОЖДАЮТСЯ… ИСТОРИЯ ОДНОЙ СУДЬБЫ *Стахеева Д. (научный руководитель Гимазетдинова И.Н.) …* ........ 40

ГЫЙЛЬМУЛЛА БАБАЙ ТҮБӘТӘЕ *Насыбуллин Ә.И. (фәнни җитәкче: Мөхәмәдиева Р.Р.)*........42

ГЫЙНИЯТОВ КӘРИМ ГЫЙНИЯТОВИЧ – УКЫТУЧЫ ПРОФЕССИЯСЕНӘ ИЗГЕ ЮЛ САЛУЧЫ *Хэбибуллин Л.(научный руководитель: Хэбибуллин А.Х.)* 44

ДОРОГА ДЛИНОЮ В ЖИЗНЬ *Хабибуллина Р.З..* ........ 47

ЕЛАМЫЙ ТОРГАН СӘЙДӘ (ФРОНТОВИК УКЫТУЧЫ МӨХӘММӘТШИНА СӘЙДӘ АПАНЫҢ СУГЫШЧАН ҺӘМ ТОРМЫШ ЮЛЫ) *Габдрахманова И.Б.* ........ 52

ЖИЗНЬ ДЛИНОЮ В ВЕК *Шарипова Ф.Ф. (научный руководитель: Шарипова Э.И.)*........58

ҖИҢҮ ЯУЛАП КАЙТКАН ВЕТЕРАН МӨГАЛЛИМНӘРЕБЕЗ
*Гардисламова С.Р.* ........................................ 60

ИСТОРИЯ ВОЙНЫ - ИСТОРИЯ МОЕЙ СЕМЬИ *Галиева Н.Н.* ........................ 63

ЛОБАНОВ СЕМЁН ИВАНОВИЧ, УЧИТЕЛЬ – ВЕТЕРАН ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Спиридонова Н.А.* ........................ 66

МӘҢГЕЛЕК УТ КЕБЕК ЙӨРӘКЛӘРДӘ ХӘТЕР УТЫ ЯНАР МӘҢГЕГӘ! (СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ, ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫБЫЗ ХӘЛИМОВ КОТДУС АБЫЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК) *Хамаева Г.Ә.* ........................ 69

МИНЕМ ГАИЛӘ ТАРИХЫНДА БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ *Чернова И.Г.* ....... 73

МОЙ ГЕРОЙ – УЧИТЕЛЬ *Баранова Ф.К.* ........................ 77

МӨХТӘРӘМ ШӘХЕС - УКЫТУЧЫ АБЫЙ *Садыкова Г.К., Әхмәтҗанова Г.Р.* ........................ 81

ПАМЯТЬ ОБ УЧИТЕЛЯХ-ВЕТЕРАНАХ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ (1941-1945 ГГ.) *Вафина Р.И.* ........................ 84

ПЕДАГОГИ - ВЕТЕРАНЫ ГАПОУ «МЕНЗЕЛИНСКИЙ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННЫЙ ТЕХНИКУМ» *Андреева З.Р., Тумакаева В.П.* 86

ПОДВИГИ МОИХ ДЕДОВ, КОТОРЫЕ ЖИВУТ В ПАМЯТИ ПОКОЛЕНИЙ МОЕЙ СЕМЬИ *Ахмеева А.В.* ........................ 91

ПОМНИМ, ГОРДИМСЯ, ЧТИМ! *Кашапова Г.Х.* ........................ 95

РӘШИТ МОСТАФИН БАТЫРЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК ҮРНӘГЕ
*Закирова А.А.(научный руководитель: Закирова Р.Р.)* ........................ 100

ТОРМЫШНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕП ЯШӘР ИДЕК *Комиссарова Ф.Г., Данилова З.С.* ........................ 103

У ВОЙНЫ НЕ ЖЕНСКОЕ ЛИЦО… *Мифтахова З.Ф., Салимова Г.И*……… ..107

У ВОЙНЫ НЕ ЖЕНСКОЕ ЛИЦО… *Мубаракова Р.Р.* ........................ 109

УКЫТУЧЫ- БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ *Закиров Н.Р. (җитәкче: Галиева Г.Ө.)* ........................ 111

УКЫТУЧЫБЫЗ – СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ! *Борһанова Г.Ш.* ........................ 114

УКЫТУЧЫЛАР ДА ҖИҢҮ ЯУЛАШТЫ *Гарипова Л.Р., Гарипов Р.Ф.* ........... 117

УЧИТЕЛЬ- ФРОНТОВИК АНВАР БУРГАНОВИЧ ИЗ БУИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА *Биктимерова Г.И. (научный руководитель: Уразаева А.М.)* ........ 120

УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Зигангараева Г.А.* ........ 123

УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Исламова Л.Ф., Мусин Р.Р.* ........ 126

УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Козлова С.В.* ........ 129

УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ КУКМОРСКОГО РАЙОНА *Ахметшина М.Г.* ....... 131

УЧИТЕЛЯ-ФРОНТОВИКИ: ПОДВИГ, КОТОРЫЙ ЖИВЁТ В ПАМЯТИ ПОКОЛЕНИЙ *Карабаева С.М., Щербакова С.И.* ........ 135

УЧИТЕЛЯ-ФРОНТОВИКИ: ПОДВИГ, КОТОРЫЙ ЖИВЕТ В ПАМЯТИ ПОКОЛЕНИЙ. УЧИТЕЛЬ-ВЕЛИКОЕ ИМЯ! *Багавиева А.Р.* ........ 140

ФРОНТОВИК УКЫТУЧЫ – МӨНИПОВ ХАҖИП МӨНИП УЛЫ *Зиганшина Л.Н.* ........ 142

ФРОНТОВИК –УКЫТУЧЫ: ӨЧ ОРДЕН КАВАЛЕРЫ МУСА *Гайнетдинова А.Ф., Валиуллина Р.Х.* ........ 145

ФРОНТОВИК, УЧИТЕЛЬ, НАСТАВНИК *Тухфатуллова Р.И. (научный руководитель: Каримова А.Ф.)* ........ 149

**УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ФРОНТ И ТЫЛ**

АВЫР ЕЛЛАР СЫНДЫРМАГАН СЕЗНЕ *Галимова Д.И., Абдуллина Э.И., Кадирова З.А. (җитәкчеләр: Г.И.Хәйруллина, Р.Р.Шакирҗанова)* .............151

АҢ-БЕЛЕМГӘ ОМТЫЛГАН МӨГАЛЛИМЕБЕЗ *Абдуллина Э.И., Кадирова З.А.* ........155

БУГУЛЬМИНСКИЕ УЧИТЕЛЯ В ТЫЛУ И НА ПЕРЕДОВОЙ *Власов М.О. (научный руководитель: Жакупова М. Г.)* ........158

ГАСЫРЛАРДА КАЛЫР БАТЫРЛЫК *Мөхәмәдеева Р.М., Романова В.Г* .….163

ИВАНОВ ИВАН ЯКОВЛЕВИЧ – КӨЧЛЕ РУХЛЫ ШӘХЕС *Исрафилова А.А., (научный руководитель: Иванова Л.А.)*…………………………………………….166

МӘСКӘҮ КҮГЕН САКЛАУЧЫ *Мавлеева Р.М.* ................................................ 168

МОЙ ПРАДЕД -УЧИТЕЛЬ -ФРОНТОВИК *Гильмутдинов К.И. (научный руководитель Гильмутдинова И.А.)*………………………………………………….171

МУЖЕСТВО И ГЕРОИЗМ УЧИТЕЛЕЙ НА ОККУПИРОВАННОЙ ТЕРРИТОРИИ *Гарифзянов А.З., Шумилова Е.В.* ............................................. 176

СВЕТ ЗНАНИЙ В ТЕМНЫЕ ВРЕМЕНА *Мухутдинова А.Н.* ........................... 180

СИЛЬНЫЙ ДУХОМ СЛАБЫЙ ПОЛ – ЖЕНЩИНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Бубекова И.А., Имамутдинова Р.Г.* .................. 182

УКЫТУЧЫЛАР ДА БӨЕК ҖИҢҮНЕ ЯКЫНАЙТТЫ *Әхмәтҗанова Р.Г.* ..... 187

УЧИТЕЛЬ УЧИТЕЛЕЙ-ХАНИФ ГИЗЕТДИНОВИЧ ХУСАИНОВ *Талипова Л.Ф., Гараева Н.Г.* ………………..……………………..…………192

УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ВКЛАД В ВСЕОБЩУЮ ПОБЕДУ *Руотсалайнен С.Р.* .................................................... 195

УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ФРОНТ И ТЫЛ *Ахметгареев А.Р., Аглямов Т.Ф. (научный руководитель: Камалетдинова И.А.)*.................................................................................197

УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ФРОНТ И ТЫЛ *Музипов Э.И. (научный руководитель: Данилов С. И.)* ………………………...201

УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ФРОНТ И ТЫЛ *Новикова В.В.*......................................................................... 204

УЧИТЕЛЯ И ФИЗИКИ ВО ВРЕМЯ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Ульясов Р.И., Маигов М.С. (научные руководители: Белялова А.Г., Шарипова Л.И.)*……………………………………………………………………207

УЧИТЕЛЯМИ БЫЛИ В ШКОЛЕ. БОЙЦАМИ БЫЛИ НА ВОЙНЕ *Габдрахманов И.Р. (научный руководитель: Хабибуллина Л.Р.)* ……………..…212

УЧИТЕЛЯ-ФРОНТОВИКИ: ПОДВИГ, КОТОРЫЙ ЖИВЕТ В ПАМЯТИ ПОКОЛЕНИЙ *Мергенов Н.И., Абдуллин Т.Р. (научный руководитель: Камалетдинова И.А.)*.....215

ФРОНТОВИК ҺӘМ УКЫТУЧЫ *Ахметзянова Р.Г.* .....219

ЭТОТ ТЕХНИКУМ – ДОМ НАШ РОДНОЙ! *Старостина О.В*………….....222

**УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД В ГОДЫ ВОЙНЫ**

ИГЕЛЕКЛЕ ТОРМЫШ ЮЛЛАРЫ *Кашапова Р.Р.*.....225

ИХ ОРУЖИЕ: ЛЮБОВЬ К ДЕТЯМ *Александрова Л.З., Митюшкина О.Г.* .....229

МОЯ БАБУШКА – УЧИТЕЛЬ! *Уланова М.В., Уланова Д.В. (научный руководитель: Уланова Е.В.)*.....232

СОХРАНЕНИЕ ЗНАНИЙ И НАДЕЖДЫ *Котельникова Д.А.* .....236

СТОЙКИЙ ОЛОВЯННЫЙ СОЛДАТИК *Кокутина Н.Ю.* .....238

СУГЫШ ВАКЫТЫ ЕЛЛАРЫНДА УКЫТУЧЫ ХЕЗМӘТЕ: МОРТ АВЫЛЫ УКЫТУЧЫЛАРЫ *Гайнанова Р.М.*. .....242

СУГЫШ ВАКЫТЫ ЕЛЛАРЫНДА УКЫТУЧЫ ХЕЗМӘТЕ: МОРТ АВЫЛЫНДА ЛЕНИНГРАД БАЛАЛАРЫ *Михайлов Ә.Е. (фәнни җитәкче: Хадиев Ф.В.)* .....245

СУГЫШ ЕЛЛАРЫНДА УКЫТУЧЫ ХЕЗМӘТЕ *Мингалиева В.Р.* .....247

СУГЫШ ЕЛЛАРЫНДА УКЫТУЧЫ ХЕЗМӘТЕ *Шәрифҗанова Л.К.*.....249

ТАЙНЫ КЛАССНОГО ЖУРНАЛА:НЕИЗВЕСТНЫЕ СТРАНИЦЫ ШКОЛЬНОЙ ИСТОРИИ *Чуприкова Э.Т.*.....251

УКЫТУЧЫ ҺӨНӘРЕ – ИҢ МӨҺИМ ҺӨНӘРЛӘРНЕҢ БЕРСЕ! *Һадиева Р.М.* .....255

УЧИТЕЛЬСКАЯ ДИНАСТИЯ ЗИННУРОВЫХ *Мусина А.И. (научные руководители :Мусина А.М, Мингаллева Э.З)* .....258

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД В ГОДЫ ВОЙНЫ *Альмиева Ф.М.*.....261

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД В ГОДЫ ВОЙНЫ *Смирнов М.А. (научный руководитель: Габтунурова Н.Н)* ........................................ 266

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД В ГОДЫ ВОЙНЫ КАК СИМВОЛ СТОЙКОСТИ, ПАТРИОТИЗМА И ПРЕДАННОСТИ СВОЕМУ ДЕЛУ *Широбоков Я.А. (научный руководитель: Пугачева В.А.)* ........................................ 271

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД В ГОДЫ ВОЙНЫ *Муртазина З.К.*. ........................................ 273

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД ВО ВРЕМЯ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ *Хисматуллина Л.Ш., Гимранова Г.А.* ........................................ 275

УЧИТЕЛЬСКИЙ ТРУД ВО ВРЕМЯ ВОЙНЫ 1941-1945Г *Халиуллина Э.Н. (научный руководитель: Дудченко Е.А.)* ........................................ 279

УЧИТЕЛЯ – ОРГАНИЗАТОРЫ МИРНОЙ ЖИЗНИ В ВОЕННЫЕ ГОДЫ *Гимранова Х.И., Насырова В.Л.(научный руководитель: Мубаракшина А.Р.)* 281

ФИДАКАРЬЛӘР *Хасанова Д.Ф. (фәнни җитәкче- Фәхретдинова Г.Ш.)* ....... 284

ХЕЗМӘТЕНӘ ТУГРЫ УКЫТУЧЫ *Губайдуллин И.А. (фәнни җитәкче: Мухаматдинова Г.Г.)* ........................................ 287

ЯШЬНӘП ҮТКӘН ГОМЕР *Мубаракова А.З. (научный руководитель: Мубаракова Р.Р.)*... ........................................ 290

**УЧИТЕЛЯ – ГЕРОИ СЕГОДНЯШНЕГО ДНЯ**

ГЕРОИ НИКОГДА НЕ УМИРАЮТ, БЕССЛЕДНО НЕ УХОДЯТ В НИКУДА *Ахметов Р.А (научный руководитель: Талипова Т.Х.)* ........................................ 291

ГОРУР ЙӨРСЕН, УКЫТУЧЫМ, КИЛӘЧӘКТӘ СИНЕҢ ИСЕМ! *Гайнуллина Л.Г.* ........................................ 296

ИКЕ ТУГАН - ИКЕ МӨГӘЛЛИМӘ *Маликова Ә.А. (фәнни җитәкче: Хамматова Г.Г).* ........................................ 298

МАРИЯ ПЕТРОВНА — МОЙ РОДСТВЕННИК И ПРИМЕР ДЛЯ ПОДРАЖАНИЯ *Исаева Н.Ю.* ........................................ 301

МОЙ ГЕРОЙ – ЭТО МОЯ МАМА *Файзылхакова Г.М.* ........................................ 304

ҺӨНӘРНЕҢ КАБАТЛАНУЫ *Габидуллина Я. (фәнни җитәкчеләр: Кәрамова А.Җ., Дәүләтшина Г.Б.)* ........................................ 308

РОДИТЕЛИ - ГЛАВНЫЕ УЧИТЕЛЯ В ЖИЗНИ РЕБЕНКА *Халиуллина Г.И. (научные руководители: Бубекова И.А., Имамутдинова Р.Г).* ......................... 313

ТОТ УЧИТЕЛЬ ХОРОШ, ЧЬИ СЛОВА НЕ РАСХОДЯТСЯ С ДЕЛОМ *Кашапова А.О. (научный руководитель: Камалетдинова И.А.)* ...................... 318

УКЫТУЧЫ БУЛУ – МӘРТӘБӘ! *Мөхәммәтрәхимов Р.Р. (фәнни җитәкче:Мөхәммәтрәхимова Р.Н.)* ............................................................ 326

УКЫТУЧЫЛАР-БҮГЕНГЕ КӨН ГЕРОЙЛАРЫ *Җәләева Г.Г.* ........................ 329

УЧЁНЫЙ, ОТКРЫТЫЙ В БИБЛИОТЕКЕ *Гущина А.А. (научный руководитель: Гущина А.Н.)* ............................................................................................ 332

УЧИТЕЛЬ – МАСТЕР, НАСТАВНИК, ВЕРНЫЙ ДРУГ *Николаева С.А.* ........ 334

УЧИТЕЛЬ, СПАСИБО ЗА ТРУД.УЧИТЕЛЯМ НАЧАЛЬНЫХ КЛАССОВ ПОСВЯЩАЕТСЯ *Дадыкина И.Н.* ............................................................ 336

УЧИТЕЛЯ - ГЕРОИ СЕГОДНЯШНЕГО ДНЯ *Хайдарзянова З.И. (научный руководитель: Гильмутдинова Л.Н.)* ................................................... 341

УЧИТЕЛЯ – ГЕРОИ СЕГОДНЯШНЕГО ДНЯ *Ганеева З.А. (научный руководитель: Сиченкова Г.И.)*............................................................... 343

УЧИТЕЛЯ – ГЕРОИ СЕГОДНЯШНЕГО ДНЯ *Султанов Э.Р. (научный руководитель: Бубнова С.В.)*................................................................... 346

УЧИТЕЛЯ-ГЕРОИ СЕГОДНЯШНЕГО ДНЯ. ПРОСВЕЩЕНИЕ, ОБУЧЕНИЕ-РОДОСЛОВНАЯ МОЕЙ ДИНАСТИИ *Кавиева Д.М. (научные руководители: Мингазова Р.М., Хусаинова Г.Х.)* ............................................................. 351

ЧЕСТЬ И СЛАВА ТАКОМУ УЧИТЕЛЬСТВУ *Юнусова Ф.Ф.*......................... 354

ЧУТКИЙ ПЕДАГОГ, ПРЕДАННЫЙ СВОЕМУ ДЕЛУ *Хайруллина И.М., Талипова Г.Ф.* ............................................................................................. 357

**УЧИТЕЛЯ-ФРОНТОВИКИ МЕНЗЕЛИНСКОГО ПЕДАГОГИЧЕСКОГО КОЛЛЕДЖА ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ**

ДОСТОЙНЫЙ ПРИМЕР ДЛЯ ПОДРАЖАНИЯ! *Санникова Е.С. (научный руководитель: Красноперова Т.А.)* ................................................... 360

ЕСЛИ ЧЕЛОВЕК ТАЛАНТЛИВ, ТО ОН ТАЛАНТЛИВ ВО ВСЕМ
*Красноперова Т.А.* ........................................................................................ 362

ИНТЕРАКТИВНАЯ ВЫСТАВКА «ВЫПУСКНИКИ МЕНЗЕЛИНСКОГО ПЕДАГОГИЧЕСКОГО КОЛЛЕДЖА ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ – УЧАСТНИКИ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ» *Новикова М.С. (научные руководители: Лаптева М.П., Минегалиева И.Д.)* ............................ 368

КЕШЕ ЯЗМЫШЫ-ИЛ ТАРИХЫ *Галиева И.М.* ................................................ 372

# УЧИТЕЛЯ – ВЕТЕРАНЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ

## БАБАБЫЗ - БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ

*Шаяхметов Рөстәм Рамиль улы*
*(җитәкчесе:Миниханова Әдилә Әмирҗан кызы),*
*“Яр Чаллы политехника көллияте”*
*дәүләт автоном һөнәри белем учреждениесе*

Хәзерге катлаулы заманда ил тарихы югала, кыйммәтләр үзгәрә, әби-бабайларыбыз казанышлары әһәмиятен югалта. Шуңа күрә, без гаилә тарихы, әби-бабаларыбыз турында истәлекләрне саклап калып, илебез тарихын тулыландырырга ярдәм итә алабыз. Шул вакытта, илебез югалмас, көчле һәм хөрмәткә лаек булыр.



Минем бабамның әтисе - укытучы һәм Бөек Ватан сугышы ветераны - Калимуллин Габидин Шәйхетдин улы 1914 нче елда Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылында туа. Ул 1933-1934 нче уку елында Тойгелде җидееллык мәктәбен тәмамлый. 1929 нчы елда пионерга керә, ә 1933 нче елда комсомол сафларына баса. 1936 нчы елда хәрби хезмәткә алына. 1939 нчы елда хәрби хезмәтне тутырып авылга кайта. Шул ук елны авыл мәктәбендә башлангыч классларны укыта башлый. Югары классларда физкультура укытучысы була. Габидин бабай Минзәлә педучилищасын тәмамлый.

Финляндия сугышы башлана, бабай тагын хәрби хезмәткә китә. Сугыш вакытында Мәләкәстә офицерлар әзерли торган Хәрби училищасында укып, кече лейтенант дәрәҗәсен алып чыга. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 нче елның 24 нче июнендә сугышка китә. 1942 нче елның маена кадәр Казанда Хәрби заводны саклый. Шул ук айда икенче Украина фронты составында сугышка керә. Дүрт елга сузылган сугышта бабам кайларда гына булмый. Ул, үз-үзен аямыйча, Туган илне дошманнан саклый. Чехословакияне, Польшаны, Болгарияне, Венгрияне, Румынияне азат итүдә катнаша.

"Укытучылар өчен сугыш кырыс мәктәп булды. Укытучы фронтта да, окопта да үз һөнәренә тугры калырга тиеш. Ничегрәк сугышырга кирәклеге турында үз мисалымда өйрәтергә туры килгән чаклар аз булмады. "Укытучыларга да ышанмасаң, тагын кемгә ышанырга?" – дип әйтергә ярата иде командир" – дип сөйләп калдырган минем бабаем. Җиңү көнен Берлинда каршылый. Сугыш беткәннән соң, 1945 нче елда, авылга кайта. Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен бик күп төрле медальләр белән бүләкләнә. Утлар, сулар кичкән шундый ветераннарның берсе булган минем бабам.

Укытучы - ул һөнәр генә түгел, ул тулы бер язмыш һәм яшәү рәвеше.

Бабаебыз сугыштан соңгы бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә, укытуга багышлый. Тойгелде сигезьеллык мәктәбендә 40 ел укыта. Ул балаларда Туган илне ярату, хезмәт сөю, чын кеше булу сыйфатларын тәрбияли. Тормышны сөяргә, хезмәтне яратырга, кешеләргә игътибарлы булырга, кече күңелле булырга өйрәткән, киләчәк тормыш өчен бик күп файдалы киңәшләр биреп калдырган.

"Укытучының фидакарь хезмәте аның укучыларында күренә. Әгәр уңышка ирешә һәм бу тормышта үз урыннарын тапканнар икән, димәк, тырышлыгым бушка китмәгән. Шул вакытта хезмәтеңнең юкка булмавына, дөрес һөнәр сайлаганыңа тагын бер кат инанасың. Авыл мәктәпләрендә тормыш кайнап торган чор бер дә истән чыкмый. Ул елларны авыл мәктәпләрендә балалар да күп иде. Укучыларга патриотик тәрбия бирү, пионер, комсомол булулары, үзешчән сәнгать смотрлары, спорт ярышлары еш үткәрелде. Һәр чорның истә калырлык күңелле, матур вакыйгалары хәтеремдә"- дип сөйли торган булган бабабыз. Намуслы хезмәт белән матур тормыш юлы үткән, ирешкән уңышларына шатланып яшәгән бабаебыз укытучы һөнәрен сайлавына беркайчан үкенмәгән.

Ул 1986 нчы елның 23 нче февралендә вафат булган. Габидин бабай балалары һәм авыл халкы күңеленә бик "олы" йөрәкле, ачык күңелле, ярдәмчел, мөхтәрәм кеше буларак кереп калган.

Аның кебек бик күпләр Ватаны өчен үзләренең гомерләрен дә кызганмыйча, авыр сугышны җиңеп, дөньяны зур афәттән коткарып, туган илебез бәхетле киләчәге өчен үзләренең көчләрен кызганмадылар. Җиңүгә юл озын һәм авыр булган. Сугышчылар соңгы сулышларына кадәр изге антларына тугры калганнар, намусларына тап төшермичә, азатлыкны буарга ирек бирмәгәннәр һәм халкыбызны коллыктан саклап калганнар. Без алар алдында шушы яхшы, тыныч, тату, бәхетле тормышта яшәвебез өчен бурычлы.

Бабаемның укытучылык эшен әнием дәвам итә. Ул да укытучы һөнәрен сайлап, ничә еллар инде авыл мәктәбендә балаларга белем сәйләннәре өләшә.

Сүземне тәмамлап шуны әйтәсем килә: вакыт уза, яңадан-яңа буыннар җиргә килә тора. Бабаларыбыз турында истәлекләрне кадерләп саклыйк, балаларыбызга һәм туганнарыбызга сөйлик. Буыннарны онытмыйк, буыннар бәйләнешен югалтмыйк, һәрчак истә тотыйк, алар белән горурланыйк!

# БАТЫРЛЫК УЛ – МӘҢГЕЛЕК

*Чернова Татьяна Владимировна*
*(Фәнни җитәкче: Чернова И.Г.),*
*Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы*
*муниципаль бюджет учреждениесенең*
*«Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбе»*

Бөек Ватан сугышының тәмамланганына сиксән ел вакыт үтеп бара. Бу канкойгыч сугыш турында телевизордан кинолар карап, тыл ветераннарыннан, өлкәннәрдән ишетеп кенә беләбез. «Сугыш» сүзен әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, эти-әнисез ятим калган сабый балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт алып килә. Япь-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау, яклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү көнен якынайту өчен бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я этиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Нинди зур югалтулар!

Ләкин халыкның тырышлыгы бушка китми: күптән көтелгән Җиңү көне килә. Бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып кала. Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә.

Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.

Без үзебез дә ел саен 9 нчы Май көнендә авылыбызның иң күренекле урынында урнашкан обелиск янына барабыз, чәчәкләр, веноклар куябыз. Бөек Җиңүгә багышлап шигырьләр, җырлар җырлыйбыз, бәйрәм队 парады уздырабыз. Хәзерге вакытта безнең авылда сугыш ветераннарының берсе дә исән түгел инде. Тик шулай да аларның сугышта күрсәткән батырлыклары, безнең якты тормышыбыз өчен үз-үзләрен аямаулары алдында баш иябез. Алар безнең хәтердә, киләчәк буыннар хәтерендә озак еллар сакланырлар әле. Обелиск янына тыл ветераннарны килә. Аларга да рәхмәтләребезне әйтәбез.

**Александр Иванович Харитонов** 1926 елның 24 октябрендә Татарстан АССР Зәй районы Сарсаз-Баграж авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Алар гаиләдә 5 бала булалар, 4 нче булып Александр туа. Октябрь революциясенә кадәр дә һәм аннан соң да эти-әнисе игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. 1940 елда артельгә керәләр. Әтисе 1961 елда, ә әнисе 1983 елда үлә.

Матур гына яшәгәндә илебезгә афәт килә. 1941 елның 22 июнь иртәсе искиткеч матур, күк йөзе ап-аяз, көннең кызу булачагы күренеп торырлык булып башлана. Ә бу вакытта Ватаныбыз чикләрендә каты сугыш бара иде инде. Канатларына кара билгеләр төшерелгән самолетлар тыныч шәһәрләрне бомбага

тота, танклар һәм пехота чикне бозып керә. Шулай итеп, фашистлар Германиясе, сугыш игълан итмичә, илебез чикләрен үтеп кереп, безнең илгә сугыш башлый.

Күп миллионлы совет халкы белән беррәттән Татарстанның хезмәт ияләре дә Ватан сагына басалар.

Бөтен Совет халкы белән бергә илебезнең иминлеген, бәйсезлеген, фашист илбасарларыннан саклау өчен Баграж авыл Советы территориясеннән барлыгы 548 кеше сугышка алына, шуларның 342сенә кире әйләнеп кайтулар насыйп булмый, сугыш кырында һәлак булалар. Югары Баграждан 238 кеше алына, 156 кеше һәлак була. Сарсаз-Баграждан 194 кеше алына, 113 кеше һәлак була. Урта Баграждан 116 кеше алына, 73 кеше һәлак була. Сугыш кырларыннан бик күбесе кире әйләнеп кайта алмаган. Бары тик авылыбыз уртасында куелган һәйкәлдәге ташка язылган исемнәре генә, әйтерсең «Без сезнең өчен, Ватаныбыз өчен сугыш кырында ятып калдык. Безне онытмагыз», дияләр кебек. Әйе, без аларны һичбер вакытта да онытырга тиеш түгел. Аларның сугыштан исән-сау кайтканнары да, сугышта алган яраларына сызланып, безнең арадан китеп бардылар. Без аларның батырлыкларын онытырга тиеш түгел.

Александр сугышка алынганчы аның ике абыйсы инде сугыш кырында була. Бу вакытка бер абыйсыннан кара мөһерле хат килгән була инде. 1914 нче елда туган Харитонов Василий Иванович 1941 елны ук сугышка алына. Блокаданы өзгәнче Ленинград фронтында була. Кёнигсбергны штурмлауда катнаша. Сугыш тәмамланып 1 ел үткәч кенә, туган якларына исән-сау әйләнеп кайта. Гомерен урманчылык эшенә багышлый. 2003 елда арабыздан китеп барды.

Икенче абыйсы 1918 нче елда туган Харитонов Федор Иванович Югары Баграж җидееллык мәктәбен тәмамлый. Оренбург очучылар училищесын бетереп, сугышны лейтенант дәрәҗәсендә каршылый. Ленинград өлкәсендә һава сугышында һәлак була. 1943 елның 15 мартында Ленинград өлкәсенең Ляхново (Слугино) авылы янында җирләнә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Александр Иванович 1941 елда, сугыш башланган елны Сарсаз-Баграж җидееллык мәктәбен тәмамлый. 15 яшьлек яшүсмер шушы елны ук Петровка спирт заводына эшкә керә. Кызыл Армия сафларына чакырылганчы ул заводта хезмәт куя. 1944 елның гыйнварендә Кызыл Армия сафларына мобилизацияләнә. Бөек Ватан сугышын Молдавия җирләрендә каршылый. Александр Ивановичның Кызылармияче кенәгәсе түбәндәгечә:

- 1944 ел, январь – апрель, 150 нче Запастагы укчы полкы, Могилев-Подольск;

- 1944 ел, апрель – сентябрь, укчы – автоматчы, 1129 нчы укчы полкы, Венгрия;

- 1944 ел, сентябрь – декабрь, яраланып эвакогоспитальдә була, Венгрия;

- 1944 елның декабреннән 1945 елның мартына кадәр 206 нчы дивизиядә укчы, Венгрия;

- 1945 елның март – май айларында 3 Украина фронтында кече лейтенантлар әзерләү курсанты, Румыния;

- 1945 ел, май – август, 460 БАО, 200 запастагы укчы полкы, Текучи – Румыния;

- 1945 елның августыннан 1946 елның январенә кадәр  х/ч 36704 укчы, Текучи – Румыния;

- 1946 елның январеннән 1951 елның маена кадәр х/ч 36704 яшерен хуҗалык эшләрендә җитәкче.

Александр Иванович данлыклы юл үтеп, Бөек Җиңү таңын Румыния-Текучида каршылый.

Шулай итеп, Александр Иванович 17 се тулуга, 1944 елның башында Ватан сугышына китә. Ул Венгриянең Баллотон күле янындагы сугышта каты яралана. Румыния, Венгрия, Австралияне фашистлардан азат итүдә катнаша. Солдат шинеле киеп, туган якларны сагынып яшәү 8 елга сузыла. Ул сугыштан соң тиешле хәрби срогы тулгач кына туган авылына кайта. 1944 нче елның январендә чыгып киткән Александр Харитонов 1951 елның маенда, 8 ел үткәч кенә, туган ягына әйләнеп кайта. Өйдә аны әти-әнисе каршылый, шатлыкларының-сөенечләренең иге-чиге булмый.

Александр Иванович истәлекләреннән:

«Баллотон күле янында Венгриядә булды бу хәл. Ике көн бертуктамый яңгыр яуды. Окопларда су тездән иде. Без, солдатлар, нишаларны казып, шунда кереп яңгырдан азрак ышыклана идек. Чөнки анда әзрәк булса да корырак. Шундый вакытларның берсендә мин каты йокыга киткәнмен. Йокы аралаш аз гына хәтерлим иптәшемнең: «Харитонов, киттек, чигенәбез», - дигән сүзләрен. Башка бер әйбер дә белмим. Аннан соң иптәшемнең: «Син нәрсә, Харитонов, шушында, окопта шул гомер яттыңмы», - дигән тавышына уяндым. Ә чынлыкта безнекеләр запастагы позициягә чигенгәннәр, никтер немецлар безнең окопларны алмаганнар, чигенгәнне белмәгәннәрдер инде. Берникадәр вакыт узгач, безнекеләр үз позицияләренә кире килгәннәр. Менә шулай итеп, мин яңадан тудым, дип әйтергә мөмкин. Әгәр дә немецлар безнең окопларга килсәләр, нәрсәләр булып бетәр иде. Фронтта нәрсә генә булмый... Ләкин немецларның мина кыйпылчыгы барыбер мине тотты. Контратака вакытында мина кыйпылчыгы тиеп яраланып, 3 ай госпитальдә ятарга туры килде».

Хезмәт юлын райкомда инструктор булып башлый. Аннан педучилище, университетның читтән торып уку бүлеге... Аның бөтен гомере диярлек Сарсаз – Баграж мәктәбе белән бәйле. Тарих укытучысы, мәктәп директоры. Шулай 40 елга якын вакыт үткән. Буыннар алышынган. Аның менә шушы буыннар өчен эшләп калдырганы күп кешегә җитәрлек. Авылда сигезьеллык мәктәп була. Укучылар саны күп булса да, күрше Югары Багражга авылына йөреп укыйлар. Көзге пычракларда, кышкы салкыннарда, күз ачкысыз бураннарда укучыларның 5 чакрым җәяү йөрүләренә ачынып, авылда унъеллык мәктәп ачу өчен зур тырышлык куя (1976). Күрше авылдан килеп укучылар өчен интернат ачыла. Еллар үтә, заманалар үзгәрә. Александр Иванович заманча, зур, якты мәктәп ачу максатын үз алдына куя. Шушы максатны үтәү өчен күпме йокысыз, борчулы төннәр үткәрергә, ничә тапкыр Казан, Зәй юлларын, күп җитәкчеләрнең бусагаларын таптарга туры килә. Әмма морадына ирешә. 1984 елда авылда

барлык уңайлыклары булган ике катлы урта мәктәп ачыла. Ул әле тагын бик күп буыннарга хезмәт итәчәк.

Александр Ивановичның авылдашлары алдында тагын бер зур, мөһим хезмәте бар. Ул да булса – мәктәп музее. Анда Сарсаз-Багражның ерак үткәне, мәгълүм шәхесләре мәңгеләштерелгән. Монысы да киләчәк өчен, кеше ата-бабасын белергә тиеш. Шул ук вакытта авыл үз музеена нигез салучы исемен дә онытырга хаклы түгел. Үз илендә пәйгамбәр юк, диләр. Бәлки, дөрестер дә. Хөрмәтнең тиешлесе күрсәтелеп тә бетмәгәндер. Әмма укытучының тынгысыз хезмәте өчен аңа Халык мәгарифе отличнигы исеме бирелә.

Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр кеше үз гаиләсенең, үз туган төбәгенең тарихын белергә тиеш. Туган як тарихын өйрәнүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Алар туган як, туган авыл, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан-буынга тапшыруда ярдәм итә.

Сарсаз-Баграж мәктәбендә туган як тарихын өйрәнү музеен тарих укытучысы Александр Харитонов оештыра. Музейга зур эзләнү-тикшеренү эшләре алып барган, кызыклы экспозицияләр булдырган өчен 1999 елда тиешле статус бирелә. Музейда 300 дән артык экспонат исәпләнә. Хәзерге вакытта музейга Александр Ивановичның улы тарих укытучысы Радий Иванович җитәкчелек итә.

Музейда эшчәнлек күпкырлы юнәлештә алып барыла. Авыллар тарихы, тормыш-көнкүреш әйберләре, танылган шәхесләр, якташларыбыз – Ватан сугышында, пионер һәм комсомол тарихы, халык йолалары һәм бәйрәмнәре кебек бүлекләр эшләп килә. Экспонатлар туплау эше инде күптәннән башланган. Укучылар Александр Харитонов җитәкчелегендә өч авылда йөреп, тарихи материаллар, фоторәсемнәр, экспонатлар туплыйлар. Бу эш әле дә дәвам итә. Музейда сирәк очрый торган экспонатлар да бар. Мәсәлән, үзе телевизор, үзе радиоалгыч, үзе үк тәлинкә уйнату җиһазы. Аны музейга Александр Харитонов тапшырган. Элек бу телевизорны карау өчен аларга бөтен авыл халкы җыела торган булган. Алар үзләре белән утырып карау өчен эскәмия һәм урындыклар күтәреп килгән. Музейда булучыларны бирелдә тупланган эш коралларыннан – кул тегермәне, орчыклар, җилпуч, каба, чабагач, гөбе, урак, киле, шулай ук тормыш-көнкүреш әйберләреннән керосин лампасы, бизмән, сугылган тастымал, хатын-кыз киемнәре һәм бизәнү әйберләре, чабата, бишек, төрле гасыр акчалары һәм башкалар җәлеп итә.

Александр Иванович Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен, «III дәрәҗә Дан ордены», «Кызыл Йолдыз» ордены, «Батырлык өчен», «Германияне җиңгән өчен», «Совет Армиясе һәм Флотына 30 ел» медальләре белән бүләкләнә.

2002 елның 30 сентябрендә Александр Иванович арабыздан китте.

Александр Иванович Мамадыштан бу якларга укытучы булып эшкә килгән Мәймүнә исемле кызга 1954 елны өйләнә. Яшь укытучы Мәймүнәне кайсы авылга укытучы кирәк булса, шул авылга күчерәләр: Имәнлебаш, Бура-Киртә, Ашыт, Липат, Шепкә... Соңрак ул Сарсаз-Баграж мәктәбенә башлангыч сыйныф укытучысы булып килә һәм шушы изге хезмәткә 40 ел гомерен багышлый.

Үзенең гаилә бәхетен дә Сарсаз-Багражда таба. Алар 50 елга якын иңне-иңгә куеп, бергә гомер кичерделәр. Мәймүнә апа белән Александр абый гаиләсендә өч бала үсте: уллары – Валерий, Радий, кызлары – Роза. Уллары Радий алар юлын сайлады. Сарсаз-Баграж мәктәбендә менә инде 40 елдан артык математика, тарих, ОБЖ фәннәрен укыта.

Бөек Ватан сугышы тәмамланга 80 ел булса да, ул үзен сиздереп тора. Сугыш онытылмый, үз артыннан тиз генә төзәлә торган яралар калдырмый ул. 1941 елның 22 июнендә фашистик Германиянең җинаятьчел һөҗүме белән башланган Бөек Ватан сугышы елларында илебез халкы искиткеч авыр сынаулар узды. Без сугышның нинди яман чир икәнлеген белергә, аны тудырырга тырышучыларга киртә булырга тиешбез. Фашизм алып килгән бәхетсезлекләрне, кайгы-хәсрәтләрне тарих битләреннән, әдипләребез язып калдырган әсәрләрдән укып төшенергә, әби-бабаларыбызның дошманга каршы көрәштә күрсәткән данын сакларга, ничә йөз еллар үтсә дә, Кеше - Син һәм Мин, җир йөзенә яшәү өчен туган башка кешеләргә карата намуслы, олы йөрәкле, кече күңелле булып калырга тиешбез.

Фашизм дигән яман чир үз артыннан бер дистә елга җитәрлек кенә газаплар калдырмады, шуңа күрә дә безнең ул алып килгән бәхетсезлекләрне, кайгы – хәсрәтләрне, күз яшьләрен, вакытсыз өзелгән гомерләрне, яндырылган авыл-шәһәрләрне, исәпсез-хисапсыз башка газапларны онытырга хакыбыз юк!

Утны-суны кичеп, меңнәрчә чакрымнар узып, илгә Җиңү алып кайтучылар сафында **Харитонов Александр Ивановичның** да лаеклы исеме, урыны бар. Шуңа да без – яшь буын алар тудырган батырлык үрнәген кадерләп сакларга һәм киләчәк буыннарга тапшырырга бурычлы. Һәр елны авылның уртасында сугышта катнашкан авылдашларыбыз истәлегенә куелган обелиск янына килеп, сугышта катнашучыларны, илебез азатлыгы өчен башларын салучыларны искә алабыз, чәчәкләр куябыз.

Бүгенге көндә дә кешеләр өйләрендә тыныч, имин яшәсен өчен илдә сугыш бара. Минем бертуган яраткан абыем Петр сугышта. 2022 елның 25 октябрендә мобилизация буенча чакырылды. Хәзергесе көндә медбрат булып хезмәт итә. Без – әти-әнием һәм мин, көн саен ут йотып торабыз. Илләребездә тынычлык урнашып, аның тизрәк яныбызга исән-имин кайтуын телибез.

# БЕЗНЕҢ МӘКТӘП УКЫТУЧЫЛАРЫ-БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЧЫЛАР

*Игдисанова Эльза Рафаиловна,*
*Пермь крае Лысьва шәһәре*
*МБГББУ "7нче номерлы ГУББМ" «Канабек төп гомуми белем бирү мәктәбе» структур бүлекчәсе.*

1941 – 1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышы – Россия тарихында иң авыр чорларның берсе. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан – ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн буена дәвам иткән коточкыч вакыйгаларны һич тә онытa алмый. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, хатын – кызлар – тол, бик күп балалар ятим калды. Фашистларга каршы төрле профессия кешеләре кулларына корал алып көрәште.

Бөек Ватан сугышы халык мәгарифе системасына һәм Совет мәктәбе эшчәнлегендә тирән эз калдырды. Сугыш башлангач, укытучылар, мәктәпне тәмамлаган укучылар һәм аларның эти-әниләре белән бергә фронтка китә. Укытучылар сугышларда батырлык, сугышчан осталык, тапкырлык һәм зирәклек үрнәге күрсәтәләр. Иң катлаулы сугыш шартларында да солдат-укытучы педагог-тәрбияче булып кала, сугышчыларны батырлыкка дәртләндерә, дошманны җиңәргә өйрәтә. Шулай итеп, сугыш совет халкы өчен, шул исәптән укытучылар өчен дә кырыс сынау булды.

Һәрбер авылдан, һәрбер шәһәрдән укытучылар бу сугышта катнашты.

Канабек авылыннан 131 кеше сугышка китә, шулар арасында өч укытучы була. Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучыларыбызның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүне актуаль дип саныйм. Минем тикшеренү эшем Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучылар турында бер истәлек булыр.

Максат:

1.Бөек Ватан сугышында катнашучы якташ – укытучыларымның тарихын өйрәнү .

2.Бөек Ватан сугышында катнашучыларның документларын җыю һәм саклау.

Бурычлар:

1.гаилә архивын өйрәнү;

2. якташ укытучыларның биографик мәгълүматларын җыю;

3. җыелган мәгълүматларны мәктәпнең барлык укучыларына җиткерү;

4.җыелган мәгълүматларны мәктәп музеена урнаштыру һәм бу теманы өйрәнү эшен дәвам итү.

Тикшерү предметы: Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучыларның язмышы.

Чыганаклар:

1.шәхси һәм гаилә материаллары;

2.Канабек мәктәбенең музей бүлмәсе материаллары;

3.Канабек авылы халкының истәлекләре;

Гипотеза: Фронтовик – укытучылар Ватанны саклаучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм Бөек Җиңүгә көчләреннән килгәнчә зур өлеш кертүчеләр.

Гамәли әһәмияте: җыелган материаллар укытучыларга батырлык дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда, шулай ук мәктәп музеенда экскурсияләр үткәргәндә файдалану өчен хезмәт итәчәк.

Бөек Җиңүгә безнең мәктәп укытучылары да үз өлешләрен кертте. Бүген безнең бурычыбыз – аларның исемнәрен мәңгеләштерү, чөнки аларны онытырга безнең хакыбыз юк! Безнең авылыбыздан сугышка өч укытучы китә: Забиров Галимҗан Бәхтегәрәй улы, Сиразетдинов Шарафулла Шайгаскар улы, Солтангулов Нурулла Хафиз улы.

1.Забиров Галимҗан Бәхтегәрәй улы - сугышта һәлак булган укытучыбыз.

Забиров Галимҗан Бәхтегәрәй улы 1918 нче елның 18 июнендә Канабек авылында туа. Канабек һәм Байтирәк мәктәбендә белем ала. Байтирәк мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң, Свердловск педагогия техникумында 3 ел укый. Аны тәмамлагач, Канабек мәктәбенә кайтып, башлангыч сыйныф укучыларын укыта башлый. Ул бик актив була, беренчеләрдән булып авылда велосипед ала. Эшендә таләпчән һәм гадел була, шуңа күрә укучылар аны хөрмәт белән искә алалар. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941нче елның июлендә аны политруклар курсына җибәрәләр.

Совет армиясе офицеры Галимҗан Бәхтегәрәй улы танк ротасы белән командалык итә. Кызганычка каршы, 1942 нче елда хәбәрсез югала. Аның якты истәлеге туганнары һәм авылдашлары күңелендә саклана.

1. Сиразетдинов Шарафулла Шайгаскар улы – укытучы, сугыш һәм хезмәт ветераны.

Сиразетдинов Шарафулла Шайгаскар улы 1917 елның 21 нче гыйнварында Пермь-Серга районындагы Чукбаш авылында туган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 3 ел Свердловск педагогия техникумында укый. Техникумны тәмамлагач, Кишерт районында балалар укыта.

Шарафулла Шайгаскар улы 1939 нчы елда армиягә алына. Аны Оренбург өлкәсенең Чкаловск шәһәрендәге зенит-артиллерия училищесына укырга җибәрәләр. Ул 1942 нче елга кадәр укый, өлкән лейтенат булып чыга. Сугышта зенит взводы командиры булып хезмәт итә. Мәскәү янындагы сугышта, Сталинград сугышында катнаша. Сугыш тәмамлангач, тагын 2 ел хезмәт итә, авылга 1947нчы елда гына кайтып җитә.

Сугыштан кайткач, Канабек мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Ул балаларны һәм үз эшен бик ярата. Яхшы күңелле, хөрмәтле кеше була. Канабек мәктәбендә 42 ел башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә. Тормыш иптәше Нәҗия Шәйхетдиновна да мәктәптә укыта, мәктәп директоры булып эшли.

Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Җиңү ордены, Батырлык өчен, Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Шарафулла Шайгаскар улы 2008 нче елның 4 нче июнендә вафат була.

2. Султангулов Нурулла Хафиз улы – укытучы, сугыш һәм хезмәт ветераны.

Султангулов Нурулла Хафиз улы 1915 елның 1 сентябрендә Канабек авыл Советының кечкенә Шиде авылында туа. Аның балачагы бик авыр була.Өч яшьтә әтисез кала, әнисен дә әз генә хәтерли, ә гаиләдә 6 бала.

Нурулла башта Канабек башлангыч мәктәбендә, аннары Байтирәк 7 еллык мәктәбендә укый. Байтирәк мәктәбен уңышлы тәмамлагач, 1933нче елда Свердловск педагогия училищесына укырга керә. Беренче дәресләрен Барда районы Үдик авылында үткәрә. Озакламый армиягә алалар. Ул Житомир шәһәрендә элемтәче булып хезмәт итә.

Сугыш башлангач, 1941нче елның 4 нче июлендә фронтка җибәрәләр. Аңа Төньяк-Көнбатыш фронтында, Беренче Балтыйк буе, Өченче Белоруссия фронтларында дошман белән сугышырга туры килә. Өч тапкыр яралана. 1945 елның 21 октябрендә Калининград шәһәреннән демобилизацияләнә.

Сугышта күрсәткән батырлыгы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, III дәрәҗә Дан ордены, "Батырлык өчен"медальләре белән бүләкләнә.

Авылга кайткач, Канабек мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып 37 ел эшли. 1975 елның 1 сентябрендә лаеклы ялга чыга.

Әлеге эзләнү эше укучыларга, мәктәп укытучыларына, ата-аналарга Канабек мәктәбендә эшләгән ветеран укытучылар турында күбрәк белергә мөмкинлек бирәчәк.

Безнең ветеран-педагоглар барысы да хөрмәтле һәм искиткеч, белемле, зирәк кешеләр иде. Кызганычка каршы, алар безнең белән юк инде, әмма алар безнең хәтеребездә мәңге сакланачак.

Бу тикшеренү эше файдалы гына түгел, кызыклы да, шулай ук гамәли әһәмияткә дә ия. Эзләнүләребезнең материаллары мәктәп сайтында урнаштырылачак, укытучылар тарафыннан Батырлык дәресләрендә, шулай ук патриотик тәрбия, горурлык хисе тәрбияләүгә юнәлдерелгән сыйныфтан тыш башка чараларда кулланылачак.

Әдәбият


1.Авыл тарихы альбомы.

3. Авылдашларыбыз Бөек Ватан сугышында альбомы.

5. Сугыш һ҅ем хезмәт ветераны альбомы.


Кушымта.



Забиров Галимжан Бәхтегәрәй улы



Сиразетдинов Шарафулла гаиләсе



Султангулов Нурулла Хафиз улы

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ВЕТЕРАН УКЫТУЧЫЛАР

*Галиева Рәсимә Мулланур кызы,*
*Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы*
*«К.Ф. Шакиров исемендәге Зур Сәрдек гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

Бөек Ватан сугышы дәүләтебез тарихында мөһим һәм кайгылы чор. Ул иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә кагылды халык мәгарифе системасына һәм Совет мәктәбе эшчәнлегенә авыр эз калдырды. Сугыш совет мәгариф системасы бөтен интеллигенциянең, шул исәптән укытучыларның һәм мөгаллимнәрнең эшлекле һәм ул заманда аеруча мөһим булган сәяси сыйфатлары өчен кырыс сынау булды. Укытучыларның сугыш елларындагы батырлыгы яшь буынны тәрбияләүдә шәхси үрнәкнең әһәмияте турындагы хакыйкатьнең «зирәклеген» раслады. Патриот һәм Ватанга хезмәт итәргә әзер гражданин тәрбияләү, теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле ныклы характер формалаштыру, шундый авыр вакытларда Яшь йөрәкләрне һәм акылларны белемгә сусау белән мавыктыру – мондый бурычны бары тик укытучы гына үти ала.

Безнең мәктәп музеенда Бөек Ватан сугышы ветераннары, тол хатыннар, балалар турында байтак материал тупланган инде. Өлкән буын кешеләре белән сөйләшеп, мәктәпнең туган якны өйрәнү бүлмәсендә бер почмакны Бөек Ватан сугышы турындагы материаллар аша кешелек тарихындагы мөһим чорга – Бөек Ватан сугышы чорына багышларга булдык. Мөгаен, укытучылары (элеккеге) Бөек Ватан сугышында катнашмаган мәктәпне таба алмассың. Аларның һәркайсы турында китап язарга була, чөнки һәркайсының үз фронт юлы булган, ул фашизмны җиңүгә юнәлгән. Бу һөнәр кешеләре һәрвакыт күренекле, алдынгы, лидер булып саналдылар. Бу тема өстендә эшләгәндә, мин укытучыларның үз укучыларында Ватанга карата мәхәббәт хисен сүз белән генә тәрбияләмәүләренә һәм аны сакларга әзер булуларына, ә шәхси үрнәкләре белән сугышырга, фронтка ярдәм итәргә, ил өчен авыр вакытта ярдәм күрсәтергә өйрәтүләренә күп тапкырлар инандым. Бу фикерне Советлар Союзы маршалы А.М. Василевскийның: « Укытучы фронтта да, окопларда да үз һөнәренә тугры калган, шәхси үрнәге белән ничек сугышырга кирәклеген өйрәткән», – дигән сүзләре дә раслый.

Минем туган авылымда да сугышта катнашкан укытучылар шактый. Рәшит Борһан улы Мостафин (1912–1989) 1941–1945 нче елларда офицер булып сугышта катнаша. 1946 нчы елдан 1972 нче елга кадәр Зур Сәрдек мәктәбендә физика-математика фәннәрен укыта. Сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, күп медальләр белән бүләкләнә.

Гаян Гариф улы Әхмәтшин -Сталинград янында барган сугышларда алар камалышта калалар һәм немецларга әсирлеккә төшәләр. Әсирлектә булуына сылтау итеп аны 25 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Аңа 6 ел 11 ай төрмәдә утырырга туры килә. 1955 нче елның 17 нче сентябрендәге указ нигезендә

амнистиягә эләгә һәм 20 нче сентябрьдән азат ителә. Азат ителгәннән соң ул Зур Сәрдек урта мәктәбендә хезмәт укытучысы булып эшкә урнаша.

Нургали Нуриәхмәт улы Нуриәхмәтов (1926–1996) –1926 нчы елда Чишмәбаш авылында туа. Зур Сәрдек җидееллык һәм Кукмара урта мәктәпләрен тәмамлый. 1943 нче елда ул Бөек Ватан сугышына мобилизацияләнә. Сугыштан соң «Бодо» дигән телеграф аппаратында эшләргә укый. Армиягә чакырылгач, Германиядә, совет гаскәрләре штабы карамагындагы аерым элемтә полкында телеграфист-бодист булып хезмәт итә. Тарихи Нюрнберг процессы башлангач, суд процессларын турыдан-туры Мәскәүгә хәбәр итеп торуда катнаша. Берлин өчен барган сугышлар вакытында 260 нчы аерым элемтә батальоны составында алар гаскәрләр арасында элемтәнең нормаль эшләвен тәэмин итә. Совет Армиясе сафларында барлыгы 7 ел хезмәт итеп, өлкән телеграфист сержант Нургали Нуриәхмәтов 1950 нче елда туган якларына кайтып төшә. Армиядә вакытта ул берничә медальгә, «Хәрби һәм сәяси хәзерлек отличнигы», «Элемтәче-отличник» дигән мактаулы исемнәргә лаек була. Үрнәк хезмәт иткәне өчен Германиядәге Совет гаскәрләре группасы башкомандующие – армия генералы В.И.Чуйков аны Мактау грамотасы белән бүләкли. Полк байрагы янында фоторәсемгә дә төшерәләр Нургали батырны. Аның шулай ук ВЛКСМ Үзәк комитеты тарафыннан бирелгән Мактау грамотасы да бар. Армия сафларында хезмәт иткән чорда Нургали абый үзен оста мәргән буларак та таныта.

Совет Армиясе сафларында барлыгы 7 ел хезмәт итеп, өлкән телеграфист сержант Нургали Нуриәхмәтов 1950 нче елда туган авылына кайта. Бу вакытта аның бертуган апалары Мәсрүрә, Закирә һәм сеңлесе Шакирә укытучы булып эшлиләр. Ул да, алар үрнәгендә, укытучы булырга дигән карарга килә. Экстерн тәртибендә имтиханнар тапшырып, Кукмара урта мәктәбен тәмамлый. Читтән торып Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлап, рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге ала. Олыяз мәктәбендә директор, Сәрдекбаш мәктәбендә директорның укыту эшләре буенча урынбасары вазифаларын башкара. Зур Сәрдек урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта, 40 елга якын гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый. Хәрби киемен салгач, Нургали Нуриәхмәтов авылда укытучы булып эшли башлый. Дүрт дистә елдан артык гомерен балалар белән эшләүгә багышлый ветеран. Хезмәттәге фидакарьлеге өчен төрле елларда хөкүмәтебез бүләкләренә дә лаек була ул. Минем әбием дә ул үткәргән рус теле һәм әдәбияты дәресләрен, сыйныф сәгатьләрен, рус теле түгәрәкләрен сагынып, яратып, зур хөрмәт белән искә ала. Ул бик төгәл, миһербанлы, белемле, ачык дикцияле, балаларны яратучы педагог иде дип сөйли. Нургали абый хатыны Дилбәрия апа белән 3 ул үстерделәр. Ул 1996 нчы елда Чишмәбаш авылында вафат булды.

Лаеклы ялга киткәч тә, Нургали абый мәктәп белән элемтәсен өзмәде, укучылар чакырган очрашуларда теләп катнашты. Ул 1996 нчы елда 70 яшендә каты авырудан вафат булды. Аның эшен уллары дәвам итә. Олы улы Ильяс Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, күп еллар Түбән Кама шәһәренең 1 нче гимназиясендә география укыта. Уртанчы улы Илдус Мәскәү радиотехника институтын тәмамлап, Мәскәүдә элемтә системасында эшли: этисенең хәрби

хезмәттәге һөнәрен дәвам итә. Төпчек улы Марсель Ижевск шәһәрендә тимер юл тармагында хезмәт куя.

Бүгенге көндә безнең төбәктә бер генә сугыш ветераны исән калды. Без алар алдында түләп бетергесез бурычлы. Ветераннар – безнең тарихыбыз, үткәнебез, киләчәгебез. Үткәнне онытып, без үзебезне хәзерге һәм бигрәк тә киләчәктән мәхрүм итәбез. Шуңа күрә безгә фронтовикларның-Бөек Ватан сугышы солдатларының исемнәрен истә тоту кирәк. Һәлак булганнарны хөрмәт итеп үз геройларыбызны хәтерләгәндә генә без җиңелмәс булачакбыз.

# БӨЕК ҖИҢҮ ПАРАДЫНДА КАТНАШКАН УКЫТУЧЫ ГЫЙМАДИЕВ ВӘГЫЙЗ ЗАҺРЕТДИН УЛЫ – БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК!

*Шәфигуллина Гөлгенә Рифкать кызы,*
*Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Шәүкәт Галиев исемендәге Бакырчы төп гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*

Укытучы!

Нәни баланың йөрәгенә белем орлыклары салучы, дөрес юлны күрсәтүче, мең сорауга җавап бирүче! Әйе, нәкъ менә күпне белүче, дөньяда барган вакыйгалар, тарих белән кызыксынучы, илнең төрле почмакларында булучы, 35 ел буе Бакырчы мәктәбе укучыларын тарих, география фәне серләренә төшендерүче, Бөек Ватан сугышында катнашып, 1945нче елның 24нче июнендә 3 нче Украина фронты җыелма полкының 6нчы батальоны составында Кызыл мәйданнан тантаналы марш белән Җиңү парадын үтүче 20 яшьлек татар егете, тарихларга кереп калган батырыбыз- Гыймадиев Вәгыйз Заһретдин улы! Авылыбызның дәрәҗәле укытучысы, хөрмәтле ветераны Вәгыйз абый Гыймадиев турында романнар да иҗат итеп булыр иде. Бик күп орден-медальләргә, мактаулы исемнәргә лаек булган ул! Өстәвенә, 1945 нче елның 24 нче июнендә Җиңү парадында да катнаша! Нинди зур мәртәбә! Тик болар берсе дә җиңел генә бирелмәгән шул...



Гыймадиев Вәгыйз Заһретдин улы 1925нче елның 15 мартында Апас районы Олы Бакырчы авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылында ала, урта мәктәпне күрше Чирмешән авылына йөреп тәмамлый. Яшьлеге генә тыныч вакытларга туры килми шул аның. Тормышының иң гүзәл мизгелендә- 17 яше тулган көннәрендә Вәгыйз абыйны фронтка чакыралар. Вәгыйз абый сугышта күргәннәрен, йөрәге аша үткәргән кичерешләрен бик тә мавыктыргыч итеп сөйли иде...

Сугыш кырына ул танк полкы аша, хәрби күнегүләр алып һәм үзйөрешле туп расчеты белән килә. Аннан орудия командиры итеп билгеләнә. Совет гаскәрләре Корсунь – Шевченко операциясен тәмамлаганда, дошманның уннан артык дивизиясе камалышта кала. Аларны тар-мар иткәндә безнең гаскәрләрнең дә сафы сирәгәйгән була. Үзйөрешле артиллерия полкын тулыландыручылар арасында авылдашыбыз Гыймадиев Вәгыйз абый да була. Килүгә туры ут эченә керәләр. Монысы әле сугышчан юлның башы гына була.

Кызыл Армия Днестрга юнәлгәндә, дошман зур көч туплап, безнең гаскәрләрне туктатырга тели. Әмма совет командованиясе Яссы – Кишинев

операциясен әзерләгән була. Сержант Гыймадиев артиллеристлары да салкын елганың уң ярында плацдармга урнаша. 1944 елның 20 нче августында меңләгән туп ут ача, дошман өстенә туктаусыз снаряд яудыра. Фашистларының 22 нче дивизиясен камау башлана. Тарихка Яссы – Кишинев операциясе булып кергән һәм 18 яшьлек татар егете Вәгыйз Гыймадиев та катнашкан бу коточкыч бәрелеш дошман өчен төзәтә алмаслык фаҗига белән тәмамлана.  Сугыш Румыния иленә күчә. Бер атна, ун көн дигәндә Бухарестны да явыз дошманнардан чистарталар.

Көн саен сугыш, сәгать саен ут. Немецлар тагын оборона тотарга җыеналар. Гаскәрләр туктаусыз һөҗүм итә. Сержант Гыймадиевның үзйөрешле орудиясе үкереп, ут чәчеп алга ургыла. Кинәт... Көтелмәгән хәл: снаряд тиеп машинаның чылбыры өзелә, ә каршыда – немецлар. Андый очракта югалып калу үлем белән бер. Сугыш кырында хәрәкәтсез калган танкны шунда ук мишеньгә алалар. Вәгыйз абый да моны белә. Укытучы кеше үз укучысын яклаган кебек, ул тиз генә: “Барыгыз да тышка!”- диеп фәрман бирә.  Орудиедәге дүрт кеше автоматларын тотып җиргә сикерә. Пулялар сызгыра, якында гына снарядлар ярыла. Механик белән туп коручы гәүдәләрен бераз күтәреп чылбырны ялгыйлар. Командир белән төзәүче ике якка ятып оборона тоталар. Ярдәмгә икенче машина да килеп өлгерә. Снарядлар шартлавы ешая төшә. Тирә-якта үлем җиле уйный. Ләкин осталык җиңә: чылбыры ялганган машина тубыннан ут сиптереп янә дошман өстенә ыргыла. Үзйөрешле артиллерия полкы бу сугышта оста маневр ясап, берничә җирдән оборонаны өзүгә булыша. Дошман техникасын һәм коралын ташлап качарга мәҗбүр була. Нинди батырлык! Тыңлаганда гына да күңелләр нечкәрә...

Тагын бер тетрәндергеч вакыйга: Венгриянең Дьюда станциясен алу өчен сугышканда була бу хәл. Сугыш барганда  самоходкаларының двигателе сүнә. Никадәр генә кабызырга теләсәләр дә, уңышсыз була. Шулчак үзләренә таба бер кечерәк немец танкы килүен күрәләр. Алар каршы якның двигателе сүнгәнен сизәләр, күрәсең. Якын ук килеп туктыйлар. Үзара сөйләшкәч, аларның самоходкасын танкларына трос белән тагып, үз якларына сөйрәп чыгарга телиләр. Шулай аларны тарттырып китәләр. Шулчак кинәт могҗиза була: Вәгыйз абыйларның самоходкасы кабынып китә һәм ике арада тарткалашу башлана: алар үз ягына, безнекеләр  үз ягына тарталар. Машина көчлерәк булып, немец танкын экипажы белән тарттырып китәләр һәм үзебезнең якка алып чыгалар. Бәхеткә, атыш булмый. Соңыннан командир белән водитель “Кызыл Йолдыз” ордены, ә Вәгыйз абый – “За отвагу” медале белән бүләкләнә.

Фашистлар бер генә шәһәр – авылны да сугышсыз бирмиләр.  Карпат тау итәкләре, тарлавыклары канлы сугыш мәйданына әверелә. Тау тезмәләрен үтеп яланга һәм Дунайга чыккач, Венгриянең башкаласы Будапешт өчен өермә башлана. Фашистларны бу каладан да бәреп чыгаралар. Артиллерия полкы составындагы Гыймадиев тубы  расчеты алган искитмәле матур Балатон күленә барып җитә һәм ул төбәктә дә үзен чын батыр итеп күрсәтә. Ә алда көтелмәгән яңа бәрелешләр, алда- Альп таулары, Австрия җире. Ниһаять, бөтен җирне яңгыратып бер тавыш яңгырый, күптән көтелгән тавыш:  “Ура!”  Солдатлар, Совет Армиясе батырлары Җиңү салюты бирәләр. Бу тоташ гөрселдәү кыя-

ташларга һәм урманнарга бәрелә-сугыла йөреп сүнәргә өлгерми, тагын салют, тагын кайтаваз, гүя җиһан үзе аңа куәт бирә: Җиңү! Җиңү!  Аларны фашистлар таптаган таулар, үзәннәр тыңлый. Җиңү авазы илләргә җәелә! Җиңү!!!

Җир шатлана... Вәгыйз абый сөенә. Ул да автоматын югары төбәп  салют җибәрә. Аның куанычы да кайтаваз булып карлы-бозлы  таулар арасында йөри. Башка  беркайчан да тетрәмәсен таулар! Аяк астында чәчәкләр  сулмасын! Вәгыйз абыйның теләкләре әнә шундый булган бу минутларда.

“И так началась война. Нас шестиклассников отправили в колхозы, которые остались без рабочих: кого забрали в армию, немцев выселили всех поголовно. Урожай в тот год уродился богатый, и нам, школьникам и женщинам, досталось его убирать. В основном работали на овощных плантациях - убирали огурцы, помидоры, арбузы, дыни и прочее. Жить приходилось в брошенных домах, еду готовили сами по очереди. Для этого оставляли двух дежурных. Сколько было пролито слёз из-за испорченной еды -да и что могли тогда в нашем-то возрасте. С нами был учитель физкультуры. В одной комнате жили мальчики, в другой – девочки, а учитель спал в коридоре на раскладушке под дверью девчачьей комнаты. Отработали сентябрь, наступил октябрь, начались дожди, здорово похолодало, а мы в летней одежде. Многие заболели, мы плакали, и нас отпустили домой.

Начались занятия в школе. Количество учеников не убавилось. Появилось много новеньких из эвакуированных, среди них было много евреев. Они отличались хорошей успеваемостью и различными талантами.

После шестого класса летом нас опять отправили по колхозам. Сперва пололи пшеницу, которая заросла осотом. Дёргали голыми руками, никаких перчаток, конечно же, никто не выдавал. Потом руки стали обвязывать тряпками. Далее были овощные плантации, где мы тоже занимались прополкой. В августе в небе начали появляться немецкие самолёты-разведчики. Только когда фронт приблизился настолько, что стала слышна орудийная канонада и по ночам в стороне Сталинграда было видно зарево от пожаров, нас отпустили домой.

Дома везде по улицам и во дворах были выкопаны бомбоубежища. Жили мы тогда в большой квартире (раньше жил прокурор). И к нам подселили много квартирантов: военные, медсёстры, врач с женой (евреи) - как то все умещались. Мама готовила еду для всех (они из пайков давали ей на это продукты). Уже тогда начались воздушные тревоги, но бросали в основном листовки. Потом начались регулярные бомбежки и обстрелы станции, особенно, когда скапливались эшелоны с военными и раненными. Ещё до бомбёжки мы видели, как с земли пускали ракеты с железнодорожного моста. Какие-то диверсанты их пускали по ночам, наверное указывали объекты для бомбёжек.

Тревоги объявляли и ночью, но чаще налетали бомбардировщики без объявления тревоги, заставали нас врасплох, мы не могли даже выскочить из дома. Тогда мы по ночам начали устанавливать дежурства. Часто нам приходилось дежурить с лейтенантом Петровым. Он после ранения работал в военкомате, а жил у нас. Когда мы слышали гул самолётов (у немецких особый гул - как у сепаратора), мы будили остальных и все прятались в бомбоубежища. После бомбёжки самолёты снова возвращались и из пулемётов обстреливали. Всё это продолжалось с небольшими перерывами до января 1942 года.

Школу в центре разбомбили ещё до начала учебного года, учиться начали в октябре. Учебные классы оборудовали в домах немцев, которые пустовали после их выселения. На уроке мы сидели и не столько слушали учителя, сколько прислушивались - не летят ли немецкие самолёты.

Сестра училась в третью смену, ночью. Они брали с собой пузырьки с керосином и нитяным фитилём. Зажигали эту коптилку у себя под носом, так как света не было. Керосиновая лампа была только на столе учителя. Она из школы приходила перед рассветом перепачканная сажей от коптилки. Мама нас отговаривала ходить в школу - говорила, если погибать. то всем вместе.

В феврале 1943 года нас принимали в комсомол. К тому времени немцев уже отогнали от Сталинграда и мы спокойно учились в две смены. Учеников прибавилось. В классах(домах) было холодно. Топили чуть-чуть. Сидели в одежде. Чернила в чернильнице замерзали и мы держали их за пазухой. Писали на газетах и старых книгах между строчек. Для контрольных работ учитель давал по одному чистому тетрадному листу.

Летом после седьмого класса нас направили на железную дорогу чинить разрушенные пути. Мы как муравьи хватались за рельсы и тащили её к месту

установки, где рабочие их устанавливали, мы деревянными лопатами «штопали», то есть утрамбовывали песок между шпал. За это нам выдавали взрослую карточку на хлеб-500 грамм в сутки, а до этого мы как иждивенцы получали по 300 грамм в день. Ещё нас бесплатно кормили в рабочей столовой, где в основном была из кислой капусты или лапша с подсолнечным маслом. По окончанию работ, нам даже заплатили деньги и я купила себе платье к школе на заработанные деньги.

В 8-ом классе мы уже учились в отремонтированной школе. Учеников было много и только 6 мальчишек, остальные уже работали-помогали своим матерям содержать семьи.

Ещё с седьмого класса у нас преподавали военное дело: изучали винтовку образца 1891 года, пулемёт Дегтярёва и пистолет-пулемёт Шпагина. Умели собирать и разбирать, а вот стреляли из мелкокалиберной винтовки. Нас учили строевой подготовке и соревновались за лучшее место. Я была командиром отделения и нас часто хвалили.

Мама работала уборщицей в военкомате, где раньше начальником был отец. Мы очень голодали. Зимой и весной корова не доилась и весь запас продуктов был: хлеб (500 грамм у мамы и 300 у нас) и солёные зелёные помидоры. Когда отец работал здесь, то нам кое-что привозили из соседних колхозов. Мне было полегче, так как подруга моя Оля меня подкармливала и я иногда у неё ночевала. А потом жёны новых молодых начальников просили маму, чтобы я понянчилась с их малыми детьми, когда они отлучались. Я читала им сказки, пела песни ну и иногда меня оставляли ночевать, опять же , подкармливая.

Когда отец приехал в краткий отпуск и увидел, как мы голодаем. Он решил нас забрать с собой. К этому времени его часть перевели в Миллерово Ростовской области. Сам уехал и прислал нам вызов из части. Ехать пришлось в товарном вагоне вместе с бойцами, которых отправляли на фронт. Бойцы нас снабжали кипятком и кое-какими продуктами. Они знали, что мы едем к отцу-старшему лейтенанту и относились к нам с сочувствием. Приехали в Миллерово в июле. Поселили нас к старушкам в четырехкомнатную квартиру. Это была квартира лётчика, который в это время служил в Оренбурге.

Меня устроили на работу в овощное хозяйство при лётной части, где отец был начальником. Мы собирали урожай огурцов, помидоры, початки кукурузы, картошку. Мне сейчас удивительно, как это 15-летняя девчонка таскала мешки с огурцами, взвалив их себе на плечо выносила из оврага. Никто тогда не заботился об условиях труда детей. Тогда я услышала, как поют украинские женщины. Это было что-то завораживающее и удивительно красиво.

В сентябре снова пошла в школу. Школа после оккупации была в негодном состоянии. Окна выбиты, их заложили кирпичом, оставив на самом верху немного остеклённой площади. Ученики в классе все были старше меня на 2 года, поскольку во время оккупации никто не учился. Многое за это время они позабыли и я оказалась самой лучшей ученицей.

Зимой отца перевели в Польшу. Я наотрез отказалась ехать с ними, потому что там не было русской школы, а я хотела учиться. И вот я стала жить в

компании с хозяйками-старушками. Мне оставили продовольственный аттестат, по которому я в военкомате получала какие то деньги. Но в Польше они прожили недолго. Солдат наших местные жители стали травить древесным спиртом, а также их семьи. По указу правительства семьи военнослужащих стали высылать в Союз. Мама, сестра, брат вернулись ко мне. Мы сменили квартиру, так как лётчик вернулся с семьей домой. Мы жили в небольшом саманном доме на окраине у одинокой казачки. Мама шила соседям платья, кофты и брала за работу продуктами. На аттестат отца было трудно прожить и он велел нам уезжать на родину в Ново-Осоргино.

День победы мы встретили бурно. Нас отпустили с уроков. Мы ушли всем классом в лес (это далеко за городом). Развели там костёр, пекли картошку, играли, пели, просто бесились, прыгали через костёр. Все были безумно рады. Поздно вечером вернулись домой. Победа для меня – символ хорошей жизни. Победа должна была осуществить мою мечту – выучиться на учителя.

Помню, как на комсомольском съезде мы с сестрой были делегатами (она работала секретарём в комитете комсомола). После был концерт и танцы.

И всё же в августе мы поехали к себе домой. Мама повела меня в Камышлу, где была средняя школа. После городской школы мне было скучно. По окончанию школы нужно было сдавать экзамены на аттестат зрелости (впервые в стране). Сдавать нужно было где - то 8-10 предметов. Сдала я хорошо, только одна четвёрка, остальные пятёрки. С двоюродной сестрой сдали документы в Бугурусланский учительский институт, приняли даже без экзаменов. Когда учёба закончилась, вернулись домой, но уже с направлением на работу на руках. Направлялись мы в Оренбургскую область. Нам, как отличникам, можно было выбирать любой район и я выбрала Сок - Кармалинский, чтобы ближе к дому. Летом я вместо мамы работала в колхозе. Отец демобилизовался в 1946 году.

В августе я пошла пешком в Сок-Кармалу, ныне Северное, за назначением. Меня назначили в Курвасильевку. Отец отвёз меня на лошади с жалкими пожитками, мешком картошки и почти без денег, так как все подъёмные я отдала отцу на строительство дома. На октябрьские праздники из соседней деревни Жмакино приехали молодежь на праздник. Среди них был и Медеведев Алексей Яковлевич, где мы и познакомились.

В 1949 году вышла замуж и начала работать в Жмакинской семилетней школе. Вела математику и немецкий язык, а Алексей - математику и физику. Еще занималась с ребятами художественной самодеятельностью и вела еще уроки пения и черчения в 7ом классе-в котором ничего не понимала и по учебнику училась вместе с ними. В 1958 году Алексея избрали председателем колхоза «Рассвет» по просьбе колхозников, позже, когда колхоз укрупнили, переименовали в «Зеленая долина».

В 1964году переехали в Ново-Домосейкино, так как меня назначили директором школы.

В 1968 году решили уехать в Бугульму и нас приняли в школу №9. Директором была бывшая фронтовичка - Сидоркина Капитолина Андреевна, а завучем – Анна Иннокентьевна Шаталова. Мужа назначили учителем физики и

математики. Работа после деревни мне показалось трудной. Во-первых, в классах по 42-45 учеников, во-вторых еще дали классное руководство в 5ом классе. Дети были из неблагополучных семей, поведение плохое, неусидчивые - плохо усваивали учебный материал. Приходилось ходить к родителям, а на родительских собраниях читать лекции о воспитании. Приходилось работать до вечера: уроки, группа продленного дня, внеклассная работа, на своих детей времени не оставалось. Один выходной день, который страшил еще больше - уборка, стирка, баня да куча тетрадей, которые надо проверить. Ладно, хоть ребята помогали мыть полы, посуду, возить во флягах воду из колонки.

В 1979 году ушла на пенсию по выслуге лет. В это же время мы с коллегами учительницами-пенсионерами ходили в бассейн. Сагитировала нас бывшая директриса Капитолина Андреевна. Приходили к 8 часам. Сначала в зале занимались гимнастикой. Потом душ, после на 45 минут в бассейн. После бассейна снова душ. Мы все стали чувствовать себя намного лучше. Энергии хватало и на работу и на рукоделие. “

Такая сильная, мужественная женщина дожила до 75летия Победы. Она была частой гостью в нашей школе на различных мероприятиях. Мы часто навещали её с коллегами, учениками, где слышали правдивую, подлинную правду из её уст. Она труженик тыла. Её судьба и история семьи была неразрывно связана с историей нашей страны, нашего народа. Мы гордимся, что среди нас существовала такой замечательный педагог.

# ЕЛАМЫЙ ТОРГАН СӘЙДӘ (ФРОНТОВИК УКЫТУЧЫ МӨХӘММӘТШИНА СӘЙДӘ АПАНЫҢ СУГЫШЧАН ҺӘМ ТОРМЫШ ЮЛЫ)

*Габдрахманова Илдария Барый кызы,*
*МББУ“Түнтәр урта гомуми мәктәбе”*

## Кереш

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы туган илем халкына бик күп бәла-казалар, зур корбаннар китерде. Бу сугыш тарихка «канлы хәрефләр» белән язылды. Бу вакыйгалар, андагы батырлыклар 80 еллык тарих катламы астында калды. Ләкин әнә шул катламнар астында югалмыйча, бүгенге көннәргә кадәр халык күңелендә онытылмаган каһарманнарыбызның батырлыклары әле исән. Шуңа күрә безгә аларны онытмаска, аларны хөрмәт итәргә, зурларга, батырлыкларын киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез.

Әлеге эзләнүле-тикшеренү эше дә менә шушы күзлектән чыгып язылды. Эшнең максаты фронтовик укытучыбыз, Мөхәммәтшина Сәйдә апаның сугышчан һәм тормыш юлы аша, туган иле, туган җире өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарыбызга карата горурлану хисе тәрбияләү. Шуңа күрә әлеге тема бик актуаль.

Фәнни тикшерү эшенең бурычлары:

1. Бөек Җиңүгә 80 ел булу уңаеннан Бөек Ватан сугышы чорында якташ фронтовик хатын-кызларның язмышлары белән кызыксыну.
2. Аларның сугышчан юллары һәм батырлыклары турында мәгълүмат җыю.
3. Сугыштан соңгы тормышларын өйрәнү.

Методлар:

1. Фәнни, әдәби, матбугат һәм интернет материаллары белән эшләү.
2. Архив чыганакларын өйрәнү, анализлау.
3. Музейдагы документларны барлау, өйрәнү.

Өйрәнү предметы: фронтовик укытучы Мөхәммәтшина Сәйдә апа турында мәгълуматлар, язмалар, истәлекләр.

Эзләнү этаплары:

1. Якташ фронтовик хатын-кызларның исемлеген барлау.
2. Авылдашым Мөхәммәтшина Сәйдә апа турында материаллар җыю.
3. Кызы укытучы Закирова Гөлсинә апа язып алып калган әнисенең истәлекләре белән танышу.
3. Сәйдә апаны белүчеләр белән очрашып сөйләшү.
4. Эшне йомгаклау.

Эшенең төзелешенә килгәндә, ул Кереш, Төп өлеш, Йомгаклаудан һәм

файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора. Керештә әлеге эшнең актуальлеген һәм максатын билгеләдек, төп бурычлар ачыкланды, тикшерү объекты күрсәтелде, безнең темага караган хезмәтләр барланды.

Төп өлештә Бөек Ватан сугышында ир-атлар белән берлектә хатын-кызларыбызның да батырларча көрәшүе ачыкланды, мәгълүматлар тупланды; фронтовик укытучы Мөхәммәтшина Сәйдә апаның сугышка кадәрге тормышын,

аның Кызыл байраклы 134 истрибитель авиаполкындагы сугышчан юлын, күрсәткән батырлыкларын сурәтләүгә киң урын бирелде, аның хәтирәләре турында, Сәйдә апаның сугыштан соң укытучылык эшчәнлеге хакында сөйләнелде. Авылдашларның аның турында фикерләре кертелде. Йомгакта эшчәнлегемнән чыгып, төп нәтиҗәләрне яздым, соңыннан әдәбият исемлеге китерелде.

**Төп өлеш**

Сугыш... Күпме ачы күз яшен, кайгы-хәсрәтне үз эченә алган бу шомлы сүз. Аны ишетүгә үк, күз алдына янып каралган иген басулары, ятим калган сабыйлар, газиз ирләрен, сөекле балаларын югалткан аналар килеп баса. Җиңү таңы җиңел генә килмәде. Шушы бәхетебез өчен үз – үзләрен аямаган кешеләрнең батырлыгын бәяли beləбезме без, ил хакын олылап кылган изгелекләрен – тәвәккәллекләрен хөрмәт итәбезме? Туган җиребезне, туган илебезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарның исемнәрен мәңгеләштерәбезме? Шушы сораулар Ватаныбыз азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкән якташларыбызның фронт елъязмасын өйрәнүгә этәрде һәм мин авылыбызның фронтовик-укытучы Мәхәммәтшина Сәйдә апабызның сугышчан һәм тормыш юлын өйрәндем.

Хатын-кыз һәм сугыш. Болар бер-берсенә ят төшенчәләр, аларны янәшә куеп, үзара бәйләнештә әйтүе сәер. Чөнки хатын-кызның асыл табигате, ходай насыйп иткән вазыйфасы – мәрхәмәтле ана булу, җиргә яңа буын китерү, кешеләргә матурлык бүләк итү.

Сугыш – ирләр эше, дисәләр дә, ул хатын-кызларны да аямаган. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк, хатын-кызлар да көрәшчеләр сафына баскан. Алар да ир-атлар белән бергә пуля, снаряд, самолетлар белән дошманга үлем илткән. Алар партизан отрядларында фашистларга каршы көрәшкән, яралыларны дәвалаган, заводларда корал җитештергән.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Татарстаннан 800 меңгә якын хатын-кыз, Ватаныбыз иминлеген саклап, яуга күтәрелә. Алар арасында безнең Балтач районыннан киткән хатын-кызлар да була. Районыбыздан сугышка 68 кыз алына, шуларның 27се – мәгариф хезмәткәрләре. Алар күп төрле гаскәрләрдә хезмәт итә. Күбесе сугышчыларга медицина ярдәме күрсәтә, алар миллионлаган сугышчының гомерен саклап кала. Хезмәтләре һәм батырлыклары өчен фронтовик хатын-кызларыбыз орден-медальләр белән бүләкләнә.

Сугышка алынган кызларга махсус таләпләр куела: белеме җиде класстан түбән булырга тиеш түгел, рус телен белүе шарт, медицина картасы тутырылган һәм сәламәт булырга тиеш, политик хәзерлеге һәм мораль тотнаклыгы исәпкә алынган. Кызларның сугыш чоры биографияләрендә шундый юллар саклана: “Тәртипле, үзенә тапшырылган хезмәтне намус белән башкара, үз һөнәрен яхшы белә. Олыларга, командирларга хөрмәт белән карый, ягымлы, ярдәмчел. Сугышта үзен батырларча тотты, политик хәзерлеге яхшы, нык...” Бу гомуми бәяләү, әлбәттә. Ләкин фронтовик кызларның һәрберсенең үрнәк булырлык сугыш чоры һәм сугыштан соңгы данлы хезмәт биографияләре тормыш эпизодлары, истәлекләре бар.

Мин дә шундый фронтовик мөгаллим, авылыбызның мөхтәрәм булган хатын-кызларыбызның берсе – Мөхәммәтшина Сәйдә апаның сугыш һәм тормыш юлын өйрәндем. Аңа язмыш авыр һәм катлаулы сынауларны бер – бер артлы тезеп кенә торган.

Сәйдә апа 1919 нчы елның 16 нчы сентябрендә Чепья районы Түнтәр авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Гаилә зур, 10 баланың 7се исән-сау үсә. 1929 елдан колхозда член булып торалар.

Гаиләдәге икенче бала Сәйдә 1929 елда Түнтәр авылындагы мәктәпкә укырга бара, бик тырыш, үзсүзле, белемгә омтылучан укучы була. Аавыл мәктәбен «4» ле, «5» ле билгеләренә генә тәмамлагач, 1936 нчы елда Казан педагогия училищесы студенты булу бәхетенә ирешә.

1939 нчы елда училищены тәмамлап, Смәел урта мәктәбендә укыта башлый ул. 1940 – 1941 нче уку елында Арбор сигезьеллык мәктәбенә завуч, география-биология укытучысы итеп күчерелә. Хезмәтенә һәм белеменә куанып, “җиң сызганып” мөгаллимлек эшенә тотынган Сәйдә апаның хезмәт биографиясе шунда өзелә, аның биографиясенә фронт елъязмасы языла башлый.

“1942 нче елның май ае. Шомлы, өметсез көннәр. Совет гаскәрләре чигенәләр. Ир-егетләр инде күптән фронтта. Кызларга да сугышка китәргә хәбәр килә башлый, күпләре үзләре теләп китәләр. Менә бер төркем классташларын туплаган җиденче класс укучысы Әминә Әскәрова Арбордан Чепьяга юнәлә. Военкоматтан озатканчы өлгерергә кирәк. Бүген аларның укытучылары – Мөхәммәтшина Сәйдә апалары сугышка китә. Әйе, ул көнне Чепья хәрби коммисариаты Арбор мәктәбе укытучысы – Сәйдә Мәхәммәтшина, Түнтәр мәктәбе укытучысы – Тәскирә Фазлыева, Пыжмара мәктәбеннән – Асия Шәймуллина һәм башка кызларны фронтка озатырга тиеш була” [1]

1942 нче елның 20 нче маенда Сәйдә апа туган илен фашистлардан саклар өчен фронтка китә. Хәрби хәзерлек үтеп (укып), “Авиационные мотористы и мастера” специальносте буенча “стрелок авивооружения” квалификациясенә ия була.

Сәйдә апа истәлекләрендә ул чордагы вакыйгалар менә ничек тасвирлана: “Казаннан, товар вагоннарына төялеп, көнчыгышка юл тоттык. Ил чиге тынгысыз, аны япон самурайларыннан сакларга кирәк. Бер айга якын барганнан соң, Хабаровск шәһәрендә тукталдык. Монда безне кече авиабелгечләр мәктәбендә укыттылар. Уку барышында толымнарыбызны кисеп ташладылар. Барыбыз да малайларга охшап калдык... Имтиханнарны тапшыргач, Кызыл байраклы, 134 истрибитель авиаполкына билгеләделәр. Шунда "Як-9" самолетларына пулеметлар, пушкалар, патроннар һәм кирәк-яраклар хәзерләдек. Тайганың сазлыклы, черкиле кырыс урманы безне чыныктырды, шагыйрь әйтмешли, еламаска өйрәтте.

Безнең полкта өч эскадрилья иде. Мин беренчесендә хезмәт иттем. Хезмәт чорында полк өч аэродромга күчте. Аэродромны үзебез хәзерлибез, землянкалар казыйбыз, самолетларга яшерен урыннар төзибез. Берсендә торак итеп ат абзары да файдаландык. Җәй айларында аеруча куркыныч булды. Көн

---

[1] “Хезмәт”газетасы, 2015, №8

саен диярлек тревога, һәрвакыт әзер торырга кирәк. Көнме, төнме винтовкаңны тотып, противогазыңны киеп, каешка патронташыңны асып, экипажың янына йөгерәсең. Очучы кабинада утыра. Без, хезмәт күрсәтүчеләр: механик, моторист, коралландыручылар, радистлар очышның төгәл һәм хәвефсез булуын тәэмин итәргә тиеш. Ракета җибәрелгәч кенә, самолетлар очып китә. Безнең полкның төп максаты – көнчыгыш чикне саклау һәм махсус мәктәп бетереп килгән яшь очучыларны яхшылап өйрәтеп, көнбатышка озату иде. Монда төрле хәлләр булды. Бервакыт япон самурайлары күрше казармадагы бөтен солдатларны төнлә суеп чыкканнар. Очышка киткән экипажның кире аэродромга әйләнеп кайтмаган көннәре кара кайгыга әйләнә иде.

Полк сынатмады, алган Кызыл байрагына тап төшермәде, һәрвакыт алдынгы булды. Мин дә тырышып хезмәт иттем. Бәйрәм көннәрендә, почетлы каравылда тору бәхете миңа да еш тиде. Полк байрагын саклап штабта да тордым, иң төз атучы да идем. Иптәшләрем мине"еламый торган Сәйдә" дип йөртәләр иде. Шулай да, әтинең үлгән хәбәрен алгач, бик каты елаганым хәтердә”.[2]

Сәйдә апа сугышта үзенең беренче мәхәббәтен очрата. Бу турыда да истәлекләрендә яза: “Миңа да чибәр украин егете Василий Яковлев гашыйк булды. Вася ясап биргән кашык, пәке, башка вак – төякләр бик кирәкле булды, кайберләрен әле истәлеккә саклыйм. Альбомда аның ялкынлы йөрәк сүзләрен язып бүләк иткән фоторәсемнәре саклана.

Сугыш бетеп аерылышканда Вася, үз якларында урнашкач, мине кайтып алачагын әйтте. Чынлап та, аннан хатлар килеп торды...[3].

Сугыш бетү көнен дә Сәйдә апа Ерак Көнчыгышта каршылый. “9 май – Җиңү көнен шатланып каршы алдык. Ләкин без илгә куркыныч янап торган японнарга каршы сугышларга хәзерләнә башладык. Без торган казарма артыннан туктаусыз гаскәрләр һәм хәрби техника үтеп торды. Япония белән сугыш башланды. Безнең полк самолетлары да сугышта катнашты. Без җиңдек, шатлыкның иге – чиге юк. 1945 нче елның октябрендә, Сталинның рәхмәт хаты белән бүләкләнеп, туган якларга юл тоттым”[4], - дип яза батыр йөрәкле фронтовик кыз.

Яхшы хезмәт иткәне өчен Сталинның Рәхмәт хаты белән бүләкләнеп, Ерак Көнчыгыш белән саубуллашып, 1945 елның октябрендә ир йөрәкле Сәйдә апа исән-сау туган якларына әйләнеп кайта. Сугыштан соң “Ватан сугышы” ордены, 8 медаль белән бүләкләнә.

Авылга кайткач, Сәйдә апа үз һөнәре – укытучылык эшенә керешә. Солдат шинеле белән туган авылына кайткан укытучы әле биш ел, башка киеме булмау сәбәпле, шул кызыл йолдызлы бүреге һәм шинеле белән тыныч тормышта җиң сызганып эшли. Арбор һәм Түнтәр мәктәпләрендә директор була. Тагын, өсте –

[2] Сәйдә Мөхәмметшинаның истәлекләреннән. Кызы Мөхәмметшина Гөлсинә язып ала.
[3] Шулай ук
[4] Сәйдә Мөхәмметшинаның истәлекләреннән. Кызы Мөхәмметшина Гөлсинә язып ала.

өстенә җәмәгать эшләре: агитатор, пропагандист, партоешма секретаре, агитколлектив җитәкчесе, лектория җитәкчесе һ.б.

Мәктәпләр ул чорда әле бетеп, әле ачылып, әле башлангыч мәктәп, әле җидееллык булып торганнар. Шуңа күрә дә Сәйдә апага Смәел, Түнтәр, Арбор, Шода, Субаш мәктәпләрендә укытырга туры килгән. Бу авыллар арасы һәрвакыт җәяү үтелгән “Кышкы бураннарда өйгә бозга әйләнеп кайтып кергән көннәрем дә була иде”, - дип язып калдырган ветеран укытучы.

1958-60 нчы елларда Сәйдә апа Түнтәр башлангыч мәктәбе мөдире һәм укытучысы була. Ә 1960 нчы елда Түнтәрдә җидееллык мәктәп ачыла һәм Сәйдә апа шунда математика, биология укыта. 35 ел мөгаллимлек итеп, 1974 нче елда лаеклы ялга чыга. Тырыш хезмәте өчен ул В.И.Ленинның 100 еллык юбилее уңаеннан “Батыр хезмәт өчен” һәм “Хезмәт ветераны” медале, күп кенә Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Бу бүләкләр – аның намуслы хезмәт нәтиҗәсе.

Кайда гына булса да, үзенә һәм башкаларга да таләпчән, эшен җиренә җиткереп, булсынга эшләгән ул. Моның шулай икәнен мин Сәйдә апа укытып чыгарган авылдашлар белән сөйләшкәндә дә аңладым. “Ул безне, иң шаян, иң усал малайларны да, бер күз карашы белән генә җиңә иде. Бер вакытта да кычкырмады, тавышын күтәрмәде, төпле белем бирде”, - диләр алар.

Әнә шулай, миллионлаган совет кешеләре белән бергә, Сәйдә апа да Җиңүгә үз өлешен керткән. Ул – авыр сугыш елларының ачысын-төчесен татып, җиңү сәгатен якынайту өчен тиңдәшсез сугыш батырлыклары күрсәтеп, сугыштан соң балаларга белем һәм тәрбия биреп, хезмәт батырлыклары күрсәткән фидакәрь хатын. Сәйдә апа күптәннән безнең арабызда юк инде. Язмама Сәйдә апа альбомыннан алынган кайбер тарихи истәлекләрне дә терким. Аның орден, медальләре, фоторәсемнәре, мактау кәгазьләре – безнең өчен кадерле ядкәр.

## Йомгаклау

Бу эшне башкарган вакыт эчендә мин үземә бик күп мәгълүматлар алдым. Бөек Ватан сугышында җиңүнең тарихи әһәмиятен, асылын тирәнтен аңладым, тарихи вакыйгаларның авылыбыз язмышында ни дәрәҗәдә чагылуын күрдем, фронтта һәм тылда өлкән буын күрсәткән батырлыкларны күз алдына китердем. Алар белән горурлану хисләре туды. Без үткәннәрне онытырга тиеш түгел. Үткәннәрсез киләчәк юк. Үткәнебезне, тарихыбызны барлап кына, без үзебезнең әби-бабайларыбызның якты истәлегенә лаек була алабыз.

Тормышта төрле кеше очрый. Эше чыпчык тезеннән булып, сүзе тау кадәрле булганнары да, мактанмыйча, югары дәрәҗәгә омтылмыйча тыйнак һәм шыпырт кына яшәп ятканнары да була. Бүген мин сезгә менә шушы икенче төркемгә кергән, күкрәген орден һәм медальләр бизәгән, лачын йөрәкле гүзәл зат, сугыш ветераны – Мәхәммәтшина Сәйдә апа турында сөйләдем. Эш барышында газета-журнал һәм интернет материаллары белән таныштым, китапханәдә, музейда һәм архив материалларында эзләндем, авылдашлар белән, Сәйдә апаның туганнары белән аралаштым. Минем өчен шунысы сөенечле: мәктәбебез музеена тапшырырлык өстәмә материал тупладым.

Без сугышта җиңү яулаган батырларыбызны онытырга хакыбыз юк. Алар турында истәлекләр буыннан-буынга күчәргә тиеш.

## Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар


1. Зарипов Р.Ш. “Тирән тамырлы Түнтәрем” китабы.
2. Мөхәммәтҗанов М.Г. “Алгарыш ташкыны ак җилкәннәр” китабы, Казан, 2010.
3. “Сөембикә” журналы, 2007 ел, №5.
4. “Хезмәт” газетасы, 2015 ел, № 8, 9.
5. Мәктәп музеенда сакланган архив документлары, тарихи истәлекләр.
6. Укытучы Закирова Г.Г. истәлекләре.
7. https://ru.wikipedia.org/wiki/


## Кушымта



Укытучы Сәйдә Мөхәммәтшина



Сәйдә апа Ерак Көнчыгыш фронтында




Сәйдә Мөхәммәтшина фронтта



Ерак Көнчыгыш фронтында Җиңү көне кызлар арасында (уртада алгы рәттә)



Сугыш чорында Сәйдә апаны ошатып йөргән Украина егете, Вася Яковлев



На добрую долгую и незабываемую память Милой Сонечке от Василия для воспоминания о нашей совместной работе и дружбе в РВСКА
31.5.46. года
Яковлев

Сәйдә апага язган истәлекләре.



Сәйдә апаның мактау кәгазьләре



Сәйдә апаның  орден медальләре

# ЖИЗНЬ ДЛИНОЮ В ВЕК

*Шарипова Файруза Фанисовна*
*(научный руководитель Шарипова Э.И.)*
*МБОУ «СОШ села Манзарас» Кукморского муниципального района*

Годы все дальше уносят нас от тех страшных лет, которые мы не имеем право забыть. Все меньше остается очевидцев Великой Отечественной Войны. Войны, которая стала суровым испытанием для всего советского народа, в том числе и для учителей и преподавателей.

Целью написания нашей статьи является сохранение памяти о людях, которые прославили малую Родину, привлечение внимания к профессии учителя, что может способствовать осознанному выбору учащимися этой профессии в будущем. Кроме того, знание истории родного края и его лучших представителей является залогом воспитания любви и уважения к предкам, их прошлому и настоящему.

В своей статье мы хотим рассказать об одном из таких людей, о нашем земляке, о ветеране ВОВ, об учителе, который когда-то преподавал географию моим дедушке и бабушке – о Мирзине Ахате Мирзовиче.

Мирзин Ахат Мирзович родился в 1918 году в деревне Нижний Арбаш Кукморского района в крестьянской семье. – Детство было непростым, мы четверо детей, росли с мамой. Отец из-за проблем с сердцем умер рано, мне было тогда шесть лет, - вспоминал Ахат Мирзин. В конце сентября 1940 года он был призван в армию. Во время Великой Отечественной Войны служил командиром отделения разведчиков в частях морской авиации на Тихом океане. Даже в мае 1945 года война для него не закончилась: он вплоть до ноября 1946 года участвовал в боевых действиях против милитаристской Японии. Во время службы на флоте он повстречал свою будущую супругу Кашифу. За боевые заслуги был награждён орденом Отечественной войны 2-й степени (1985 г.) и юбилейными медалями ВОВ.

Ахат Мирзин прожил честную и достойную жизнь. Всю свою жизнь он посвятил системе образования. Уже в мирное время Ахат Мирзович работал учителем географии и биологии в Нижнеарбашской школе, до выхода на заслуженный отдых был директором этой школы. Данная школа была открыта как семилетняя в 1934 году, позже в 1959 году она стала восьмилетней. По воспоминаниям учеников, Ахат Мирзович был требовательным и сильным педагогом, старался воспитать в детях только лучшие качества. Большое внимание уделял трудовому воспитанию, организовал мастерские и большой пришкольный участок. За заслуги в системе образования получил звание «Отличник просвещения РСФСР», был награжден медалью ВДНХ за урожай, выращенный на пришкольном участке.

Со своей супругой Кашифой в мире и согласии прожили около семидесяти лет. Воспитали четырех сыновей и дочь. Но и личная жизнь не обошлась без трагедий: дочь умерла в молодости, оставив новорожденного ребенка. Внучку вырастили, поставили на ноги. Даже после выхода на заслуженный отдых Ахат Мирзович вел активную общественную жизнь, был учредителем местной

мусульманской религиозной организации — прихода мечети деревни Нижний Арбаш. Ахат Мирзович умер в возрасте 100 лет, оставив после себя светлую память в душах и сердцах своих учеников.

Таким образом, обобщая нашу статью, можно прийти к следующим выводам: жизнь и трудовая деятельность педагогов-ветеранов по-своему интересна и значима, каждый педагог вложил свой непосильный вклад как в Победу в ВОВ, так и в дело обучения и воспитания подрастающего поколения.

В преддверии празднования 80-летия Победы в Великой Отечественной войне важно ещё раз вспомнить о событиях тех лет и о людях, которые завоевали нам мир.



Мирзин Ахат Мирзович

# ҖИҢҮ ЯУЛАП КАЙТКАН ВЕТЕРАН МӨГАЛЛИМНӘРЕБЕЗ

*Гардисламова Светлана Ринат кызы*
*ДАҺБУ “Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте”*

Бай тарихлы Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте тиздән үзенең 90 еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнә. Шушы дәвер эчендә меңләгән булачак мәдәният хезмәткәрләренә училищебызның мөхтәрәм ветеран-мөгаллимнәре белем биргән. Бөек Җиңүгә 80 ел тулган көннәрдә студентлар белән алар турындагы истәлекләрне барлау,табу, фото-күргәзмәләрне яңарту, музейга яңа экспонатлар туплау буенча күпкырлы эш алып барыла. Сугышка кадәр укыткан һәм аннан соң Алабуга культура –агарту училищесында эшләгән ветеран-мөгаллимнәребез безнең арада күптән юк инде. Әмма Михаил Иванович Машанов,Константин Александрович Кашаев, Ибраһим Салахович Шәрәфетдинов, Галим Сабирович Сабиров, Габдрахман Габдуллович Насыйбуллин, Алексей Ермолаевич Шишмагаев, Анатолий Иванович Бондаренко, Алексей Васильевич Козлов, Анатолий Николаевич Кузнецов, Евгений Туктарович Кобров, Григорий Николаевич Злобнов,Рәшит Мөхәммәтдинович Шакиров, Василий Алексеевич Теренин, Хабра Рахман исемнәре училище тарихында, аларда белем алган укучылары хәтерендә мәңге сакланыр. Бу ветераннарыбыз хакында бик күп язып үтәргә булыр иде, ләкин мин сезне аларның берсе белән генә таныштырып үтәсем килә. Ул 47 ел студентларны баянда уйнау серләренә өйрәткән мөхтәрәм укытучыбыз Рәшит Мөхәммәтдин улы Шакиров.

Революциягә кадәр Менделеевски районында Ушковларның бөтен Рәсәйгә билгеле химия заводы урнашкан урында, Кокшан эшчеләр поселыгында гади хезмәткәр Мөхәммәтдин белән Шәмсебәдәр гаиләсендә өченче бала туа. Аңа Рәшит – туры юлдан баручы дип исем кушалар. Әтисе өздереп гармунда уйный, ә әтисенең сеңлесе Саимә апа гармунда уйнап җырлый да торган була. Шулар йогынтысында Рәшит тә кечкенәдән җыр-моңга, музыкага тартыла. Музыка, гармун серләренә өйрәтүче дә әтисе була, 4 класста укыганда инде ул гармунда җиңел уйный, хромка, тальян кебек уен коралларын буйсындыра. Улының музыкага омтылышын күргән әти кеше улына ничек булса да ярдәм итәсе, табигый сәләтен үстерәсе килгәндер инде. Беркөнне ул таналарын җитәкләп чыгып китә һәм кичкә култык астына ашъяулыкка пөхтәләп төрелгән баян кыстырып кайтып керә дә, өстәлгә куя. Әбиләре бот чабып: “Менә ичмасам, тана өстәл өстенә менеп тә утырды!”, - ди. Әмма бу баянда туйганчы уйнарга гына насыйп булмый Рәшиткә.

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа әле нибары 14 яшь кенә була, сугышның үзенә җибәрмәсәләр дә, тылдагы бөтен авырлык хатын-кыз, карт-коры һәм 13-14 яшьлек яшүсмерләр җилкәсенә төшкәнен һәркем белә. 7 классны да тәмамлатмыйча , аны Менделеевскидагы ФЗОга җибәрәләр. Алар анда сугыштан кайтарылган солдат итекләрен тегеп, чистартып, көнгә 7шәр пар аяк киемен яңадан киярлек хәлгә китереп, норма үтиләр. Бер ел ярым вакытын ул

шунда үткәрә, ә 1944 елда, 17 яше дә тулмаган егетне сугышка озаталар. Товар поездында, 40 градуслы суыкта, бер-берсенә сыенып, тимер мичне сүндермичә, 28 көн һәм төн аларны Ерак Көнчыгышка илтәләр, анда пушкадан атарга өйрәтеп, зенит артеллериясенә билгелиләр. Илебезне япон илбасарларыннан азат иткәннән соң, ул хезмәтен ерак Карелиядә дәвам итә: тайгада полигонда эшли, агач кисә, юл сала. Дошман гаскәрләре тар-мар ителгәннән соң, туган илгә "Японияне җиңгән өчен", "Кореяне азат иткән өчен" һәм "Германияне җиңгән өчен" медальләре булган килеш әйләнеп кайта. Ләкин сугыш сукмагыннан төшү аңа насыйп булмый: Кытай азатлыгы өчен көрәшеп, ул тагын җиде ел утлы сугышта уздыра, моның өчен «Төньяк Кытайны азат итү өчен» медале белән кабат бүләкләнә.

Мыек та чыкмаган, буыннары да ныгымаган көе өеннән чыгып киткән яшүсмер бары тик 10 елдан соң гына,1954 нче елда,инде 27 яшьлек егет булып, дөньяның ачысын-төчесен татып, үлем белән күзгә күз очрашып, медальләр тагып, туган нигезенә кайтып төшә. Авыр эшләрдә эшләп тупасланган бармаклар өйдә көтеп торган баян телләренә кагылу белән язылып, хәтер түрендә сакланган көйләрне уйный башлыйлар. Әтисе улына эшне яисә укуны сайларга куша, шуңа Рәшитнең Казан музыка училищесын сайлавына каршы килми. Әмма фронтовик егетне Казан колач җәеп каршы алмый, тулай торак юк, кайтып йөрергә ерак, гаиләнең ярдәм итәргә мөмкинлеге юк, шуннан ул ныклап уйлый да, Алабугага, культпросвет мәктәбенә укырга керә. К.А.Кашаев классында 4 ел буе баян серләренә өйрәнә, тырыш егетне бик тиз күреп алалар, уку чорында ук ул инде музыка кабинетында лаборант булып эшли, ә укуны тәмамлауга аны шунда ук укытучы итеп калдыралар.

Ә Казанны ул барыбер яулый, 1963-1968 елларда Казан музыка училищесында укып кайта. Аның хезмәт кенәгәсендә ике генә язу – 1952 елда эшкә алынган, ә 1999 елда үз теләге белән лаеклы ялга чыккан. 47 ел Алабуга мәдәният училищесында эшләү дәверендә, аның кул астында кемнәр генә канат ныгытмаган, музыкага гашыйк булмаган?! Табигате белән тыныч, тыйнак бу гади баян укытучысының шәкертләре илебезнең һәм республикабызның төрле почмакларында тырыш хезмәт итәләр, аларның дистәгә якыны инде үзләре остаз, “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исемнәргә лаек, ә ике шәкерте –И.Г.Нургалимов һәм Р.А Рәхмәтуллин – мәдәният училищесының директорлары булып та эшләделәр. Ләкин нинди генә югары постларда эшләп, нинди генә мактаулы исемнәргә генә лаек булмасыннар, алар үзләренең беренче укытучылары – чишмә башы булып торган Рәшит Мөхәммәтдин улы Шакировны онытмыйча, аның төпле киңәшләрен истә тотып, аның исеменә тап төшермәскә тырышып, намуслы хезмәт иттеләр. Ә укытучы өчен укучыларының уңышларын күрү, ишетүдән дә зуррак бәхет, горурлык бар микән!? Бу бит аның да уңышы, аның да казанышы.

Бәхет бер генә яклы була алмый, яраткан эшеңдә сине илһамландырып, көч биреп торучы гомерлек ярың булмаса, бәхет тулы була алмас иде. Ә бу яктан язмыш Рәшит абыйны читләп үтмәгән. Озын кара толымлы, зәңгәр күзле Минзәлә кызы Рәсимәне Рәшит училищеда укыганда күрә. Спектакльләрдә төп

рольләрне уйнап, концертларда моңлы тавышы белән күп егетләрне таң калдыручы бу кызга якын килергә, сүз кушарга аның җөрьәте җитми, эчтән генә сызып йөри. Рәсимә училищеның театр бүлеген бетереп эшкә китә, ә Рәшит Алабугада кала. Әмма яшь егетнең “магниты” шулкадәр көчле булган, ахрысы, бер елдан Рәсимә яңадан Алабугага килә, китапханәчеләр техникумында укый башлый. Менә шунда инде фронтовик егет, укытучы Рәшит кыюланып Рәсимәгә сүз куша, алар сөйләшеп, дуслашып китәләр һәм бу дуслык чын мәхәббәткә әверелеп, яшьләр 1956 елның 1 октябрендә никах укытып, уртак гомер юлларын башлап җибәрәләр.

Менә шушы мәхәббәт җылысында бер-берсенә терәк, киңәшче булып, Йосыф белән Зөләйха төсле, алар 57 ел бергә гомер итәләр. Мәхәббәт җимешләре – ике кызлары Рәйлә белән Резеданың инде үзләренең балалары үсеп җиткән, оныкларының баласы бар. Балаларыңның, онык-оныкчыкларыңның бәхетен, тәүфыйгын күреп, тигез тормышта картаюдан да зуррак бәхет бар микән дөньяда! Алар лаеклы ялга чыккач та бәйрәмнәргә парлап килеп,үзләренең кызыклы хәлләре, укучылары турындагы истәлекләре белән уртаклашып,безне сөендереп китәләр иде. Менә шушындый бәхетле картлык кичереп, онык-оныкчыкларын сөендереп, туганнарына таяныч, укучыларына киңәшче, остаз булып яшәгән Рәшит абый 2014 елның 18енче августында арабыздан китеп барды. Аның пар канаты Рәсимә апаның да арабызда юклыгына тиздән 4 ел тула. Тормыштагы кебек, алар анда да бергә, янәшә яталар.

Данлы еллар ерагайган саен, үткәннәрне онытмасак иде. Үткәннәрдән башка киләчәк юк. Әйдәгез, үзебезнең үткәнебез белән горурланудан туктамыйк, ул чорның каһарман улларына һәм кызларына ихтирамыбызны киметмик. Киләчәк буынга аларның батырлыгы турында күбрәк сөйлик,башка андый канкойгыч сугышлар кабатланмасын иде.

# ИСТОРИЯ ВОЙНЫ - ИСТОРИЯ МОЕЙ СЕМЬИ

*Галиева Наиля Нурисламовна,*
*ГАПОУ «Арский агропромышленный профессиональный колледж», филиал №2*

ХХ столетие стало для человечества важнейшей вехой. Это век великих открытий, кардинально изменивших жизнь людей. Это век значимых событий, которые потрясли весь мир.

Пожалуй, самое судьбоносное, страшное и трагическое событие прошлого столетия для русского человека – Великая Отечественная война. Нет такой семьи в России, которую не затронула война. К каждому в дом постучалась война-разлучница и забрала мужей, отцов, сыновей. Многие так и не вернулись к родным с поля боя…

Моему деду Шакирову Фатиху Шакировичу было еще только 18лет, когда в деревню пришла печальная весть о войне. В июне 1941 года он окончил 10класс Балтасинской СОШ. Несмотря на то, что многие его сверстники были мобилизованы, из-за того, что в деревне не хватало учителей, моего деда оставили работать в семилетней Соснинской школе преподавателем. В марте его призвали в ряды Красной Армии. В сентябре 1942года после прохождения военного обучения мой дед был отправлен на Волховский фронт. Воевал он в батальоне артиллеристов-пулеметчиков. В своих дневниковых записях он подробно описывает военный быт, жестокие бои, тяжелые моменты военных дней. Ему нередко приходилось стать свидетелем гибели боевых товарищей. К тому же его родных три старших брата были мобилизованы в первые же дни войны. Один из братьев Хашим погиб во время ожесточенных боев около Ленинграда. Другой брат Тагир стал участником Сталинградской битвы. Тяжело раненный он попадает в плен немецким фашистам. В течение долгих трех лет ему пришлось испытать все тяготы фашистского плена. Был освобожден лишь в 1945году и долгие годы проработал в одном из челябинских предприятий. Медаль за боевые заслуги в битве за Сталинград вручили спустя много лет после окончания ВОВ. Третий брат моего деда Минсалих участвовал в военных действиях на Дальнем Востоке около Мурманска. В ходе войны был тяжело ранен. Затем долгое время трудился на железных дорогах Мурманска.

Мой дед воевал против немецких захватчиков в течение трех лет. 20 месяцев этого периода прошли в оборонительных боях: в каждую минуту под смертельной опасностью, в напряженной обстановке, без жизненно важных человеческих удобств. Участвовал в освобождении Новгорода и Петрозаводска и был удостоен Благодарственного письма Верховного Главнокомандующего за героизм и отвагу. В декабре 1945 года врачебная комиссия мобилизовала деда из-за полученных многочисленных ранений в ходе войны.

Из войны мой дед вернулся с тремя медалями. По его словам, самая дорогая награда из них – медаль «За отвагу». Из его воспоминаний: «Весной 1943года мы защищали плацдарм от врагов. Немцы атаковали беспрестанно. Мы храбро сражались и сумели выстоять, хотя и ценой больших человеческих потерь. Стало известно, что многие бойцы из нашего взвода будут представлены к

Государственной награде. К сожалению, в этот же день я получил тяжелую контузию и был отправлен в госпиталь. К огромному несчастью, на рассвете почти все мои боевые товарищи погибли в результате неравных боев. В живых остались лишь двое из наших товарищей. Награда «За отвагу» была вручена только им. Во время войны невозможно выпрашивать награду, да и воевали мы не из-за какого-то вознаграждения, а за мирное небо, за то, чтобы остаться в живых и чтобы враг был изгнан из наших земель. Возможно, список представленных к награде где-то потерялся или были еще другие причины, я эту ценную награду получил лишь в конце 1945года. Медали, полученные на войне для меня очень ценные, потому что это память тяжелых военных лет. Мы воевали под лозунгом «хоть умирай, но не сдавай позицию врагу, если сдал, то отвоюй обратно».

Мой дед с душевной теплотой вспоминает те дни, когда он вернулся в родную деревню после демобилизации. После окончания ВОВ, он был отправлен на войну против японских милитаристов и лишь в конце 1945года вернулся в родные края. Его встретили мать и младшая сестра. Их радости не было предела.

Сразу же после возвращения мой дед начинает работать в школе, преподает военное дело. В1949году заочно поступает в КГПИ в 1954 году получает диплом преподавателя истории. Работает сначала завучем, потом директором в разных сельских школах до 1983 года. За заслуги в работе в 1959году был удостоен почетного звания «Заслуженный учитель РСФСР». Вместе с бабушкой воспитали пятерых детей. Всем дали не только хорошее воспитание, но и высшее образование. Его сыновья выполнили свой воинский долг, отслужив в рядах Вооруженных Сил Советского Союза. Среди их детей есть и врачи, инженеры, учителя. Продолжателями династии учителей стали моя мама Фарида, четвертый по счету ребенок в семье (учитель математики) и самый младший сын Ильдус (преподает в КГАСУ).

Я часто оставалась у бабушки и дедушки. Мне с малых лет нравилось гостить у них. После Сабантуя он собирал всех своих внуков и устраивал нам разные конкурсы, игры, одним словом, своего рода малый Сабантуй. Они вели спокойный, размеренный образ жизни. Всегда были чем-то заняты. Дед всегда гордился своими воспитанниками, односельчанами. Призывал нас хорошо учиться, быть человечными. Спустя годы я стала отчетливо понимать, оказывается, мой дед был самым лучшим отцом для своих детей, идеальным мужем для своей жены, заботливым дедушкой для нас – своих десятерых внуков, требовательным и мудрым руководителем для своих коллег, опытным наставником для учеников, уважаемым человеком для односельчан и бесстрашным героем своей страны, который внес достойный вклад в победу над фашистами, одним словом, был примером для подражания.

Уже прошло много лет со дня его смерти. Я часто вспоминаю о нем. Особенно тогда, когда приближается День Победы. Он каждый год с трепетом встречал этот праздник. Дед был счастлив, что ему удалось участвовать в

районном параде в честь 60-летия Великой Победы. К сожалению, больше стать участником таких событий ему не было суждено.

Я счастлива тем, что у меня был такой дед и я с гордостью могу рассказать о нем своим детям, тем, что я являюсь одним из представителей учительской династии Шакировых, продолжаю его дело. И самое примечательное то, что он при жизни позаботился о том, чтобы мы, его дети, внуки, потомки знали о бесстрашном подвиге народа во время ВОВ не понаслышке. На память о себе он оставил нам записанные в толстой тетради личные воспоминания о своей жизни во время войны, о военных буднях простого солдата, о подвиге народа на войне. Эти воспоминания бесценные. Без прошлого не может быть будущего. Знать историю своей страны, историю семьи обязан каждый, наш долг – сохранить историческую память о подвигах участников Великой Отечественной войны, тружениках тыла, в особенности каждый из нас должен знать, какой вклад в победу внесли члены семьи. Моя семья – это тоже история России. Я понимаю, насколько труден был путь к победе, сколько мужества и стойкости требовала от людей война. Надо помнить о тех, кто спас нашу страну, кто вернул нам мир, весну и свободу. Пусть всегда будет над нами чистое мирное небо.

# ЛОБАНОВ СЕМЁН ИВАНОВИЧ, УЧИТЕЛЬ – ВЕТЕРАН ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ

*Спиридонова Надежда Александровна*
*МБОУ «Средне-Кушкетская СОШ им. О.Н. Исаева»*

Он осилил всю тяжесть
Солдатских дорог,
Воевал по-геройски гордо.
*П. Синявский*



Именно таким учителем стал Лобанов Семён Иванович. Родился в 1924 году в деревне Мельничная Баласинского района ТАССР. Его отец, Лобанов Иван Васильевич, был плотником. Мать, Лобанова Мария Петровна, работала в колхозе. Семья была большой: было шестеро детей. Семён был самым старшим из детей. В 1930 году Семён Иванович поступил в первый класс Мельничной начальной школы. С 1934 года продолжил обучение в Ципьинской школе. 1940 году получив аттестат о среднем образовании, поступил в Арское педагогическое училище специальности учителя физики и математики. Через год началась война, но он продолжил обучаться. Сразу же после



окончания педучилища он начинает работать в Мельничной начальной школе. Не успев проработать и месяц в своей родной школе, его переводят в Ципьинскую среднюю общеобразовательную школу. В 1942 году в мае месяце его призывают на войну. С Шеморданского железнодорожного вокзала на поезде он отправляется на фронт. Служит на четвёртом украинском фронте. Сначала прибыл в Киев, а затем уже на южный фронт. Точной информации о том, в какой именно гвардии он служил нет (по воспоминаниям жены- 2-ая гвардейская дивизия). В конце октября в начале ноября 1943 года войска 4-го Украинского фронта, в котором был и Семён, завершили Мелитопольскую операцию (правда, Семен участвовал в ней частично. Так как тогда проходил военную подготовку). Семён участвовал в Никопольской-Криворожской операции, в ходе которой получил ранение. Во взаимодействии с 3-им Украинским фронтом ликвидировали никольский плацдарм противника на Днепре. В ходе Крымской стратегической

операции его дивизия попала в засаду, здесь Семён Иванович получил тяжелое ранение в грудь. Его отправили в военный госпиталь города Баку. Около недели лежал без сознания. «Госпиталь, в котором я лежал, был двухэтажным. На первом этаже лежали солдаты с легкими ранениями, а на втором – с более тяжелыми. Меня поместили во второй этаж, в палату под номером 345, в котором лежало одиннадцать бойцов, хотя она была предназначена только для пятерых. За нами ухаживала медсестра Любочка (вскоре Семен назовет свою дочку ее именем), фамилию уже не помню. У нее были длинные курчавые волосы и добрые глаза. Она, не жалея сил ухаживала за больными, но в сентябре 1943 года она погибла. …из тех одиннадцати ребят, которые лежали в одной палате со мной, вернулись домой лишь только восемь, остальные остались лежать на одесской земле. Выписали меня в декабре, погода тогда моросила, небо было обтянуто тучами. Одели меня в одежду какого-то погибшего солдата, так как другая одежда нужнее была на фронте, и я вернулся в свою родную деревню Мельничную…. », - так он воспоминает о госпитале. Пролежав в госпитали около 6 месяцев, в 1943 году его демобилизовали.

После возвращения с фронта, в 1943 году, он продолжает работать в Ципьинской средней школе (но в связи с ранением выходит на работу лишь в 1944 году). В 1949 году его переводят в Средне-Кушкетскую среднюю общеобразовательную школу. В 1962 году Семён Иванович вновь начинает работать в Ципьинской школе.

За тот период, когда он работал в школе, успел проработать учителем физики, математики, ботаники ( учителей не хватало и учить детей было некому). Но со временем начались проблемы со здоровьем: ранение в грудь не давало покоя никогда.



20 августа 1965 года женится на Халтуриной Надежде Дмитриевне (фамилию мужа она не взяла). Вскоре удочеряют девочку -Любовь. Своих детей у них нет. 1975 года он умирает.



Хотя он и рано ушел из жизни, но сумел прожить ее достойно. Он награжден многими медалями. Лобанов Семен Иванович – «Ветеран труда», «Ветеран Великой Отечественной Войны», участник Великой Отечественной Войны. Награжден медалями: «За отвагу», «За участие в ВОВ», «За трудовое отличие», «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945г.г», и юбилейными медалями.

Он является доблестным учителем и в связи с этим навечно оставил свое имя как в Средне-Кушкетской так и в Ципьинской школе. Его портрет висит на стенде, посвященный людям, которыми гордится школа.

Литература


1. Архивные материалы музея «Даур куара («Голос веков») МБОУ « Средне-Кушкетская СОШ»
2. Материалы семейного авхива
3. https://obd-memorial.ru/html/search.htm?f=Лобанов&n=Семен%20&s=Иванович%20&y=1924&r=&book=1
4. https://foto.pamyat-naroda.ru/?mode=main&find=Лобанов%20Семен%20Иванович%20%201924

# МӘҢГЕЛЕК УТ КЕБЕК ЙӨРӘКЛӘРДӘ ХӘТЕР УТЫ ЯНАР МӘҢГЕГӘ! (СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ, ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫБЫЗ ХӘЛИМОВ КОТДУС АБЫЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК)

*Хамаева Гөлфинә Әзһәр кызы,*
*Минзәлә шәһәре*
*2 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Разведчик истәлекләре**

Ахмеев Илья Афанасьевич родился в селе Батырево Батыревского района Чувашской Республики 10.12.1924 года в семье крестьянина. Когда ему исполнилось 6 лет, умер отец Афанасий Максимович, его мать осталась с 4 детьми. Окончил Бытыревское педучилище. Началась Великая Отечественная война. Он был участником великой отечественной войны. Ему было не полных 18 лет, когда его мобилизировали в 1942 г, после окончания краткосрочных курсов был определен наводчиком противотанкового ружья на Западном фронте. Место службы: 24-я танковая Краснознамённая ордена Суворова бригада 5 тк. . Илья Ахмеев храбро сражался в боях за г.Ржев, где получил контузию. После выздоровления он, уже старший сержант, был назначен командиров взвода разведчиков. В этой должности он участвовал Орловской операции 1943 года. Под его командированием взвод не раз проводил вылазки в тыл врага, добывал ценные сведения, помогал войскам атаковать противника. За подвиг в боях Илья Ахмеев был награжден Орденом Красной Звезды, медалями «За отвагу» и «За боевые заслуги».

В 1944 году наградили Ахмеева И.А. Орденом «Красной звезды».



Рисунок 3 Орден Красной Звезды Ахмеева И.А.

Орден Красной Звезды спас его от смерти. В одном из боев осколок попал в грудь, но отскочил от ордена, сбив с него рубины с двух его лучей». Он получил контузию и левый глаз видел только на 10%.

После демобилизации в 1946 году, окончил Чувашский государственный педагогический институт, физико - математический факультет. Работал учителем математики и физкультуры в Батыревской 8-летней школе. Он проработал в этой школе 27 лет.

Награжден многими Почётными грамотами РОНО, Министерства Просвещения Чувашской республики, спортивными грамотами.

В последствии контузии сказалось на его здоровье, он прожил всего 50 лет.

Илларионов Николай Семенович (13.01.1925-18.08.2002).



Рисунок 4 Илларионов Николай Семенович

Николай Семенович родился в учительской семье13.01.1925 года рождения, родился в Тат Буинске, с 15 марта 1942 года работал в школе Больше – Чеменевской, Первомайского района, неполной средней школе. Место призыва: Шемуршинский РВК, Чувашская АССР, Шемуршинский р-нс 07.01.1943 года. С 13 января 1943 был направлен в Свердловское пехотное училище, курсант Полковской школы 362, ЗСП,33 Муромской бригады, стрелок. Воевал на Западном фронте. В 1945 году служил в Берлине Был назначен командиром автоматным взводом Военный Комендатуры р-на Альтенбург СВФ5.По июль 1948 года находился в войсках Советской красной Армии, уволен в звании младшего лейтенанта. Получил медали: «За боевые заслуги», «За победу над Германией» , «30 лет Советской Армии» Место службы: 93 гв. сп 29 гв. сд 7 гв. ск 10 гв. А ЗапФ29-я гвардейская стрелковая Ельнинская Краснознамённая ордена Суворова.

С 1948 году начинает работать в Отрадной школе, Буинского района Татарской АССР, В 1949 году с отличием, экстерном закончил Тетюшское педагогическое училище, где получил звание учитель начальных классов. Проработал в школе 42 года.

Мне повезло я застала дедушку в живых. Вместе с ним мы ходили в лес по грибы и по ягоды. Он знал наизусть басни Крылова И.А., стихи Лермонтова М.Ю., произведения А.П. Чехова. Играл на аккордеоне, рисовал отменно.

Он рассказал трагическую историю фронта. Их рота попала под обстрел. Его сослуживиц и друг Александр снял сапоги у убитого немца, и когда он их обувал, его застрелили». Это я сейчас понимаю, какого было им 18 -19 летним ребятам, видеть как смерть забирает друзей, близких, боязно, но не смотря на страх они защищали свою Родину !



Рисунок 5 Волков Леонид Пантелеймонович

Волков Леонид Пантелеймонович (20.01.1924-08.03.2002)

(двоюродный дедушка со стороны отца) родился 1924 году в селе Алманчиково, заочно окончил Батыревское педучилище. 20 августа 1942 году получил повестку, Гв. красноармеец, 20.01.1924, Чувашская АССР, Чкаловский р-н, д. Алманчиково, Место службы: 13 гв. сд, Чкаловский РВК, Чувашская АССР, Чкаловский р-н, 39 гв. сп 13 гв. сд 39-я гвардейская мотострелковая Барвенковская ордена Ленина. С 20 августа 1942 года отправлен в пехотное училище в г. Ярославль. С 20 августа 1943 года стал разведчиком и автоматчиком, его награды: Ордена «Красная звезда», «Отечественная война 2 ступени», медали: «За боевые

заслуги», «За победу над Германией», «30 лет Советской Армии», «20,25,30,40,50 лет Победы в Великой Отечественной войне. На войне вёл дневник, где подробно описывает события, которые произошли с ним с 1944 по 1945 годы, этот блокнот храниться в музее села Алманчиково, Чувашской республики.

В 1945 году был направлен в Казанское Танкотехническое училище танкистов (КТТУ). После войны работал в военкомате в звании старшего лейтенанта.

В 1955 году поступил на исторический факультет в Чувашский государственный педагогический институт им. И.Я. Яковлева далее (ЧГПИ).

С 1961 года работает учителем в Батыревской школе, педагогический стаж составил 26 лет.

Каждое поколение семьи берет всё лучшее у своих старших наставников. Педагогическое мастерство передается продолжателям учительского дела. Я надеюсь, что династия педагогов моей родословной не прекратит своё существование.

Моя крестная, Ольга Ильинична Кудряшова (дочь И.А. Ахмеева), а также учитель русского языка и литературы выпустила книгу «Загляните в семейный альбом», где записаны странички из истории трудовой династии учителей семьи.

Рисунок 6 Рисунок 1 QR – code на сайт Учительской династии

Четыре года продолжалась эта война, сколько слёз было пролито, сколько судеб сломано! Более 27 миллионов погибло, будущее поколение не имеет права забывать, какой ценой завоёвана свобода, суверенитет нашей страны. Хочется закончить свою работу словами Ахмеева И.А. «Служил я честно. И в том, что мы отвоевали свободу своей Родины, сберегли мир от фашистской чумы есть и моя заслуга. Пришлось мне воевать на разных участках фронта. Форсировал Днепр, освобождал Украину и Польшу, воевал на территориях Австрии, Германии. Боевой путь завершил в Берлине, на ступеньках Рейхстага»

Список литературы

1. «Загляните в семейный альбом», автор Кудряшова О.И. – г. Чебоксары,2018, - 108с]

2. https://podvignaroda.ru/?#tab=navHome

# ПОМНИМ, ГОРДИМСЯ, ЧТИМ!

*(Директора – ветераны Великой Отечественной войны нашей школы)*

*Работу выполнила: Кашапова Гулфира Хаматовна,*
*учитель родного языка и литературы*

Вся страна проживает год, который стал особым для всего русского народа. Год, несущий важную дату – 80- летие со Дня Победы в Великой Отечественной войне. Менделеевская школа №4 занимает особое место в истории края . Это одна из немногих школ России, которая может гордиться тем, что что шесть её воспитанников стали Героями Советского Союза, участниками Великой Отечественной войны. Это Михаил Фомин, Вилен Бурмистров, Василий Белоусов, Пётр Сафронов, Михаил Суднишников, Василий Пискунов. Один из героев Сафронов Петр Сергеевич, вернувшись с фронта, преподавал уроки физкультуры в нашей школе. В честь Бурмистрова Вилена Ивановича и Фомина Михаила Сергеевича названы улицы нашего города, на которых находятся школы №1 и №4. На Аллее героев увековечена память об их заслугах перед Родиной. Благодаря их мужеству и героизму в 1990 году здание учреждения внесено в реестр исторических памятников Республики Татарстан, а в 15 выпускников школы выполняли интернациональный долг в Афганистане в 1979-1989 годы. А когда началась СВО, наши выпускники тоже не остались на стороне. Они героически сражаются, защищают нашу Родину от врагов.

6 мая 2022 года, в торжественной обстановке отметили важную дату в истории 4-й школы – присвоение ей почетного звания! Согласно Постановления Исполнительного комитета № 230 от 30.03.2022 г. муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа №4» Менделеевского муниципального района Республики Татарстан переименовано в МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4 «Школа мужества и воинской славы» Менделеевского муниципального района Республики Татарстан.

История нашего учебного заведения – это сплав традиций и достижений! История нашей школы по праву считается уникальной!

Пожалуй, не найдешь школы, где бы её учителя (уже бывшие) не были участниками Великой Отечественной войны. Вряд ли найдётся такой участок фронта, такое сражение, где бы ни сражались учителя. Маршал Советского Союза Александр Михайлович Василевский писал: «Учитель и на фронте, в окопах, оставался верен своей профессии - личным примером учил, как надо воевать». Кто же они, учителя-фронтовики? Как сложились их судьбы? Это интереснейшая тема. О каждом из них можно написать книгу, ибо у каждого был свой фронтовой путь, который привёл к общей победе над фашизмом. Такими учителями - директорами может гордиться и наша школа. Даже самим своим присутствием в школе они являли пример служения воинскому и гражданскому долгу.

1) КУЗОВОВ МИХАИЛ ИВАНОВИЧ



Родился 20.10.1923 года в Татарской АССР, Лаишевского района, д. Стрюково. В 1941 году окончил Казанскую специальную среднюю школу ВВС, в 1943 г. Яновскую военную школу авиамехаников ВВС, получив специальность авиамеханика и звание сержанта технической службы. Службу проходил до 1946 года авиамехаником Балашовской военной авиашколы, затем механиком в войсковой части Приморского военного округа. Демобилизован в 1949 году.



После окончания Казанской юридической школы работал следователем прокуратуры, прокурором Бондюжского района. Был избран вторым секретарем Бондюжского районного комитета КПСС, председателем Бондюжского исполкома. Получил заочно высшее юридическое образование, впоследствии окончил историко-филологический факультет Казанского государственного педагогического института. Много лет проработал директором Менделеевской средней школы №4, преподавал историю. Избирался депутатом районного Совета народных депутатов. Капитан запаса.

Награжден медалями «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.», «Ветеран труда», юбилейными.

2)БЕСПАЛОВ АЛЕКСАНДР КУЗЬМИЧ



Родился 25.10.1922 года в рабочем поселке Бондюга. В 1940 году начал работать токарем в ремонтно-механическом цехе химзавода имени Карпова. В армию призван в июле 1941 года.

Воевал на Западном, Брянском, Первом Украинском фронтах, командир огневого взвода дивизии прорыва, лейтенант. Прошел путь от Волоколамска до Дрездена. Был контужен.

Награжден медалью «За отвагу» (1943), «За освобождение Праги», двумя орденами Отечественной войны второй степени (1945, 1985).

Демобилизовался в 1946 году. Работал на химзаводе имени Карпова, затем поступил в Елабужский пединститут. Получив диплом, работал учителем истории, инспектором отдела образования, завучем Менделеевской школы №4, потом директором школы №3. Умер 15.04.2010 года.

3) ЛЫЗЛОВ НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ

Родился в 1923 году в селе Тихие Горы Бондюжского района ТАССР в семье



крестьянина. В 1939-1940 учебном году окончил 9 классов Бондюжской средней школы и поступил счетоводом в Бондюжский райпотребсоюз, где проработал до июля 1941 года.Мобилизован в 1941 году Бондюжским райвоенкоматом. Окончил в 1942 году Оренбургское военное училище. Командир взвода 563-го отдельного танкового батальона Северокавказского фронта. Был ранен. С ноября 1944 года по июль 1947 служил на территории Ирана. Награждён медалью «За оборону Кавказа», юбилейными.



Демобилизовался в 1947 году. Работал в райпотребсоюзе, председателем Тихогорского сельского Совета.

С 1 сентября 1949 года перешел на педагогическую работу. Трудился учителем Тихогорской начальной, Ленинской семилетней школ. С 16 августа 1953 по 7 августа 1958 года возглавлял Кураковскую семилетнюю школу.

Много лет Николай Иванович работал директором Бондюжской школы №4. Заочно окончил Елабужский педагогический институт, филологический факультет. Отличник просвещения.

1 сентября 1977 года вышел на пенсию. Ушел из жизни в 1980 году.

4)БЕЛЯЕВ АЛЕКСАНДР АЛЕКСЕЕВИЧ



Беляев Александр Алексеевич родился в 19 марта 1920 года в селе Тихоново Елабужского района, русский. Отец Алексей Макарович и мать Ксения Назаровна работали в колхозе. После школы окончил Чистопольский педрабфак, учителей русского языка и литературы. С 15 августа 1939 года начал работать учителем в Таринской НСШ Елабужского района.



В сентябре 1940 года был призван в ряды Красной Армии Елабужским РВК. Окончил медицинские курсы. Когда началась война, был санитаром. Член КПСС с 1943 года. Воевал на Забайкальском фронте, капитан. Инвалид II группы. Награжден орденом Отечественной войны II степени, медалями «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг.», «За победу над Японией», юбилейными медалями.



После демобилизации в 1946 году трудовую деятельность начал с заместителя директора училища № 10. Женился в 1946 году на Толоковой Надежде Михайловне, в 1953 году родилась дочь Евгения. Удочерил двух девочек Устюговых Тамару и Валентину.

С августа 1950 года по 1954 год работал учителем русского языка в Бондюжской средней школе. В 1953 окончил Елабужский учительский институт, исторический факультет. С 1954 года назначен директором Бондюжской семилетней школы № 4. С 1961 года - заведующий РОНО. С 1962 – 1968 год директор Бондюжской восьмилетней школы № 3. В 1968 году по состоянию здоровья перешёл в среднюю школу № 1 учителем истории и технологии. Умер в сентябре 2000 года в г.Менделеевске.

В его домашнем архиве Мещеряковой Еленой Юрьевной МБОУ «СОШ № 4» г. Менделеевска, 2 ноября 2013 года были найдены две книги для учительских учебных заведений.

5) БЕЗДЕЛОВ АНАТОЛИЙ НИКОЛАЕВИЧ

Родился 27 мая 1926 года в деревне Старая Шудья Алнашского района Удмуртской АССР, русский. Отец Безделов Николай 27 лет работал учителем.

29 декабря 1943 года мобилизован в Красную Армию Пастуховским РВК города Ижевска. Обучался в школе санинструкторов в городе Горбатов Московского военного округа. С 1944 года воевал в составе 2 гвардейского отдельного инженерно- саперного батальона №72566 «с» Карельского фронта.

Награждён медалью «За боевые заслуги». С 28 декабря 1946 года демобилизован, вернулся в родную деревню. Начал работать в Старо - Шудьинской начальной школе.С 1951 года работал учителем начальных классов Ижёвской семилетней школы Бондюжского района ТАССР. В 1960 году был назначен директором этой школы.В 1963 году заочно закончил ЕГПИ, физмат.29 августа 1969 года переведён завучем в Менделеевскую восьмилетнюю школу № 4. Умер в 1999 году.

80 -летие великой Победы и станет данью уважения всем , кто сражался за Отечество в разные исторические периоды : героям и участником Специальной военной операции нашего времени и подвигам всех наших предков , сражавшихся в разные исторические периоды за Родину. Во славу наших отцов, дедов, прадедов, сокрушивших нацизм! Во славу всех, кто защищает и защищал нашу Родину, всех, кто отдавал и отдает свои силы и жизнь ради мира на земле! Год защитника Отечества – это не просто календарная дата, а символ национального единства и патриотизма. Это выражение глубокой признательности тем, кто защищал и продолжает защищать суверенитет и

безопасность нашей страны. Это год, который напоминает нам о важности исторической памяти и о непреходящей ценности мира, который защищают наши защитники Отечества своей мужественностью и самоотверженностью. И давайте помнить, что Год защитника Отечества и Год 80-летия Победы — это не только события календаря, это целая эпоха, которую мы должны ценить и передавать из поколения в поколение. Мы помним, гордимся, чтим!

Использованная литература


1. Архивные материалы краеведческого музея.
2. ГильмановЗ.И., Айнутдинов А.К. Герои Советского Союза – наши земляки.
3. Книга Памяти.
4. Они ковали Победу (Районный Совет ветеранов войны и труда. Химзавод им. Л.Я. Карпова)
5. Фаттахов Н. Бондюжцы Татарстана.
6. Сайфуллин Х.Ш. Так шли мы к Победе….
7. Яковлева Ф.Г., Мещерякова Е.Ю. Страницы истории Менделеевской школы №4.

# РӘШИТ МОСТАФИН БАТЫРЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК ҮРНӘГЕ

*Закирова Аниса Алмазовна*
*(научный руководитель: Закирова Р.Р.),*
*МБОУ "Гимназия с.Большой Сардек им.К.Ф.Шакирова"*

Рәшит Борһан улы Мостафин (1912–1989) 1912 нче елның 29 нчы февралендә Кукмара авылында (хәзерге Кукмара шәһәре) туа. Аларның гаиләсе 1920 нче елның җәендә Зур Сәрдек авылына күчеп кайта. Аңа Бөек Октябрь революциясе китергән олы шатлыкны, 1921 нче елда булган зур ачлыкны кичерергә, колхозлашу елларында авылда ликбез оештырып укытучы булып эшләргә дә туры килә. Культармеецлар дип йөртәләр аларны ул чакта. 1928 нче елда комсомолга керә. 1932 нче елдан 1939 нчы елга кадәр Кызыл Армиядә хезмәт итә. Иң элек Ерак Көнчыгыш салкыннарында, аннары Урта Азиянең ут кебек кызган һавсында чыныгу ала. Рядовойдан кече лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелә.

1939 нчы елдан Зур Сәрдек мәктәбенә кайтып укытучы булып эшли генә башлый, өстенә яңадан шинель кияргә туры килә: сугыш! Баштарак, бер ай чамасы Казанда солдатларны өйрәтә, аннары шулар белән үк фронтка чыгып китә. Сугышта төрлесен күрергә туры килә. Холм шәһәре тирәсендә солдатларны һөҗүмгә алып барганда, янында гына мина шартлап аяктан ега. Госпитальдә шактый вакыт дәваланганнан соң, яңадан фронтка китә. Сталинград далаларында, Курск дугасында сугышларда була. 1943 нче елның көзеннән башлап совет гаскәрләрен барлык фронтларда да һөҗүмгә күчәләр. 57-армия составында Туган илебезне һәм күп кенә чит илләрне азат итүдә катнаша. Җиңү көнен Венгриядә каршылый.

Бертуганнары, абыйсы Рәүф, сугышның беренче айларыннан ук хәбәрсез югалган. Фәрит абыйсы сугыш алдыннан армиягә алына һәм очучылар мәктәбен тәмамлый. «Исән булсак, хаттан өзмәбез», – дигән хатлары гына килгән. Бу хатлары икесенең дә соңгы хатлары була.

1946 нчы елдан 1972 нче елга кадәр Зур Сәрдек мәктәбендә физика-математика фәннәрен укыта. Сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыклары өчен отставкадагы өлкән лейтенант Рәшит Мостафин "Кызыл Йолдыз", II һәм III дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, күп медальләр белән бүләкләнә. Рәшит абый математика, физика дәресләрен тормыштагы мисалларга бәйләп, ихластан укыта. Ул һәр укучының күңеленә үтеп керерлек итеп аңлатырга омтыла. Рәшит абый Мостафин турында «Хезмәт даны» газетасында Җ.Б.Хөсәеновның «Җуелмаска калган хәтердә» дигән мәкаләсе дә басылып чыккан.

Рәшит Мостафин бик кечкенәдән үк төрле техника һәм җайланмалар белән кызыксына, аларны ясый, өйрәнә. 1925 нче елда авылда беренчеләрдән булып детекторлы радиоалгыч кора. «Радио баганасына этием ат бәйләгәч, багана ауган, Рәшит тәгәри-тәгәри елады», – дип искә ала авылдашлары. Сугыштан җиңүче булып кайтса да, табигате белән җимерергә түгел, төзергә ярата ул. Иң беренчеләрдән булып үзе эшләгән акчасына велосипед сатып ала. Сугышка

кадәр үк, бу төбәктә беренче булып, Ковров шәһәрендә эшләнгән мотоциклны ул иярли.

Сугыштан соң батарея белән эшли торган «Искра» радиоалгычы бары Рәшит абыйларда гына була. Авылда беренче электр лампочкасы Рәшит абый өен яктырткан. Лампочканы туендыручы аккумулятор батареяларына токны 6 метр биеклеккә беркетелгән җил чарыгы әйләндерә торган динамо биргән. Шулай итеп, ул 50 нче еллар башында ук өен электрлаштырган. Табигатькә зыянсыз иң чиста энергиядән файдаланып күрсәткән. Авылда беренче булып мунчага душ, такта шомарту җайланмасын кора, өен дә агачны экономияләп төзегән. Безнең як агач эше осталарының өй салганда агачны экономияле тотулары Рәшит абыйдан килә булса кирәк. Чөнки авылымдагы балта осталарының күбесе Рәшит абый шәкертләре. Ул пенсиягә чыкканчы мәктәптә математика һәм физика фәннәрен укыта. Бик күп өлкән кешеләр аның дәресләрен сагынып искә алалар. Һәр эшне төптән уйлап эшләүче, үз тәҗрибәсе белән теләп уртаклашучы, ярдәмчел, эзләнүчән, тырыш кеше була ул.

Рәшит абый су көче әйләндерә торган роторлы электр станциясе кору өстендә эшли, күптөрле вариантларны сынап караган . Буш яткан тау битендә менә дигән алма бакчасы үстерә. Пенсиягә чыккач та тик тормый. Авылда беренче булып полиэтилен пленкалы зур теплица корып, кыяр үстереп күрсәтә. Авылда беренчеләрдән булып «Җигули» машинасы ала. Кышкы салкын буранда да, язгы-көзге пычракта да кайтырга-китәргә транспорт көтеп тилмерүче җәяүлеләрнең ышанычы булган ул. Колхозның ветераннар советы рәисе итеп сайланган.

Рәшит Мостафин  татар әдәбиятын да ярата. Г.Тукай шигырьләренең күбесен яттан белә. Әдәби китапларны күп укыган. Үзенең командиры булган күренекле фронтовик-язучы Вергасов һәм башка фронтташ дуслары белән хатлар алышып яшәгән. Шашка уенын яратып һәм оста уйный. Колхоз, район беренчелегенә уздырылган күп кенә ярышларның җиңүчесе булган.

Рәшит Мостафинның тормыш иптәше Минһаҗева Асыл Минһаҗ кызы педагогик эшчәнлеген Кукмарада башлап җибәрә. Казан укытучылар әзерләү институтын тәмамлый. 1937 нче елдан Зур Сәрдек мәктәбендә эшли башлый. 1972 нче елга кадәр, пенсиягә чыкканчы, шунда балаларга татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирә. Рәшит абый һәм Асыл апаның балалары Розалия белән Рафаэль эти-әниләре һөнәрен сайлаганнар. Суфия исә КДМИны тәмамлап табибә булып эшли.

Батырлыкның гомере озын аның. Һәм ул буыннан-буынга тапшырылырга тиеш. Тыныч тормыш өчен көрәшкән батырларның даны мәңге яшәсен!



Рәшит Борһан улы Мостафин (1912–1989)




*Ветераннар алдында җитәкчеләр чыгыш ясый*

Бөек Җиңүнең 40 еллыгы – 1985 ел. Бу көнне Зур Сәрдек авыл башындагы бушлыкка агачлар утыртылып, Җиңү паркы ясалган. Һәр агачка кайтмый калганнарның исемнәре язылган биркалар тагыла. Уңнан беренче: Рәшит Мостафин.

# ТОРМЫШНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕП ЯШӘР ИДЕК

*Ф.Г.Комиссарова , Данилова З.С.,югары квалификацияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары,*
*Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы*
*«Полилингваль белем бирү комплексы «Адымнар - Алабуга»*
*гомуми муниципаль автономияле белем учреждениесе.*

Сугышта булып арыслан,
Ватанга җиңү яулаган!

2025 ел Россиядә Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде.“Без Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Шуңа бәйле рәвештә 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә тәкъдим итәм. Безнең геройлар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм Ватаныбыз өчен төрле тарихи чорларда сугышкан ата-бабаларыбызның батырлыклары истәлегенә. Нацизмны җиңгән әтиләребез, бабаларыбыз, бабаларыбыз даны өчен" Владимир Путин.

Тарих...Чал тарих битләрен заман җилләре актара. Һәр халыкның авыр һәм гаять бормалы, адаштыргыч юллар белән чуарланган үткәне бар. Шушы үткән гасырлар эчендә күпме кайгы-шатлыгы, күз яшьләре, дәһшәтле сугышлар, гүзәл йолалар яшеренеп яталар. Шул чорда күпме шәһәр – авыллар яшәгәндер, елгаларда сулар аккандыр. Аларны хәзер тарих битләрендә генә очратырга була, ләкин бик сирәк. Аларның да үзләренә күрә ятышлы, җанга якын исемнәре, шул чор кешеләре кушкан атамалары булгандыр. Юкка гына:”Географик атамаларда - чал тарих эзләре, исемнәрдә – ил хәтере, ил тарихы, аның тарихи үткәннәре, хәзергесе һәм киләчәге”,-дип әйтмәгәннәр. Бүгенге эшләребезне, тормышыбызны аңлау һәм дөрес бәя бирү өчен үткәннәрне онытмау, тарихыбыз, халкыбызның әдәби һәм мәдәни тормышы белән кызыксыну бүгенге көндә бик тә әһәмиятле. “Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән милләт үзенең үткән көннәрен белсен һәм үз тарихы белән дус яшәсен”- дип әйтеп калдырганнар борынгылар. Бүгенге катлаулы заманда милли үзаңны үстерү максатыннан тарихка кат – кат әйләнеп кайтабыз.Тарих ул – хәтер. Хәтер…Бары тик кешеләргә генә хас изге хис. Ул безнең аңыбызда мәңге яши. Хәтер югалса, яшәешнең бөтен мәгънәсе югала. Тарихын белмәгән яки аны бөтенләй оныткан халык юкка чыгачак.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм канкойгыч 1418 көне һәм төне кешелек хәтереннән мәңге чыкмас.Бу көрәштә илебезнең миллионлаган намуслы һәм батыр ул-кызлары җирдә тынычлык һәм бәхет өчен гомерләрен бирделәр,шуның аркылы алар үлемсезлеккә атлады. Бөек Ватан сугышы елларында татар шагыйрьләре, Советлар Союзының барлык әдипләре белән бергә, немец басып алучыларына каршы көрәште, кулларына корал тотып та, каләмнәре белән дә актив катнашты, явыз дошманны Ватаныбыздан куып чыгаруда батырлыклар күрсәтте.

Безнең сүзебез Алабуга педагогия училищесында һәм китапханә техникумында тел-әдәбият укытучысы, шагыйрь,Алабуга район газетасының редакторы булып эшләгән Хәбра Рахман турында барачак.Мәшһүр шагыйребез

Сибгат Хәким: “Әгәр дә Хәбра исән булса, татар әдәбиятына бик күпне биргән булыр иде,” – дип язып калдырган.Ул яшьли, иҗады чәчәк ата башлаган чорда, ил азатлыгын яклап, батырларча корбан була. Х.Рахман иҗатын танытуда, аның данлы исемен әдәбият дөньясына кайтаруда Алабуганың танылган язучысы, шагыйрәсе Дибәҗә Каюмова күп көч куя.Ул 1997 елда батыр йөрәкле әдип турында «Өзелгән шомырт чәчәкләре» исемле автобиографик повестен яза. “Әсәрне тудыруда, дөньяга чыгаруда Д. Каюмовага күп эшләргә, күп кешеләр белән очрашырга, шагыйрьнең тормыш иптәше Сара апа белән хатлар алышырга, архивларда эзләнергә туры килә. Нәтиҗәдә автор, вакыйгаларны үз йөрәге аша үткәреп, ижат хыялы белән бергә кушып, тормыш юлы 28 яшендә өзелгән яшь шагыйрьнең жанлы образын тудыра” Әсәрдәге вакыйгалар документаль-биографик материалга нигезләнгән. Вакытлыча югалып калган шагыйрь Хәбра Рахман кем ул? Нинди тормыш юлын үткән, үзеннән соң җирдә нинди эз калдырган? Гомере вакытсыз киселгән яшь шагыйрьнең ижади кыйбласы нидән гыйбарәт? Д.Каюмова үзенең әсәрендә шушы һәм башка күп кенә сорауларга ачык һәм тулы җавап бирә. Рахманның һәм аның студент дусларының тормышы, шагыйрьнең студент дусларына карата булган ихлас мөнәсәбәте, аларның уку елларындагы вакыйгалар агышы повестьта шактый тулы тасвирлана. Бездә Рахманның фронттан гаиләсенә язган хатлары зур кызыксыну уятты.

Хатлар, хатлар... Өчпочмаклы, ак, зәңгәр яки ал конвертлы, читенә кыр почтасының тәртип саны куелган, штемпель сугылган хатлар. Алар бит бөтенләй башкача итеп төрелгән, конвертка да салынмаган өчпомаклы хатлар. Күз алдыгызга китерегез:кыска гына ял вакытында солдат окопта кәгазен тез башына куеп, хат яза. Дошманга булган ачы нәфрәте дә, Туган илгә булган көчле мәхәббәте дә, сугыш авырлыгы, яраларның сызлавы, иптәшләрнең һәлак булу кайгысы- барысы да шушы хатка сыеп беткән. Бу кечкенә генә кәгазьдә дошманны чигендереп алган шәһәрләр һәм авыллар турында да сөйләнә. Солдат язылып беткән хатын бик пөхтәләп, өчпочмаклап төрә, адресын яза һәм кыр почтасына илтеп сала. Шулай итеп, иң изге теләкләрен әйтеп, гаиләсенә сәлам хаты җибәрә.Менә шуларның берсе...

“...Дошманның корал һәм сан ягыннан күпкә өстен көчләренә каршы сугышлар барды, хат язарга мөмкинчелегем булмады. Хәзер вакытым бар. Яраландым, госпитальдә ятам. Перевязкалардан башка вакытта аяк бөтенләй авыртмый диярлек. Госпиталь фронт тирәсендәге бер авылга урнашкан. Кечкенә госпиталь булса да врачлар тәжрибәле, әйбәт врачлар. Уход яхшы. Тамак яклары да әйбәт. Ләкин мин монда озак ятарга тиеш түге, мине фронт көтә.. Хәзер таза булу үзе зур эш. Сара! Минем Алабугадан киткәнгә озакламый ярты ел тула. Мин элегә кадәр, Ходайга шөкер дигәндәй, әле һаман да исән. Кем белә, бәлки, синең белән Рафаэль бәхетеннән, туганнар бәхетеннән яки үз бәхетемнән исән-сау сезнең ян га да кайтырга язгандыр. Шулай булса, билгеле, бик яхшы булыр иде. Ул вакытта без синең белән тормышның кадерен белеп яшәр идек. Әгәр ул көннәр насыйп булса, мин ярлыларга, ятимнәргә кулдан килгән ярдәмемне кызганмас идем. Аларга яхшылыклар кылырга тырышыр идем.

Сара! Син үзең ничек тормыш итәсең? Бик авыр түгелме, Рафаэль зур булдымы инде? Сөйләшәме? Аның сәламәтлеге ничек? Мөнәвәрә ничек эшләп ята? Аның тормышы ничек? Ул үзенә аерым хат язмаганга ачуланмасын. Монда кәгазь табулары бик читен (бу кәгазьне дә случайно кулга төшердем) Мәрьям апалар ничек торалар? Гомумән, шәһәрдә, педучилищеда, редакциядә нинди яңалыклар бар? Быел уңыш ничек булды? Барын да әйтеп хат яз. Хатны шул иске адрес белән яз. 1482-ая полевая почта, часть 485.Элекке хатлардан карап яз (соңгы икесеннән), чөнки синнән бу хатка җавап килгәндә мин инде шул үзем хезмәт иткән частьта булырмын.Хәзергә шушының белән тәмамлыйм. Исән-сау булып, синең белән, Рафаэль белән, туганнар белән, дус-ишләр белән яңадан күрешү һәм татулык, тынычлык, туклык белән бергә-бергә гомер итү көннәрен түземсезлек белән көтеп калам.Сәлам белән Хабра.28 октябрь 1942 ел.

Әйе, фронт сызыгыннан язган хатларында гади солдат Хәбраның туган ягын өзелеп сагынуы да, дошманга нәфрәте дә ачык чагыла, гаиләсенә, туганнарына , авыл өлкәннәренә хөрмәте, ышанычы да күренә. Сугышчылар, исән-имин кайтуларына ышанып, Җиңүгә өмет итеп, батырларча сугыша.

«Безне фашистларның ныгытмаларына каршы һөҗүмгә җибәрәләр. Иртәгә таңда һөҗүмгә ташланабыз. Исән калсам балам бәхетеннән, баш салырга туры килсә, бәхил булыгыз!»—дип язган иде соңгы хатында. Бу хатын Сара октябрь ахырында алды. Кулны көйдерә торган бу кыска хатны ул никтер бик сирәк укый, сирәк кулга ала. Аны укыган саен ул аңлый, Хабра үзен аямаячак, утның ялкынына ыргылачак. Шуңа күрә җанын өзгәләмәс өчен бу юлы да ул соңгы хатны укымады. Инде бер айдан артык бернинди дә хат-хәбәр юк. Ул ни уйларга, үзен кая куярга белми.

Сара мичне томалап, бәрәңге боламыгын суынмасын дип каплап өстәлгә куйды. Рафаэль инде уянырга җыена, киерелгәли, сузылгалап ала. Тик күзен ача алмый. Бераздан ул да уяначак. Икәүләп тәмләп майлы боламык ашарлар.

Шулчак ишек шакып авыр сумкасын иңенә аскан почтальон хатын килеп керде. Ул никтер Сара Ибневна дип дәшмәде, карлы аягына карап, бер урында бераз таптанып алды. Хат китерүче хатын кулындагы хат кисәген сузарга ашыкмады, башын аска иеп басып торуын дәвам итте.Өчпочмаклы гәҗит битенә кеше кулы белән язылган шомлы хат иде бу...

”...Иргезне 14 ноябрьдә станциядән ерак түгел поселок каберенә җирләдек”

Хәбра Рахманның туган ягына кайту турындагы уйлары хыялда гына кала.Кызганычка каршы, ул Мәскәү янындагы каты сугышларның берсендә авыр яраланып, шул ярадан савыга алмыйча, 1942 елның ноябрендә вафат була. Аның гәүдәсе Калинин өлкәсенең Максатиха дигән тимер юл станциясендә күмелә, ят җирләрдә мәңгелеккә ятып кала. Хәбра Рахманның тормышны, матурлыкны сөя торган олы җанлы кеше булуы һәрбер хатыннан күренә. Хабраның хатларындагы Сара өчен гомерлек васыять булып яңгырарлык сүзләре генә кала. Рафаэльны сакла!Ярлыларга,ятимнәргә кулдан килгәнчә ярдәм ит!Тормышның кадерен белеп яшә!

Сара гомере буе ирен оныта алмый. Аның хатларын, кулъязмаларын, бердәнбер китабын кулына алып, шулар белән үзенә юаныч таба.

Әйе, бу сугыш илебезгә күпме кайгы-хәсрәт, күпме күз яше китереп, күпме сабыйны ятим калдырды, бәхеттән мәхрүм итте. Шулай булуга карамастан, Ватанга булган мәхәббәт, тыныч, бәхетле киләчәккә ышаныч барысыннан да көчле булып, Бөек Җиңүгә китерде. Хәбра Рахман яшь килеш шаһит булып,якты дөньядан киткән. Ләкин аның әле үсмерләрчә беркатлы, эчкерсез, самими шигырьләре яши, алар безнең белән. Якташлары аны онытмый. Хәбра Рахман турындагы истәлекләрне Яңгул авылы халкы кадерләп саклый. Авыл мәктәбе музеенда аның тормышы һәм иҗаты турында күп мәгълүмат тупланган.Казанның Матбугат йортында Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучылар истәлегенә куелган мемориаль такта бар,анда алтын хәрефләр белән язучы-солдат Хәбра Рахман исеме дә язылган.

Бүгенге көндә күп кенә милләт өчен янып йөргән җирле язучыларыбыз иҗатлары тиешенчә тикшерү, ачу, анализлау көтеп ятадыр. Аларны дөньяга чыгару, халыкка таныту - бурыч. Алар үзләренең кабатланмас иҗатлары, куйган хезмәтләре белән тормышыбызны матурлый, күңелләребезне сафландыра,тәрбияли, ата – бабаларыбызның мирасын саклауга зур өлеш кертәләр. Безнең язманы менә хәзер, Бөек Җиңүнең 80 еллыгын каршыларга әзерләнгәндә, татар теле дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда, ветераннар белән очрашуларда кулланырга тәкъдим итәбез.

Кулланылган әдәбият исемлеге.

1.Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986.-635б.

2.Каюмова Д.,Шәехов Ф.,Әхтәмова.Г.Чулман язлары. -Алабуга нәшрияты ,1997.- 84б.

3.Каюмова Д.Өзелгән шомырт чәчәкләре.-Алабуга,1997.-91 б.

4.Лаисов Н.Х.Татар язучылары Алабугада: Монография. Алабуга, АДПУ нәшрияты, 2008.-152б.

# У ВОЙНЫ НЕ ЖЕНСКОЕ ЛИЦО…

*Мифтахова Зульфия Фарисовна,*
*Салимова Гульшат Инсафовна,*
*МБОУ "Николаевская ООШ им. С.А. Кузнецова"*

Говорят, что у войны не женское лицо,
Что женщине не нужно воевать.
Пусть она красивая и хрупкая,
Будет просто женщина и мать,
Свой очаг хранящая голубкою.



Борисова (Советникова) Евдокия Михайловна родилась 1 января 1924 года. Евдокия Михайловна ушла добровольцем по путевки комсомола на Великую Отечественную войну 11 ноября 1942 года, со второго курса Мензелинского педагогического училища. С 11ноября 1942 по 24 марта 1943 г. в г. Казани прошла подготовку для работы на ПУАЗО – прибористом (прибор управления артиллерийским зенитным огнем), засекала и передавала цели по самолётам и передавала зенитчикам, выставляла угол наклона, т.е. координаты для сбивания самолётов противника. Во время учёбы охраняла пороховой завод в г. Казани. 25 марта 1943 года 379-й ОЗАД (Отдельного зенитно – артиллерийского дивизиона) взял курс на Запад. Евдокия Михайловна участвовала в освобождении захваченных населённых пунктов, сначала в г. Щигры Курской области, с 30 августа ст. Готняч Сумской области, освобождали Черниговскую область.

За успешную противовоздушную оборону коммуникаций Центрального фронта солдатам, сержантам и офицерам 379–го ОЗАД командующим Центральным Фронтом генералом Рокоссовским К.К. была объявлена благодарность и вручена медаль «За боевые заслуги».

Фронтовые дороги вели на запад в Румынию, Венгрию. 2 марта 1945 г. освободили Румынию, а затем и Венгрию ст. Ботажек. С 1 апреля 1944 входили в состав Южного фронта. На фронте Евдокия Михайловна выпускала и оформляла стенгазету «Новости с фронта».

Демобилизовалась из рядов советской армии в августе 1945 г., на основании Закона Верховного Совета СССР от 23 июля 1945 г.

Борисова Евдокия Михайловна награждена медалями «За взятии и освобождение Румынии», *«Праги», «Венгрии»*, «За победу над Германией», юбилейными медалями.

После окончания ВОв продолжила обучения в Мензелинском педучилище, а в 1947 г. поступила очно в Казанский педагогический институт, на факультет филологии. Окончив институт в 1952 г. 2 года работала в Новочеркасске, затем проработала завучем и преподавателем русского языка и литературы в "Совхозской СОШ" Мензелинского района РТ. В 1972 г. ушла на заслуженный отдых.

Борисова Евдокия Михайловна умерла 21 июня 2004 года. Её подруга- Баязитова Асия Фахразиевна написала книгу «Зенитчицы Татарстана: воспоминания автора и её однополчанок из 379-го Отд. Зетин. Арт. Дивизиона о своей юности в шинелях. ...», Казань,2010г.



Бель Зоя Григорьевна родилась 1 ноября 1923 года. С 1942 по 1945 г. была в действующей армии. Весной 1942 г. комсомолки были призваны на защиту своего отечества, среди них была и Зоя Григорьевна. В Москве прошла 3-х месячные курсы обучения «Воздушное наблюдение и оповещение связи». Они защищали столицу от фашистских стервятников с воздуха: сообщали марку самолёта, направление, высоту и его цель на центральный пост, по указанию которого поднимались наши самолёты в небо или била артиллерия.

После войны Зоя Григорьевна стала работать в Ульяновской области в школе учителем начальных классов. Затем переехала в Мензелинский район в совхоз имени Воровского. Здесь работала в "Совхозской СОШ" Мензелинского района РТ учителем начальных классов.

Бель Зоя Григорьевна награждена медалями «За оборону Москвы», «За победу над Германией", "20лет Победы","30лет Победы".

# У ВОЙНЫ НЕ ЖЕНСКОЕ ЛИЦО…

*Мубаракова Роза Равилевна,*
*МБОУ "Гимназия с.Большой Сардек им.К.Ф.Шакирова"*



Галиева Мансура Галиевна (1921 - 2004) – ветеран войны и труда. Родилась 12 августа 1921 года в деревне Арпаяз Кукморского района в семье крестьянина-середняка. В 1937 году окончила 7 классов и поступила в Чистопольское педагогическое училище. Трудовую деятельность начал в 1939 году учителем Асан-Елгинской начальной школы. В 1940-1941 учебном году была переведена в Таишевскую школу учителем начальных классов.

Все складывалось хорошо: молодость, любимая работа. Девушка жила и радовалась жизни... но вот война ураганом ворвалась в мирную жизнь людей, искалечила многие судьбы. Так трудовая деятельность Мансура апа была прервана войной, и к ее биографии стала прилагаться фронтовая летопись. Военные годы были очень тяжелыми.

Служила рядовым красноармейцем в медсанбате 43-й команды 186-го запасного полка на Смоленском фронте. На фронт привозили раненых. Их принимали, перевязывали раны, кормили и отправляли в городской госпиталь. За хорошую работу в октябре того же года Мансуре апа было приказано работать медсестрой в 32-й бригаде. Смоляные леса очень густые. Полевой госпиталь был сильно замаскирован. И днем, и ночью немецкие самолеты непрерывно бомбили. Сначала они очень боялись, а потом привыкли.Фронт был близок: с одной стороны – 15 км, с другой – 19 км. Мужчины выезжали на разведку в города и села, где располагались немцы. Они захватывали "язык", взрывали мосты, по которым ходят немцы, сжигали деревни и возвратились живыми. Немцы бомбили деревни и города и начали отступать. 7 ноября 1943 года пришлось идти в разведку, где была ранена. Ее отправили в Рязанский госпиталь. Вернулась с войны 26 декабря 1943 года. Через два месяца после возвращения из военкомата пришло известие, чтобы она снова отправилась на войну, но по семейным обстоятельствам не пошла.



Вернувшись с войны, Мансура апа продолжила преподавательскую работу. Несколько месяцев работала директором и учителем в Арпаязе, 10 лет - в Таишево, Асан-Елге, 30 лет - в Адаевской начальной школе. Проработав 40 лет преподавателем, в 1979 году вышла на пенсию. Ее заслуга в организации учебно-воспитательной работы была велика.

Активно участвовал в общественной работе, много лет работала агитатором, секретарем бригадной организации.



КОМИТЕТ
ПО ПОДГОТОВКЕ И ПРОВЕДЕНИЮ
ПРАЗДНОВАНИЯ
55-Й ГОДОВЩИНЫ ПОБЕДЫ
В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ
1941-1945 ГОДОВ

Галеева
Мансура
Галеевна
РОССИЙСКИМ
ОРГАНИЗАЦИОННЫМ КОМИТЕТОМ
вручается знак
"ФРОНТОВИК
1941-1945"

ТАНЫКЛЫК

Галеева
Мансура
Гали кызы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ исеменнән 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлек билгесе белән бүләкләнде.

Шәһәр, район
администрациясе Башлыгы

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Галеева
Мансура
Галеевна

от имени ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН награжден памятным знаком Республики Татарстан в честь 55-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.

Глава администрации
города, района .......... (подпись)

«1» мая 2000г.

За участие в Великой Отечественной войне награжден медалями "За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.", к 20, 25, 30, 40, 50-летию Победы, медалью "Ветеран труда". В 2000 году награжден знаком "Фронтовик 1941-1945".

Где бы она ни работала, Мансура апа пользовалась уважением учеников и родителей, сельчан. Справедливая, честная, старательная, она являлась примером для подражания своим коллегам.

Вместе с супругом-ветераном Великой Отечественной войны Хазиахметовым Гильмухамметом Хазиахметовичем прожили 54 года, вырастили 3 дочерей и 1 сына.






Ветеран войны и труда, учитель Мансура апа умерла в 2004 году. Остались светлое имя, добрые дела Учителя, который воспитал столько поколений детей.

# УКЫТУЧЫ- БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ

*Закиров Нурислам Рамил улы*
*(җитәкче: Галиева Гөлсәрия Өлфәт кызы),*
*"Тауасты Байлар төп гомуми белем мәктәбе" ГБМБУ,*
*8 нче сыйныф укучысы*

Бөек Ватан сугышы тәмамланган көннән соң 80 ел узып та киткән. Еллар безне онытырга хакыбыз булмаган коточкыч көннәрдән ерагайта. Ул сугышның шаһитлары торган саен азрак кала бара.

Сугыш... Шундый кыска һәм гади сүз кебек тоелса да, күпме хәсрәт, кайгы, күз яшьләре һәм үлем китерә. 1941нче елның 22 нче июне күпләр өчен бәйрәм була. Мәктәпләрдә чыгарылыш кичәләре үтә... Нәкъ шул көнне иртән иртүк фашист Алмания гаскәрләре Советлар Союзына һөҗүм итә. Илебез өчен иң куркыныч, канкойгыч сынау башлана. Сугыш җиле какмаган бер генә гаилә, бер генә йорт та калмый.

Авыр сынау елларында халкыбыз барысын да кичерә. Ир-атлар, яшь егетләр фронтка китә. Хатын-кызлар, картлар һәм балалар иген кырларында, завод-фабрикаларда эшлиләр, фронт өчен икмәк үстерәләр, хәрби техника өчен детальләр, корал һәм башка кирәкле әйберләр ясыйлар. Эш туктаусыз дәвам итә, кешеләр станок янында тәүлегенә 12, хәтта 14 сәгать торалар, һәм һәркем җиңүгә үз өлешен кертергә омтыла. Авыр вакытларда безнең халык бердәм була, хәтта этләр дә яралы солдатларны коткарырга ярдәм итә.

Кечәге укучылар шунда ук фронтка язылалар, яшь кызлар һәм егетләр үз теләкләре белән Ватанны сакларга китә.

Язмам Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, хөрмәтле укытучы Мосабиров Мирсәяф абый турында.

Мосабиров Мирсәяф (Мирсәй) Мосабир улы 1925 нче елның 8нче февралендә Актаныш районы Байсар авылында туа. Байсар мәктәбендә белем ала. Җидееллык мәктәп укучысы буларак, Калинин районы Илтимер башлангыч мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп билгеләнә.

Мирсәяф абый, 18 яше тулу белән, фронтка җибәрүләрен үтенеп, хәрби комиссариатка гариза яза. Кызыл Армия сафларына 1943нче елның 8 нче гыйнварында алына ул. Өченче Белоруссия фронтында хезмәт итә. Үз-үзен аямыйча көрәшүче кыю егет өч тапкыр яралана. Хәтта туганнары аның үлеме турында кәгазь дә ала. Мирсаяф абыйны, яшь булуына карамастан, 552 нче укчы полкның укчы отделениесе командиры итеп билгелиләр. Яраланганнан соң 421нче армия госпиталендә дәвалана. Сәламәтлеге ныгыгач, 711 нче укчы полкында отделение командиры булып хезмәт итә. Икенче тапкыр яраланганнан соң 2404 нче эвакогоспитальдә дәвалана. Гыйнварда 120 нче санинструкторлар мәктәбенә укырга җибәрелә. Укудан соң 34 нче Түбән сапёр батальонының, соңрак 148 нче гвардия укчы полкының санинструкторы була. "Сугыш елларында меңнәрчә кешенең гомерен саклап калдым!" - дип горурланып сөйли ул.

Бары тик 1950 нче елның апрелендә генә демобилизацияләнә. Туган ил азатлыгы өчен күрсәткән сугышчан казанышлары, тиңдәшсез батырлыклары

өчен Мирсәяф Мосабиров «II дәрәҗә Ватан сугышы» ордены, «Жуков ордены», «Батырлык өчен», «Германияне Җиңгән өчен» медальләре һәм күп кенә юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Сугыштан соңгы елларда Актаныш районы Пучы урта мәктәбендә физика, математика фәннәрен укыта. Минаева Мофаваза исемле укытучы кыз белән гаилә кора, өч кыз, ике ул үстерәләр.

1979 нчы елда Минзәлә районы Тауасты Байлар сигезьеллык мәктәбенә нигез салынгач, Мирсәяф Мосабир улын директор итеп билгелиләр. 192 балага исәпләнгән Тауасты Байлар мәктәбен төзүне оештыра ул һәм 1986 нчы елга кадәр мәктәп җитәкли, математика фәне укыта.

Тауасты Байлар авыл халкы, ата-аналар, укучылар бик хөрмәтли аны һәм, якын итеп, “директор абый” дип эндәшә.

Мосабиров Мирсәяф Мосабир улы авыр, шул ук вакытта мактаулы тормыш юлы үтә. Ул бик күп балаларга белем һәм тәрбия бирә. Күпләргә ул туган җиргә, туган якка риясыз мәхәббәт хисе тәрбияли. Ул үзенең оптимизмы һәм зирәклеге белән укучылар өчен игелеклелек һәм тормыш сөючәнлек үрнәге була. Ә иң мөһиме – Мирсәяф абый авылның үз кешесенә әйләнә. Бүген дә аны укучылары хәтерлиләр, онытмыйлар, игелекле эшләре һәм рәхмәт белән искә алалар.

Кушымта.







Фотоларда:

1. Сугыш һәм хезмәт ветераны Мосабиров Мирсаяф Мосабир улы
2. Мирсаяф абый тормыш иптәше Мофаваза белән
3. Мирсаяф абый тормыш иптәше Мофаваза апа һәм кызы белән

# УКЫТУЧЫБЫЗ – СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ!

*Борһанова Гөлназ Шәйхенур кызы,*
*Менделеевск шәһәре 4 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Мин Менделеевск шәһәренең 4нче“Каһарманлык һәм хәрби дан” мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим. Мәктәп стендында фоторәсемнәр бар. Аннан миңа япь- яшь егетләр карап торалар, әйтерсең лә мине сәламләп елмаялар. Алар- мәктәбебезнең горурлыгы булган укучылар, Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырлар-Советлар Союзы Геройлары. Алар да бу мәктәптә белем алганнар , коридорлар буйлап йөгергәннәр, көлгәннәр, шаярганнар. Сыйныф бүлмәләре, мәктәп стеналары әле дә аларны сагыналар шикелле. Чыннан да, мин укыта торган 4 нче мәктәпнең үткәне бай тарихлы, истәлекле, данлы. Безнең мәктәбебез - Россия Федерациясендә 6(!) Советлар Союзы Герое  тәрбияләп үстергән бердәнбер мәктәп бит ул! Ничек инде аның белән горурланмыйсың?!

Безнең мәктәпнең якты тарихы- Ватанга мәхәббәт хисе, аның тарихы, мәдәнияте, казанышлары белән кызыксыну; милли символларга, изге урыннарга хөрмәт белән карау, җәмгыятькә һәм халкыңа хезмәт итәргә әзер булу хисләре тәрбияли. Рәвил Фәйзуллин шигырендә бу фикер  бик ачык чагыла:

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, күркәм затларыбыз, халкыбыз үткән олы тарихыбыз, гүзәл туган җиребез  белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә һәм лаеклы шәхесләр тәрбияләп үстерергә тиеш.

Туган якны өйрәнү музее - мәктәбебез горурлыгы. Күптән түгел ул Россия статусындагы  музейга әйләнде. Монда Бөек Ватан сугышы геройларына багышланган стендлар, аларның шәхси әйберләре, фоторәсемнәр, борынгы көнкүреш кирәк-яраклары, китаплар, шәһәребезнең үткәнен һәм киләчәген яктырткан экспонатлар тупланган.

Менә мин Геройларга багышланган экспозиция каршында басып торам. Яшь егетләрнең якты һәм сөйкемле йөзләреннән күзләремне ала алмыйм, үзебезне, балаларны алар белән чагыштырам. Минем күңелемдә горурлык хисләре уяна.

Бәйрәмнәрнең иң олысы, иң кадерлесе -  Җиңү бәйрәме. Күп корбаннар хакына, зур югалтулар бәрабәренә яуланган җиңү ул! Тарих бу кадәр булган афәтне башка хәтерләми. Рәсми мәгълүматларга караганда илебез бу сугышта 27 миллион  кешесен югалткан, 17000 шәһәр хәрабәгә әйләнгән,10 мең авыл җир белән тигезләнгән. Димәк, анда яшәүчеләрнең ачы язмышын күзалларга була.

Үткән гомер –аккан су, искән җил диләр. Ә менә Бөек Ватан сугышының данлы үткәне, аның үлемсез каһарманнары искән җил генә булып калмасмы? Һади Такташның “Киләчәккә хатлар “әсәрендә түбәндәге юллар бар:

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исемем сезгә җитмәс- онытылыр...

Әйе, “Исемем сезгә җитмәс- онытылыр,”-ди шагыйрь.Сезнеңчә,1418 көн,1418төн буена барган сугыш кайтавазы, җиңелүләр, җиңүләр, югалтулар, батырлар онытылырга тиешме? Киләчәк буыннарга бу көннәр, вакыйгалар турында җиткерә алырбызмы соң? Юк, онытмабыз, мәңге күңелләребездә сакларбыз!

Менә алар-мәктәбем стеналарына алтын хәрефләр белән язылган Советлар Союзы Геройлары: Белоусов Василий Игнат улы, Бурмистров Вилен Иван улы, Пискунов Василий Григорий улы, Суднишников Михаил Владимир улы, Софронов Петр Сергей улы, Фомин Михаил Сергей улы.

Софронов Петр Сергей улы... Сугыштан соң укытучы булып эшләгән героебыз турында укучыларым белән материаллар җыйдык. Ул 1925 нче елда туган.1943нче елның гыйнвар аенда сугышка китә.1944нче елның 15 нче гыйнварында Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Сугыш башланыр алдыннан әти-әнисе белән безнең шәһәргә күчеп килә, безнең мәктәпне тәмамлый. Армиягә киткәнче заводта эшли. Курск тирәсендә барган сугышта катнаша.

1943 нче елның 28 нче сентябре. Днепр ярларында бик көчле яңгыр ява башлый. Безнең разведчикларга шул гына кирәк тә инде. 9 кешелек десант составында безнең Петр да бар.Алар әкрен генә уң як ярга таба йөзеп китәләр. Днепр елгасының теге ягында, 2 сәгать эчендә, кечкенә генә группа 150 фашистны тоткарлап тора. Командир һәлак булгач, Софронов аның урынына баса һәм көрәш дәвам итә.Шушы батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое дигән исем бирәләр. Петр бу хәбәрне хәрби госпитальдә ишетә.Ул сугыш юллары буйлап Берлинга кадәр барып җитә.

1948 нче елда исән-сау туган ягына әйләнеп кайта. Алабуга педагогия училищесын тәмамлап, безнең мәктәптә укытучы булып эшли башлый. Минем уйлавымча, Петр Сергеевич дөньяга алты Советлар Союзы биргән мәктәптә эшләве белән горурлангандыр, мәктәп стеналары, сыйныф бүлмәләре аңа сугыш кырларында үлгән иптәшләрен хәтерләткәндер. Шуңа күрә ул бар көчен куеп эшли, укучыларны патриотик рухта тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирә. Музейны оештырып җибәрә. Фронтовик шагыйрь Шәрәф Мөдәрриснең шигъри юллары искә төшә.

Дусларымның барсын , йолдыз итеп,
Күкрәгемә тагып кайтуым...
Тик һаман да шушы Кызыл Йолдыз
Күкрәгемне тора пешереп,
Яшьли сүнеп, яуда ятып калган

Дусларымны искә төшереп...

Без аларны онытмыйбыз. Шәһәребезнең урамнары Герой исемнәрен йөртә, мәктәп стенасын алтын хәрефләр белән язылган мемориаль такта бизи, “Геройлар аллеясын”дагы мәрмәр сыннары безнең тынычлыгыбызны саклый, ерак та түгел мәңгелек ут яна. Гүя алар безне Ватанны сакларга чакыралар, киләчәккә имин барыр өчен, үткәннәне онытмаска кушалар.

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Исеңдә тот аларның син
Сугышларда кан түккәнен,
Туган җирнең иреге өчен
Зинданнарда интеккәнен...
Һәр карыш җир сугарылган
Шәһит җаннар каннарында.
Үткән яулар шәүләсе бар
Туган якның таңнарында.
(Р.Фәйзуллин)

Герой якташларыбызның тормыш юлын өйрәнү яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияүдә, Бөек Ватан сугышында җиңүнең тарихи әһәмиятен, асылын тирәнтен аңлауда, төрле милләт кешеләре арасындагы дуслыкның кадерен белергә өйрәтүдә, фронтта һәм тылда өлкән буын күрсәткән батырлыкларны күз алдына китерергә булышлык итүдә бүген дә зур әһәмияткә ия.

В 1954 году поступил на заочное отделение исторического факультета КГУ. Работал сначала зам. редактора, затем редактором районной газеты «Азьлане» Балтасинского района. Позже его направили директором Лельвижской средней школы, где проработал 25 лет до пенсии. Сейчас Иван Филиппович на заслуженном отдыхе. Он является председателем совета ветеранов в селе, частый гость в школе. Рассказывает детям о своем боевом пути, о незабываемом подвиге солдат, прививает молодежи военно-патриотический дух, уважение к людям старшего поколения.

Вместе с супругой Матрёной Егоровной воспитали пятерых детей. Все они получили образование. В этом году у Ивана Филипповича юбилей. Все мы его поздравляем с этой датой, желаем здоровья и долгих лет жизни.

Живите долго, Иван Филиппович, на радость нам и вашим детям!

**Волонтерский отряд «Радуга» МОУ СОШ с. Лельвиж.**





„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1980 ГОДА"

Знак учрежден Центральным Комитетом КПСС, Советом Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Букашев Иван Филиппович

от имени Министерства и ЦК профсоюза

награжден знаком

„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1980 ГОДА"

30 декабря 1980

(подпись) (подпись)







# УЧИТЕЛЯ-ФРОНТОВИКИ: ПОДВИГ, КОТОРЫЙ ЖИВЕТ В ПАМЯТИ ПОКОЛЕНИЙ. УЧИТЕЛЬ-ВЕЛИКОЕ ИМЯ!

*Багавиева Алсу Расимовна,*
*(педагог-библиотекарь*
*МБОУ «СОШ им.С.А.Ахтямова с.Манзарас)*

Великая Отечественная война 1941-1945 гг.- очень тяжелый период в истории России. Проходят годы, все события уходят безвозвратно.

Из 18 тыс. ушедших на фронт жителей Кукморского района ТАССР вернулись с войны 7 тыс. солдатов. Среди них были и учителя. Учителя-ветераны нашего Кукморского района: Алексеев Михаил Алексеевич, Ахметгалиев Зиннур Ахметгалиевич, Ахметов Кави Ахметович, Ахметшин Гаян Гарифович, Бикбов Фарид Галеевич, Вагапов Харис Вагапович, Гараев Габдулхак Гараевич, Галин Риза Ясавиевич, Гайнанов Заки Магсумович, Газизуллин Акрам, Федоров Степан Николаевич, Саляхов Зиннур Саляхович, Саляхов Баян Фаляхович, Пичугин Александр Васильевич, Минекаев Раиф Миневаевич, Зиганшин Каим Зиганшинович, Герасимов Александр Герасимович, Гайнетдинов Мидхат Абдуллович, Васильев Анатолий Романович, Валеев Анвар Абдрахманович, Бикбов Нагим Димухаметович, Хусаинов Магсум Галевич, Халиуллин Ахмат Халиуллович, Федорова Мария Григорьевна, Фатыхов Гариф Фатыхович, Сергеев Федор Сергеевич, Самигуллин Наумир Абдуллович, Саляхетдинова Хатира Саляхетдиновна, Саватеев Семен Александрович, Романов Зайнулла Гайфутдинович, Рахманов Васил Хабибуллович, Мустафина Закира Нуриахметовна, Назипов Билал Назипович, Мулюков Карим Мулюкович, Миннемуллин Нурулла Миннемулович, Лукьянов Николай Степанович, Мамаев Шариф Усманович, Куракин Николай Александрович, Ефимов Петр Трофимович, Егоров Семен Сидорович, Егоров Николай Егорович, Давыдова Тамара Дмитриевна. Эти люди были бойцами на войне, учителями в школе.

Подвиг-это когда в великом бескорыстном порыве души человек отдает себя людям, во время людей жертвует всем, даже собственной жизнью.

Мы, подрастающее юное поколение, должны знать и помнить о тех, кто ценой своей жизни, ценой своего здоровья совершил подвиг, победил фашистских захватчиков.

Маршал Советского Союза Александр Михайлович Василевский писал: «Учитель и на фронте, в окопах, оставался, верен своей профессии-личным примером учил, как надо воевать».

С первых дней войны многие тысячи учителей, надев серые солдатские шинели, с оружием в руках, плечом к плечу, отважно сражались за нашу Родину.

Я хочу рассказать о герое, который защищал малую Родину, об учителе-ветеране, жившего в нашем городе Кукмор (раньше поселок). Его имя-Минимуллин Нурулла Минимулович.

Почему выбрала именно его? Потому что он был учителем моих родителей. Он преподавал физику. Мои дорогие учились в Кукморской средней школе №1.

Родился он 10 августа 1920 года в Кукморском районе в селе Кошкино.

Минимуллин Н.М. на фронт призван в 1942 году, прошел обучение в городе Владимир. Время поступления на службу: 1939. Воинское звание: лейтинант. Воевал за освобождение города Курск в составе 60-ой армии. Командовал взводом автоматичков на 1-ом украинском фронте.

Был ранен. Всегда был на передовом фланге.

Награжден многочисленными медалями.

После войны долгие годы работал в Кукморской школе №1 военруком, учителем физики.

У учителей и учащихся школы об учителе остались добрые воспоминания. Предмет физики дается не каждому. Но Нурулла Миннемулович своим умением и талантом педагога умел заинтересовать учащихся. По воспоминаниям мамы, он на уроке приводил примеры из жизни, из своего опыта. Он никогда не повышал на учеников голос, был спокоен и имел отличное чувство юмора. Он был интересным собеседником по всем вопросам жизни.

Мы привыкли видеть учителей с указками на руках. И очень трудно представить, что учитель может сменить указку на автомат. В годы Великой Отечественной войны немало педагогов воевало на фронте. Учителя в боях показывали пример отваги, мужества, воинского мастерства.

Учителя- фронтовики, сражавшиеся в борьбе за освобождение родной земли от фашистов, стали гордостью школы. Поэтому наш долг-сохранить память о наших доблесных земляках.

# ФРОНТОВИК УКЫТУЧЫ – МӨНИПОВ ХАҖИП МӨНИП УЛЫ

*Зиганшина Лариса Наиловна,*
*Казан шәһәре муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең*
*“ М. И. Мәхмүтов исемендәге 184 нче гимназиясе”*

Кеше китә, кылган гамәлләре, эшләгән эшләре кала. Уйласаң, кеше гомере – уянып килүче табигатьне сизелер - сизелмәс кенә сыйпап үткән таң җиле кебек. Әйләнеп карарга да өлгермисең, сагыш - моңга сарып, утларда яндырып, уза да китә гомер дигән мизгел...

Кеше үз гомерендә ниләр генә кичерми дә, нинди генә авырлыклар, киртәләр аша үтми. Шуларны җиңеп чыгарга көч, фидакарьлек таба.

Үзеннән соң килгән буыннарга үрнәк булырлык шәхесләр күп безнең арада. Бу язмамда шуларның берсе – чын мәгънәсендә утны-суны кичкән, катлаулы авыр тормыш юлы үткән, озак еллар балаларга, шул исәптән минем әтиемә дә белем һәм тәрбия биргән сугыш һәм хезмәт ветераны укытучы Хаҗип ага Мөнипов белән таныштырып үтәсем килә.

Мамадыш районының Дусай дигән кечкенә генә матур бер авылында 1915 нче елда гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә ул. Ике баласын - бишектәге сабыен, ике яшьлек улын хатыны Шәрифелҗамалга калдырып, гаилә башлыгы Беренче бөтендөнья сугышына алына, шул китүдән әйләнеп кайтмый: һәлак була. Үз гомерендә бер генә тапкыр да әти дигән кадерле сүзне әйтә алмыйча, әнисе сөйләгәннәреннән генә хәтерендә саклап яши Хаҗип ага. Каз көтүе дә көтә, чабата ясарга да өйрәнә, ничек тә кул арасына керерегә, әнисенә булышырга тырыша ул. Балачак еллары ачлык-ялангачлыгы белән үзәкләренә үтеп исендә кала аның.

Авылларындагы башлангыч мәктәпне тәмамалагач, берничә сабакташы белән Мамадыш шәһәрендәге крестьян яшьләр мәктәбенә юл тота. 1931 нче елда бу мәктәп бөтен байлыгы, укучылары белән Кукмара районы Мәчкәрә авылына - урнәк тәҗрибә колхоз мәктәбенә күчә. Биредә укучыларга белем бирү белән беррәттән авыл хуҗалыгы эшләрен дә өйрәтәләр: җир эшкәртү, чәчү, урып-җыю эшләрен укучылар үзләре башкара. Ара ерак булгач, өйгә дә каникул вакытларында гына кайта ала, җәйге елларда авыл халкының сыер, сарык көтүен көтә, үз тамагын үзе туйдырырга тырыша Хаҗип ага. Яхшы укыганы өчен, мәктәпне тәмамлаганда, таныклык белән бергә бик зур бүләк: костюм – чалбар бирәләр. Үз гомерендә иң беренче тапкыр өстенә яңа кием кию бәхетенә ирешә егет.

Хаҗип аганың хезмәт юлы 1932 нче елдан - 17 яшеннән башлана. Кукмарада ике ай укытучылар әзерләү курсларында укыту методикасын өйрәнгәннән соң, аны Кукмара районы Түбән Өскебаш авылы башлангыч мәктәбенә укытучы, пионервожатый итеп җибәрәләр. Биредә өч ел укытканнан соң, күршедәге Кәркәүч җидееллык мәктәбенә күчерелә. Бер елдан соң күрше Бурсык – Елга авылында башлангыч мәктәп ачыла. Тәҗрибәсе юк дип тормыйлар, яшь һәм энергияле дип, аны мәктәп директоры итеп билгелиләр. Бар белемен, сәләтен туплап, баш-аягы белән эшкә чума ул. Кәркәүч авылының

чибәр кызы Миңсылу белән тормыш корып, балалар үстереп, бәхеткә тиенеп яшәргә хыялланалар.

Укытучы Хаҗип 1940 нчы елда Совет Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырыла. Бераздан Куйбышев шәһәрендәге политруклар әзерли торган училищега укырга алына. Ул арада озакка сузылуы, дәһшәтлелеге белән тарихка кереп калган Бөек Ватан сугышы башлана. Өч көн үтүгә, рота политругы дәрәҗәсендә Волхов фронтына хәрәкәттәге армиягә җибәрелә. Хаҗип ага коточкыч сугышларда катнаша, үз ротасы солдатларын сугышка алып керә, аларга үрнәк күрсәтә. Волхов фронтында барган каты сугышларда чыныгу ала.

1941 нче елның 29 нчы сентябрендә авыр яралана, контузия ала һәм Чиләбе шәһәрендәге госпитальләрнең берсендә дәвалана. 1942 нче елның гыйнвар ае башында туган авылына кайтып, гаиләсе белән күрешә. Ике көннән соң яңадан фронтка чыгып китә. 51 нче армиянең 824 нче полкы 398 нче дивизиясендә Кырым өчен барган авыр сугышларда катнаша, рота командиры була. Күрсәткән батырлыклары өчен “2 нче дәрәҗә Ватан сугышы” ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Каты сугышларның берсендә тубык сөяген 2 пуля тишеп керә һәм снаряд кыйпылчыгы тез башын вата, авыр яралана. Кара диңгез буена чыгарылып, Новороссийск шәһәренең госпиталендә бик озак ята. Гангрена башланып, аягын, үзеннән сорамыйч**а** кисәргә мәҗбүр булалар . Бу хәлне Хаҗип ага бик авыр кичерә: “Аягым юклыгын белгәч, беренче мәртәбә госпитальдә еладым”,- дип искә ала. Хәрби хезмәткә яраксыз дип, өенә кайтарып җибәрәләр. Киселгән аягы, юлда кайтканда бик каты сызлап, авыртып, яңадан госпитальгә эләгә. Наркозсыз – нисез аягын кабат тездән югарырак кисәләр. Бу хәл Махачкала шәһәреннән ерак түгел бер госпитальдә була. Хаҗип агага госпитальләрдә озак дәваланырга туры килә. Тблисси шәһәрендә, Ашхабадның 1273 нче номерлы эвакгоспиталендә дәвалана. Биредә аны тегүчелеккә өйрәтәләр, инвалидлар өчен оештырылган интернатта яшәп, тегүче булып эшләп калырга өндиләр. Тегүчелек эшен авылда да башкарырга була дип, Хаҗип ага гаиләсе янына Кукмара районы Кәркәүч авылына әйләнеп кайта. Юлда кайтканда аның башында төрле уйлар булгандыр: “Кабул итәрләрме? Тегү тегеп, гаиләмне туендыра алырмыммы? Аяксыз килеш ничек яшәрмен?” “Мин кайттым, Миңсылу, аяксыз килеш мине кабул итәсеңме?”- дип сорый ул беренче сүзе итеп. Бу хәл 1943 нче елның 4 нче апрелендә була. Үзең исән булгач, ничек тә яшәрбез әле дип шатланып каршы алалар аны хатыны һәм кызы.

Төшенкелеккә бирелеп, иркәләнеп озак ятарга туры килми аңа. Аяксыз килеш мәктәптә эшләп булмас дип уйлаган Хаҗип аганы бер айдан соң ук Кәркәүч җидееллык мәктәбенә тарих укытучысы итеп эшкә чакыралар. Култык таяклары белән йөрергә өйрәнеп, мәктәптә эшли башлый. Читтән торып Казан педагогика институтында укый, югары белемле тарих укытучысы була. 1943 нче едан алып 1977 елга кадәр балаларга тарих фәне укыта, патриотик тәрбия бирә, батырлык үрнәген үз мисалында күрсәтә. Завуч, директор вазифаларын да башкара ул. Сугыштан соңгы авыр елларда төшеп калмаска, ничек тә үз өлешен кертергә тырыша: партия оешмасы секретаре булып эшли, халык арасында

агитмасса эшләрен алып бара. Күпьеллык фидакарь хезмәте өчен хөкүмәтебез аны “Хезмәттәге казанышлары өчен” медале белән бүләкли.

Гаиләдә үрнәк эти, хатынын хөрмәтләп яшәүче яхшы ир буларак, авыл халкы арасында аның абруе зур була. Ике малай, биш кыз тәрбияләп, аларга урта һәм югары белем алырга мөкинчелек тудырып яши алар. Балалар үстергәндә дә күп авырлыклар күрергә, кыен шартларда яшәргә, эшләргә туры килә гаиләгә. Балаларының һәрберсе үз юлын табып, илгә – көнгә кирәкле булып, төрле өлкәләрдә уңышлы хезмәт итәләр. Кызларының икесе, әтиләренең юлын сайлап, укытучы һөнәрен үзләштерәләр. Венера апа Кукмараның 1 нче номерлы мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирә, озак еллар завуч вазифасын башкара. Икенче кызы Нүрия апа Кукмара районы Пычак мәктәбендә биология фәнен укыта. Икесе дә районның алдынгы укытучылары, хезмәт ветераннары, ихтирамга лаек затлар.

Хаҗип ага картлык көннәрендә малае һәм килене тәрбиясендә гомер итә. Оныкларын үстерешә, дәресләрен әзерләргә булыша, йортка күз-колак, йозак була. Көченнән килгәнчә, хуҗалык эшләрендә дә катнаша, кул кушырып утырмый. Күршеләре хәтта тәбәнәк урындыкка утырып, бәрәңге чүпләгәнен, чүп утаганын хәзер дә искә алып сөйлиләр. Үзе исән вакытта 19 оныгын, оныкчыкларын да кулына алып сөю бәхетенә ирешә.

2004 нче елның апрелендә легендар шәхес Хаҗип аганың йөрәге тибүдән туктый. Аны укучылар һәм укытучылар, җәмәгатьчелек зурлап соңгы юлга озата.

89 еллык гомер юлында аңарга күп мәртәбәләр үлем белән күзгә күз очрашырга туры килә. Бала вакытында, сугышта күп көннәр ач торулар... Пулемёт уты астында һөҗүмгә барулар... Авыр яралы хәлдә, санитарларны килгәнен көтеп, кан эчендә ятулар ... Боларның берсе дә аның көчле рухын сындыра алмаган: яшәүгә булган омтылыш, Туган илгә булган чиксез мәхәббәт аны көчле рухлы иткән.

Быел илебез Бөек Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итә. Илне коллыктан, халыкны изелүдән саклап калу, киләчәк буынны бәхетле тормышта яшәтү өчен, гомерләрен дә кызганмыйча, дәһшәтле ут эченә кергән миллионлаган сугышчылар безнең һәм бездән соңгы буыннарның хәтерендә мәңге сакланыр.

Соңгы вакытларда илдә барган вәзгыять уңай якка үзгәрсен, гонаһсыз сабыйлар ятимлектә үсмәсен, аналарның ачы күз яшьләре түгелмәсен иде. Илебез халкы шундый өмет белән яши бүгенге көндә.

# ФРОНТОВИК –УКЫТУЧЫ: ӨЧ ОРДЕН КАВАЛЕРЫ МУСА

*Гайнетдинова Айназ Фазыл кызы, Валиуллина Рәмзия Хәмзә кызы*
*Баулы шәһәренең 6 нчы урта мәктәбе укытучылары.*

Көрәшергә чыктык ил чакыргач,
Газиз башларниләр курмәде!
Нинди генә суны кичмәдек без
Нинди генә утка кермәдек!
Шушы бүгенге өчен без кан белән,
Яшьлегебез белән түләдек!
Разил Вәлиев

1941 нче елның июне. Басу-кырларда чәчү төгәлләнгән, табигать яшеллеккә күмелгән. Авылларда Сабан туйлары, чыгарылыш кичәләре гөрләгән, мәктәпне бетереп чыккан укучыларның матур хыялларга уралып, киләчәккә зур планнар корып йөргән көннәре. Ел буена шау-гөр килеп торган сыйныф бүлмәләре тынып калган. Укытучылар да , балалар да көтеп алган каникуллар... Җәйнең җылы, рәхәт көннәре. Шушы тыныч тормыш агышын җимереп, 1941 нче елның 22 нче июнендә немец-фашист илбасарлары илебезгә һөҗүм итә. Бөек Ватан сугышы башлана. Бу хәбәр яшен тизлеге белән илебезнен иң ерак почмакларына да барып ирешә. Ишеткән һәр кешенең йөрәге тетри, күңелен шом баса.



“Сугыш башланган” дигән коточкыч бу хәбәрне Муса Миңлебай улы Миңнеголов поездда, Саратов якларындагы туганнарыннан кайтып килгәндә ишетә. Әле кичә генә имтиханнарын уңышлы биргән укучылар өчен куанып, аларга һөнәр алу өчен уку йортлары сайлашып, яңа уку елы башланганчы эшлисе эшләрен уйлап, планнар корып йөргән яшь укытучы бер мизгел эчендә ныклы карарга килә. Фронтка китәргә! Аның гаиләсе тарихында куркаклар да, хәйләкәрләр дә булмаган: гражданнар сугышында да, фин сугышында да катнашкан туганнары бар. Бу турыда авылдашлары да яхшы белә. Ул вакытта әле Татар Димескәе Баулы районына караган, сугышка китүчеләргә повестскалар да Баулы хәрби комиссариатыннан җибәрелә торган булган. Муса Миңлебай улы да шунда гариза илтә. Сугыш башлангач, укытучыларның эше тагын да арта: аларга халык арасында аңлату эшләре алып бару, митинглар уздыру, сугыш хәбәрләре белән халыкны таныштыру кебек бурычлар да йөкләнә. Үзенә повестка килгәнче Муса шул эштә актив катнаша, тирә-яктагы авылларга да йөреп, политукулар, митинглар уздыра.

Тиздән Мусага да сугышка китәргә чират җитә. Яшь коммунист запас полкка килгәч, 1941 нче елның октябренда политруклар хәзерләү курсларында укырга тәкъдим ала. Татарлардан тугыз кеше Курск өлкәсендәге политработниклар мәктәбенә җибәрелә. Анда озак укырга мөмкинлек булмый - фронт якынлаша. Укуларын яңа гына башлаган кешеләрне Татарстанның Минзәлә шәһәрендә вакытлыча оештырылган Хәрби-политик училищега күчерәләр. Муса Миңнеголов бу курсларда Муса Җәлил белән бергә укыган һәм , 1941 нче елның 31 нче декабрендә укуны төгәлләп, полтрук званиесы алган. Ләкин бергә укыган иптәшләргә бергә китү насыйп булмый. Аларны төрле частьларга тараталар. 1942нче елның гыйнварында Муса Миңнегол улы Калининград фронтына җибәрелә, пулемет ротасында политрук булып хезмәт итә башлый. Авыр бәрелешләрдә катнаша. Великие Луки өчен барган сугышта каты яралана, хәрби госпитальгә эләгә. Дәваланып чыккач, 1943нче елда танкистлыкка укый. Авыр танкның өлкән механик-йөртүчесе булып сугышка керә. Генерал Катуков командалык иткән Беренче танк армиясе составында Украинадан башлап, Польша, Германия җирләрендә сугыша, “Берлин” операциясендә катнаша. Наводчигы Габдрахман Садыков белән бергә фашистларның “Тигр” , “Фердинанд” дигән куәтле танкларын, ут нокталарын күп мәртәбәләр юк итәләр.

Шундый атакаларның берсе турында танкистның үзе сөйләгән сүзләре Дания Рәүпованың “Ватан солдаты” дигән хикәясендә урын алган: “...безнең авыр танклар полкы “Берлин” операциясен башлауга әзер. Атака өчен соңгы позицияләрдә торабыз. 15-20 метр саен ара калдырып куелган пушкалар, агач–куаклар арасына яшерелгән танклар, самоходкаларны күреп күңелләр рәхәтләнә. Менә кайда ул фашизмның оясын тар-мар итәчәк көч! Артиллерия әзерлеге башлана. Тоташ гүелдәү. Бер-берең белән колакка якын килеп, кычкырып кына сөйләшеп була. Һавада безнең штурмовиклар оча, алар туп-туры дошман позицияләренә юнәләләр. ...Менә куәтле “катюша”лар соңгы залпларын биргәч, атакага өндәп, һавага кызыл ракеталар чөелә. Танклар, самоходкалар гүелдәп алга омтылалар. Дошман аяусыз каршылык күрсәтә. Коерыгына баскан елан кебек бөтерелә. Сугыш кыры шартлаган снарядлардан, ике якның да дөрләп янган танкларыннан таралган әче төтен, күккә күтәрелгән тузан өермәсе белән каплана. Әмма безнең гаскәрләр бер адым да артка чигенмиләр, батырларча сугышалар. Фашистларның ...танклардан һәм пушкалардан торган ут нокталары бер-бер артлы юкка чыгарыла”.

“...Берлиннан ерак түгел бер участокта ...ике үзйөрешле орудие совет сугышчыларының алга барышын тоткарлый, безнең берничә танкны яндыра. Муса Миңнеголов экипажына һәм тагын ике танкка шуларны юк итәргә приказ бирелә. Алар, оста маневр ясап, дошман көтмәгән яктан һөҗүм итәләр. Һәм аларны көчле утка тоталар. Озак та үтми, “Фердинанд”ларны ялкын телләре чолгап ала. Шулай итеп, безнең гаскәрләргә алга барырга юл ачыла...”

Сугышның һәр көне зур югалтулар, канлы бәрелешләр, ут-ялкын, җимерелү һәм җиңүгә өмет белән уза. Җиңү көненең якын булуы сугышчыларда дәрт уята. Берлинны алгач сугыш бетәчәгенә ышану аларга көч өсти. 1945 нче елның

апрель азагында танк полкы Берлин территориясенә бәреп керә. Урам сугышлары башлана. Һәр йорт, һәр бина өчен каты бәрелешләрдә бик күп совет сугышчылары һәлак була. Шул сугышларның берсендә Муса Миңнеголов та каты яралана. Аны Польшага, госпитальга озаталар. Җиңү көнен ул госпитальда каршылый. Бу вакытка ул инде гвардия өлкән лейтенанты званиесында була.

Командование һәм хөкүмәтебез Муса Миңлебай улы Миңнеголовның сугышта күрсәткән батырлыкларына зур бәя бирә. Ул Кызыл Йолдыз ордены, ике тапкыр икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

1945 нче елның Җиңү көне илебезгә генә түгел, ә Европа илләренә дә азатлык алып килә. Күп сугышчылар өйләренә кайтып, гаиләләре белән очрашу шатлыгын кичерә. Ә бик күпләр хәрби хезмәтен дәвам итә. Чөнки Ерак Көнчыгышта сугыш һаман туктамый, Япония белән солых төзелми. Шулай ук сугыш китергән җимерекләрдән дә арынасы, төзисе, юллар, күперләр, завод-фабрикалар ремонтлыйсы бар. Яшь сугышчыларның эшкә яраклы исән-саулары шундый эшләргә җәлеп ителә. Муса Миңлебай улына да хәрби хезмәтен озайтырга туры килә. Ул бары тик 1947 нче елның февралендә генә туган ягына әйләнеп кайтуга ирешә.

Татар Димескәй авылы аны иң гаярь, көчле ир-атларын югалткан, ятим балаларга, хатын-кызларга тормыш йөген тартып бару йөкләнгән, атлары фронка алынган ярым буш ат сарайлары, икмәге фротка алынган буш амбарлары, ябыгып беткән халкы белән каршы ала. Муса Миңнеголов яңадан үз эшенә кайта, мәктәптә балалар укыта башлый. Сугыш чоры балаларын укытуның бөтен авырлыгын үз җилкәсендә күтәрә. Ятим балалар белән эшләү, уку әсбаплары җитмәү, азык-төлек, кием-салым кытлыгы, укытучылар җитмәү кебек проблемалар сугыштан соңгы елларда бик озак дәвам итә.



Муса Миңнеголовның оештыру сәләте зур икәнне район җитәкчеләре дә күрә. Колхозны аякка бастыру өчен бар көчен куясына ышанып, аны Тукай исемендәге колхоз председателе итеп билгелиләр. Колхозны алга җибәрү өчен, кешеләрнең тормышы җайга салынсын өчен Муса Миңлебай улы белемен дә, сәләтен дә кызганмый. Бер үк вакытта партоешма секретары вазифасын да үти. Үзен оста оештыручы, тәвәккәл, кыю җитәкче итеп күрсәтә.

Гаиләсендә дә ул үзен үрнәк эти, уңган-булган ир, җаваплы, кайгыртучан хуҗа итеп күрсәтә. Тормыш иптәше белән бергәләп ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Уллары да этиләре кебек җитәкче постларда эшлиләр. Кызлары

Рәйсә дә әтисе һөнәрен сайлый. Ул да укытучы булып, Баулы шәһәренең 3 нче мәктәбендә балаларга инглиз телен укыта.

Бу гаиләне Ташкичү авылы халкы хөрмәт итә. Лаеклы ялга чыккач та Муса Миңлебай улы йортыннан кеше өзелми. Кемгәдер киңәш, кайсынадыр сафтан чыккан көнкүреш техникасын төзәтергә кирәк. Муса агай беркемне дә кире бормый, барсына да кулыннан килгәнчә булыша, тәҗрибәсе белән дә уртаклаша. Буш вакытларында Муса Миңлебай улы гармунда уйнап, сугышчан дусларын искә ала, фронтта күргәннәрен гаиләсенә, якыннарына сөйли. Гомеренең сонгы көннәренә кадәр авылдашларының хөрмәтен казанып яши ул. Хәзерге көннәрдә дә Муса аганы сагынып искә алалар һәм аның белән горурланалар.

Бөек Җиңүгә үз өлешен керткән өч орден кавалеры Муса Миңлебай улы Миңнеголовның якты истәлеге үзе укыткан укучылар күңелендә дә, авылдашлары хәтерендә дә сакланыр, Татарстанның дан китабында да исеме лаеклы урын табыр.

# ФРОНТОВИК, УЧИТЕЛЬ, НАСТАВНИК

*Тухфатуллова Рания Ильдаровна*
*(научный руководитель: Каримова А.Ф.),*
*ГАПОУ «Буинский ветеринарный техникум»*

В годы Великой Отечественной войны немало педагогов воевало на фронте. Учителя в боях показывали пример отваги, мужества, воинского мастерства, находчивости и смекалки. Вряд ли найдется такой участок фронта, такое сражение, среди активных участников которого не было бы педагогов. Гордостью дивизий, полков, батальонов и рот были на фронтах многие учителя.

Мы подрастающее поколение, должны знать и помнить о тех, кто ценой своей жизни, ценой своего здоровья совершил подвиг, победил фашистских захватчиков. В своей исследовательской работе хочу рассказать о своем прадеде – педагоге, ветеране Великой Отечественной войны - Бабужине Абдулле Юнусовиче.

Абдулла Юнусович, родился 15 сентября 1915 году в селе Елховое озеро Симбирской губернии, в семье рабочих, где воспитывались 8 детей. После окончания школы, в 1934 году, он поступает в Ульяновский педагогический техникум. С тех пор и начинается его педагогическая деятельность. В 1935-1939 годах, он работает учителем в Старостуденецкой семилетней школе Буинского района. В 1939 году, он призывается в ряды вооружённых сил, где служит в самой южной точке Советского Союза, в городе Кушка, в Туркмении. В 1940-1941 годах, в городе Чарджоу, учится в военном училище. В связи с началом Великой отечественной войны, прадед досрочно оканчивает учёбу в училище, и 25 июля 1941 года он назначается командиром 30 взвода и роты легендарной Панфиловской дивизии. В 1942 году он получает тяжёлое ранение. Получив лечение в госпитале, он возвращается на фронт и назначается начальником артиллерии 1-го батальона 30-го полка 8-й Гвардейской дивизии. Прадедушка служил на Западном, Северо-Западном, 2-м Прибалтийском, Ленинградском фронтах. Был 5 раз ранен, дважды контужен. Но вера в победу, вера в жизнь не покидала его.

Абдулла Юнусович награжден Орденом Красной звезды, Орденами Великой отечественной войны 1 и 2 степени, медалями "За отвагу". Великую Победу 1945 года, он встретил в Чехии. После окончания войны, талантливого командира отправляют в Прибалтику на подавление незаконных банд формирования. Мобилизовался он в 1948 году. В 1950 году прадедушка поступает в Андижанский педагогический институт, на географический факультет. После окончания института, долгие года работает директором "Нижненаратбашской" средней школы Буинского района. В то же время преподает уроки химии и биологии.

Абдулла Юнусович активно участвовал в общественной жизни района и села. Будучи на заслуженном отдыхе прадед избирается членом "Совета ветеранов" города Буинска. Его неиссякаемая энергия, неугомонность довела его до 97 лет жизни. Жизнь его остановилась в День Защитника Отечества - 23 февраля 2012 года.

Я очень горжусь своим прадедом. Несмотря на все тягости жизни, он прожил длинную жизнь и воспитал 4 прекрасных дочерей.

Глубочайшее уважение народа к учителям, совершившие славные подвиги в сражениях Великой Отечественной войны и после ее победоносного завершения вернувшиеся к педагогическому труду.

Чтить память о героях Отечественной войны — это наш долг. Эти люди проявили невероятную храбрость и самопожертвование, защищая свою родину и обеспечивая нам светлое будущее.

# УЧИТЕЛЯ В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ: ФРОНТ И ТЫЛ

## АВЫР ЕЛЛАР СЫНДЫРМАГАН СЕЗНЕ

*Галимова Динә Ингелевна,*
*(Җитәкчеләр: Г.И.Хәйруллина, Р.Р.Шакирҗанова),*
*Балтач урта гомуми белем мәктәбе*

Сугыш чыгарылыш сыйныф укучыларының хыялларын җимерде, аларның күбесе укуларын дәвам итү урынына чыгарылыш кичәсеннән соң фронтка яки тыл хезмәтенә китәргә мәҗбүр булды. Ләкин сугыш совет белем бирү системасы үсешенә зур этәргеч бирде. Ил җитәкчелеге, мәктәпләрдәге укуларны өзеп, аларны ябарга ярамаганны аңлый иде. Киресенчә, мәктәпләр саны артты. Педагогика сутыш чорына яраклашкан иде.

Укучылар һәм укытучылар, көчләреннән килгәнчә, илгә ярдәм күрсәттеләр - саклану корылмалары төзеделәр, кырда һәм госпитальләрдә эшләделәр, әмма укыту процессы бу авыр елларда да өзелмәде. Барлык балаларны мәктәпкә тарту эше мәктәпнең төп бурычы булып тора. Җимерелгән мәктәпләр урынына башка биналар яраклаштырыла. Патриотлык хисе тәрбияләүгә зур әһәмият бирелә. Табигый фәннәрне укытуга практик юнәлеш бирелә. Укучыларга практик эшчәнлек алу мөмкинлеге өчен мәктәпләрдә укыту-җитештерү остаханәләре булдырыла. Хезмәт тәрбиясе тәртип һәм белем сыйфатына уңай йогынты ясаган.

Шул ук вакытта, белемнең сыйфатын күтәрү максатыннан, эксперименталь эшчәнлек тә алып барылган. Ләкин барысы да уңай нәтиҗәләр бирмәгән. Укыту эшчәнлегендәге ярышлар һәм аерым укыту (кызлар аерым) кертелү укыту-тәрбия эшенең сыйфатын киметкән.

Балаларның туклануы белән сәламәтлегенә бик зур игътибар курсәтелә. Әти-әнисез калган балалар интернатларга урнаштырылган яки яңа гаиләләргә тәрбиягә алынганнар.

Бу елларда мөһим яңалыклар кертелә. Шуларның күбесен без хәзер дә кулланабыз: биш баллы бәяләү системасы; мәҗбүри жидееллык укыту; җиде яшьтән гомуми белем бирү; башлангыч һәм жидееллык мәктәптә мәҗбүри чыгарылыш сынаулары; 10 еллык урта мәктәптә өлгергәнлек аттестаты алу өчен имтиханнар биру; уку алдынгыларына алтын һәм көмеш медальләр тапшыру.

### Балтач урта мәктәбе тарихыннан

1939 нчы елда мәгариф эшендә киеренке чор башлана, чөнки байтак укытучы ир-егетләрне армия сафына алалар. Нәтижәдә, Балтач районында укытучылар саны 40 кешегә кими. Балтач мәктәбеннән Фазыл Мөхәммәтов, Әнвәр Капкаев, Сәет Әхмәтовлар шинель кия.

Тәҗрибәле укытучыларга кытлык булган заманда кемнәрне куярга? Мәгариф бүлегенең 1939 нчы елның 15 нче августында чыккан 59 нчы номерлы приказы нигезендә, Балтач һәм Янгул урта мәктәбен бетергән иң сәләтле

укучылардан кадрлар туплана башлый. Балтач урта мәктәбенең 1940 нчы елгы беренче чыгарылыш укучылары Готыф Әхмәтов, Мәдинә Вәлиева, Әхәт Гыйльмуллин, Галия Сөләйманова, Бибинур Юнысова, Мәсхүт Мөхетдинов, Асия Галиева, Гайшә Исмәгыйлева, Тайфә Шакирова, Әминә Кадыйрова, Фатыйма Моратова, Әминә Фәхертдинова мәктәпләргә башлангыч белем бирергә җибәреләләр. Мәктәпнең икенче чыгарылышыннан Суфия Зыятдинова, Фатыйх Шакиров, Әминә Рамазанова, Хәят Кильдиева, Наил Зарипов, Шәгъвәнә Мәгъсумова, Хәдичә Сәгъдиевалар да укытучылар итеп билгеләнәләр. Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты юлламасы белән Балтач мәктәбенә Мөхәммәди Гарифуллин кайта. Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты курсларын бетереп, Камал Сафина татар теле укыта башлый.

Сугыш авырлыклары Балтач урта мәктәбе тормышына да үтен керә. Бер-бер артлы директорлар алышына. Миңнуллин Госманны Рафиков Мәгъсүм, аны Кирасиров Кашаф (1942 нче елда), Кирасировны 1943 нче елда Труднев Иван алыштыра. Ул сугышка озатылгач, вакытлыча директор вазифалары физкультура укытучысы Дмитриев Анатолийга йөкләтелгән. Сугышның соңгы чорында, 1944-1945 нче уку елында директор булып Газизов Каюм (Нормабаш авылы кешесе), ә завуч булып Кильдеев Мөхәммәтҗан эшләгән. Аны 1945 нче елның августында Закиров Габделхак алыштырган.

Балтач җирлеге зур сандагы эвакуацияләнгән гаиләләрне кабул иткән, үз канаты астына алган, көченнән килгән кадәр яшәү өчен шартлар тудырган. 1941 нче елның 26 сентябрендә 6 гаилә - 13 кеше кайтканы билгеле. 1944 нче елның 1 мартына булган мәгълүматлар буенча Балтачта 16 гаилә сыеныр урын һәм эш тапкан.

Балтач урта мәктәбендә эвакуация белән килгән балалар өчен рус класслары ачылган, эвакуацияләнгәннәрнең үз араларыннан укытучылар билгеләнгән. Циля Говерман, Вера Stručkova, Алексей Дмитриенко укытучылар булын эшләгәннәр. Шулай ук ленинградлы Лидия Владимировна Хмылко, Нина Трофимова, Польшадан килгән Бронислава Абрамовна Жехте, ригалы Михай Вольне һәм Мәскәү шәһәреннән туган авылы Балтачка кайткан Мәхфүзә Кутуева, шулай ук Мәхсудова Әмина (сугыш елларында эвакуация белән кайткан язучы Мәхмүт Мәсхудовның хатыны) турында яхшы истәлекләр саклана.

## Сугыш чоры укытучылары

Укытучының эчке дөньясын, психологиясен үтәли күрә белгән язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев - үзе дә укытучы. Ул ир-ат укытучыларны нык торган имән агачы белән тасвирлый.

Әйе, фронтовик укытучылар да, агачлар күк, газаплы сугыш давылын уздырып сынмадылар, үлемне җиңделәр, илгә җиңү яуладылар, туган якларына кайттылар. Сугыштан соң да озак еллар дәвамында җирнең иңнәренә керләнмәгән ак шәл ябучылар, ак юл - белем юлын сузучылар булдылар.

Бөек Ватан сугышында районыбыздан барлыгы 400 мәгариф хезмәткәре катнашкан. Шулар арасында 149 кеше, жиңү яулап, укытучылык эшенә кире кайта; 40 кеше офицер дәрәҗәсенә күтәрелә; 27 хатын-кыз ир-атлар белән беррәттән дошманга каршы сугышкан.

Районның мәгариф хезмәткәрләре арасыннан 250гә якыны һәлак булды, хәбәрсез югалды яисә билгесезлектә калды *(күрсәтелгән саннар районның мәгариф бүлеге архивы, хәрби комиссариат мәгълүматларына таянып һәм шул чорда эшләгән укытучыларның истәлекләрен искә алып бирелә).*

Балтач мәктәбеннән Бөек Ватан сугышына алынганнарның уналтысы яу кырларында ятып калган. Менә аларнын исемнәре: Габдулла Фәезов, Гаптрахман Сәйфуллин, Кашаф Кирасиров, Ибнеәмин Фатыйхов, Мөнир Садыйков, Сәгъди Хәмитов, Мәснәви Мусин, Әнвәр Капкаев, Мирсәет Шигапов, Габделхәй Зарипов, Мөхәммәтгали Ризванов, Сөлейман Бикбаев, Фомин Яков, Мөнир Садыйков.

Сугышка кадәрге Балтач урта мәктәбенең татар теле укытучысы Гомәр ага Садыйков улының үлгән хәбәрен алганнан соң (үзе дә шул вакытта фронтта), кайгы-сагыштан уйланып, улы Мөнир белән «сөйләшә», кичерешлерен шигъри юлларга сала, улы белән хушлаша. Аның «Улыма истәлек» шигыре туа. Бу шигырь хат булып туган ягына Балтачка, кызлары Наилә белән Ленага килеп ирешә һәм саклана. Шигырьне Балтач урта мәктәбендә озак еллар рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән Асия Рәхимҗанова язып алган.

**Укытучылар хатирәләреннән**

...Сугыш дәвам итә. Үлүче кешеләр турында кайгылы хәбәрләр килеп тора. Кайгының иге-чиге юк. Гаиләләре белән елыйлар, эшкә барасылары килми. Без – укытучылар, иртән иртүк торып, мәктәпкә барганчы, бригадир белән өй саен кереп, кешеләрне эшкә билгелибез. Аннан соң укытырга киләбез. Дәресләр беткәч, балалар белән урманнан утын ташыйбыз. Аннары агитаторлык. Дәрескә әзерләнү өчен төнге йокы сәгатьләре китә. Әле дәфтәрләр җитми. Башлангыч сыйныфлар өчен газетаның буш урыннарына төне буе сызыклар сызабыз. Шуларга укучыларны язарга өйрәтәбез...

...Без, укытучылар, ул елларны барыбыз да яшьләр. Яшьлек үзенекен итә. Тормыш никадәр авыр булса да, дәртебез ташып тора. Йөгерәбез, барысына да өлгерәбез. Мәктәптә дә укытабыз, урак урабыз, җир үлчибез, бүләбез, кибән дә куябыз, башак та җыябыз, кышын утын ташыйбыз. Авыл буйлап җылы кием җыябыз.

*Кушымта*

## Сугыш чоры укытучылары



**Фәхертдинова Әминә**
Сугыш алды һәм сугыш елларында укыткан татар теле укытучысы



**Сәгъдиева Хәдичә**
Сугыш чорында Балтач урта мәктәбендә математика укытучысы



**Сәмигуллина Фатыйма**
Сугыш чорында Балтач урта мәктәбендә татар теле укытучысы



**Зиләева Зәбирә Сәлахетдин кызы**
Сугыш чорында Балтач урта мәктәбендә немец теле укытучысы



**Кутуева Мәгъфүзә**
Сугыш чорында Балтач урта мәктәбендә татар теле укытучысы



**Шаһиева Банат Фәтхулла кызы**
Сугыш чорында Балтач урта мәктәбендә рус теле укытучысы



**Килдиев Мөхәммәтҗан**
1944-1945 нче елларда Балтач урта мәктәбендә завуч



**Газизов Каюм**
1944-1945 нче елларда Балтач урта мәктәбендә директор






# АҢ-БЕЛЕМГӘ ОМТЫЛГАН МӨГАЛЛИМЕБЕЗ

*Абдуллина Эльмира Илфаковна, Кадирова Зухра Абдрахмановна,*
*МБОУ “Нурминская СОШ” Балтасинского муниципального района РТ*

Авыл кешеләрендә балаларына аң-белем бирү омтылышы элек-электән килә. Кайсы чорга гына күз салсак та, наданлыкны бетерү өстендә эшләүче мөгаллимнәр бихисап булган һәм алар тарихта тирән эз калдырганнар. Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә 2025нче ел Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде. Бөек Җиңүне якынайтучы шәхесләребезнең берсе - ул Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы.

Кем соң ул Габделхәй Сөләйман улы? Нигә без аның тормыш юлына тукталырга булдык? Әлбәттә, мондый сораулар бик күп, ә боларга җавапны без тарихи эзләнүләр аша таба алдык.



Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы 1905нче елның 12нче февралендә Кариле авылында крестьян гаиләсендә туа. 1914нче елда Кариле мәктәбенә укырга керә һәм биш сыйныф программасы буенча белем ала. Аннан авыл хуҗалыгында эшли. 1926нчы елда Казандагы хәрби җыенга алына. 1927нче елдан 1931нче елга кадәр наданлыкны бетерүдә катнаша, белеме аз булганнарны укыта. Шушы елларда ул мәгаллим буларак беренче адымнарын ясый башлый. 1930нчы елдан колхоз әгъзасы булып тора.

1931нче елның 1нче ноябреннән Кариле мәктәбендә мөдир вазыйфасын башкара һәм балаларга белем бирә. Шул ук вакытта үзенең белемен күтәрү өстендә дә эш алып бара. 1932нче елда Апазда 10 көнлек курста була. 1933нче елның кышкы каникулында Карадуганда белемен күтәрә. 1934нче елның җәендә, Балтачта ай ярым курста булып, алтынчы класс программасы күләмендә белемгә ия була. 1936нчы елның җәйге курсында җиде сыйныф программасын үзләштерә.

1930-1940нчы елларда ил тарихи вакыйгаларга (күмәкләштерү, мәдәни революция һ.б.) бай була. Гади авыл халкын илдәге сәяси вакыйгалар белән таныштырып, әйдәп баруның төп йөге дә укытучылар җилкәсенә төшкән. Габделхәй Сөләйман улы бу эшләрдә дә актив катнаша. 1931-1936нчы елларда профсоюз члены булып тора, “Кызыл юл” колхозында ревком булып эшли.



Кариле мәчете бинасында урнашкан мәктәп

Эзләнү барышында без 1937нче елда район мәгариф бүлеге мөдире Шәрәфиев тарафыннан язылган характеристика да таптык. Анда мондый юллар бар: “Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы биш ел укыта. Тәрбия эшләрен

планлы алып бара. Балаларның дициплиналары яхшы, өлгерешләре буенча уртача. Укытучының педагогик эш белән кызыксынуы җитәрлек, авторитеты бар”. Димәк, монда инде без мәгаллимнең югары дәрәҗәдә эшләвен күрә алабыз.


Характеристика.
Бу бирелә Балтач районы Кариле башлангыч мәктәп мөдире ип. Сулайманов Габд. Сулайманов Кариле башлангыч мәктәбендә мөдир булып эшли. Үзенең эшен һәм укыту тәрбия эшләрен яхшы үти, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.
Ип. Сулаймановны мәктәп мөдире булып эшләргә Роно лаеклы дип таба.
Роно мөдире:
20.II.40г.

1940нчы елның 20нче февралендә язылган характеристикада без Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улының директор вазыйфасын бөтен таләпләргә туры китереп башкаруына тагын бер тапкыр инандык. “Үзенең эшен һәм тәрбия эшләрен яхшы үти, җәмәгать эшләрендә актив катнаша” дигән мактау сүзләре язылган.

Тарихка күз салсак, 1939-1940нчы елларда мәктәпләрдә кириллица кертә башлыйлар. Ә Габделхәй абый моңа әзерлекне 1938нче елның җәендә курсларда узган була, шуңа күрә укыту эшен тиешле дәрәҗәдә алып бара.

1941нче елның 22 июнендә таң алдыннан, сугыш игълан итмичә генә, һөҗүм итмәү турындагы килешүне явызларча өзеп, немец-фашист илбасарлары совет җиренә бәреп керә. Сугыш еллары һәркемнең күңелендә авыр истәлекләр, һичбер вакыт онытылмый торган тирән хәсрәтләр калдыра. Сугышның беренче елында әле мәктәп беркадәр яңа уку елына әзерләнгән була, утынның да шактый өлеше инде ташып куелган, шуңа күрә мәктәпкә яга алмыйча укуларның өзелү очраклары булмый, ләкин гаилә хәле авыраю белән мәктәпкә балаларның йөрүе начарая. Ничек кенә булмасын, шундый авыр шартларда да балаларны укыту, белем бирү туктамаган.

Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы 1942нче елның 25нче мартына кадәр Кариле башлангыч мәктәбендә эшли. Дәресләр бетүгә, укытучыларны чиксез эшләр көтә: колхозчылар арасында агитатор, стена газетасы чыгару, бригадир белән колхозчыларны эшкә дәшеп йөрү. Шулай ук хайваннарга азык әзләү, фермада дежур тору, ял көннәрендә өмәләр оештыру, кышын кар тоту, тирес түгү, көл җыйнау, ашлык ташу, чистарту кебек эшләрдән дә азат булмый укытучы.

Мәктәп музеенда без Бөек Ватан сугышы елларында тылда хезмәт куючыларның истәлекләренә тап булдык: “Фермада хайваннарга азык җитешми, ачлыктан егылып үләләр, шуларны күреп йөрәк әрни иде”. Шулай ук Кариле башлангыч мәктәбендә укыткан хезмәттәше Гарипова  Мәэмүнә апа сугыш елларын менә болай дип  искә төшерә: “Балалар ач, начар киемле, боек, анең өстенә әтиләре, туганнары фронтта булган балаларга йөрәк өзгеч күңелсез хәбәрләр килеп тора”. Балалар дәрестән соң кыр эшләренә чыгалар: яшелчә утырту, чүп утау, башак җыю, бәрәңге һәм яшелчә алу.

1942нче елның 25нче мартында Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы фронтка китә. Ульяновскида тимер юл салу эшендә катнаша. Әлбәттә, безнең фикеребезчә, бу фронт өчен бик кирәкле хезмәт була, чөнки сугышчыларыбызга ярдәм итү тимер  юл аша башкарыла. 1943нче елны аңа Кавказга китәргә туры килә. Анда Армавир, Тихорецк исемле шәһәрләрдә ватык тимер юлларны төзәтеп йөри. 1944нче елда Себергә Омск шәһәренә китә. Анда яңа тимер юллар

салу белән шөгыльләнә. Шушы шәһәрдә водокачка һәм депо эшләүдә катнаша. Укытучы буларак, аны хезмәттәшләре арасыннан агитатор итеп сайлыйлар. Шушы еллардагы уңышлары өчен берничә мәртәбә командование тарафыннан бүләкләнә. Сугыш елларында Габделхәй абый бер эштән дә курыкмый, кайда гына җибәрсәләр дә, Ватан алдында намус белән үз бурычын башкара. Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улы “Германияне җиңгән өчен”, “1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорындагы батыр хезмәтләре өчен” һ.б. медальләр иясе.

1945нче елның 27нче июнендә хәрби хезмәттән демобилизацияләнеп кайта һәм укытучы булып эшләвен дәвам итә. Ул 1945-1953нче елларда Кариле мәктәбендә укыта, мөдир дә булып тора. 1947 елда партия сафларына баса.



1951нче елда Норма авылында җидееллык мәктәп ачыла, Кариле мәктәбе Норма мәктәбенә кушыла. Берничә ел дәвамында кайбер сыйныфлар Кариле мәктәбе торагында укыйлар. Норма балалары да шунда йөреп укый, ә укытучылар ике мәктәптә дә укыта. 1953нче елның 15 сентябреннән 1954нче елның 28 июленә кадәр Норма сельпосында склад мөдире булып тора.

1945-1955нче елда, армиядә хезмәт иткән еллар педагогик стажга кермәү сәбәпле, ул тагын укытуга күчә. Норма җидееллык мәктәбенә вакытлыча укытучы итеп билгеләнә.

1983 нче елның 14нче февралендә вафат була. Аның исеме “Җиңүчеләр” китабында мәңгелеккә язылган. Шулай ук мәктәп музеенда, авыл китапханәсендә, “Кариле” китабында һ.б. чыганакларда Габделхәй Сөләйман улы турында якыннанрак танышып була.

Сөләйманов Габделхәй Сөләйман улының педагогик эшчәнлеген дәвам итүчеләр бүгенге көндә дә бар. Белгәнебезчә, аның улы һәм кызы үз тормышларын укытучы һөнәре белән бәйләгәннәр. Әле алай гына да түгел, оныклары һәм аларның тормыш иптәшләре дә бабаларының юлын дәвам итәләр.

Әлеге эзләнү эше безгә Бөек Җиңү мирасын саклауның мөһимлеген тагын да яхшырак аңларга ярдәм итте. Аң-белемгә омтылган мөгаллимебезнең тормышы киләчәк буын өчен Ватанга тугърылыклы хезмәт итү үрнәге булып тора. Хәзерге һәм киләчәк буын ветераннарыбызның сугыш елларында нинди авырлыклар аша үткәннәрен белеп яшәргә тиеш. Бүген яшьләрне ватанпарвәрлек үрнәгендә тәрбияләү җәмгыятьнең төп бурычы булып тора, чөнки илебезнең иминлеге һәм үсеше шуңа бәйле. Ә без, укытучылар, аны тормышка ашыручылар булып торабыз.

# БУГУЛЬМИНСКИЕ УЧИТЕЛЯ В ТЫЛУ И НА ПЕРЕДОВОЙ

*Власов Матвей Олегович*
*(научный руководитель: Жакупова М. Г.),*
*ГАПОУ «Бугульминский машиностроительный техникум»*

Героическое прошлое нашей страны вызывает горячий отклик в сердцах молодых. Наш долг – сохранить память о каждом защитнике Родины и гордость за них. Актуальность исследовательской работы заключается в потребности углубления знаний обучающихся о подвиге солдата на войне, особенно, если этот солдат – учитель. Трудно переоценить роль учителя в жизни человека. Именно учитель открывает бескрайний мир знаний, учит премудростям жизни. Дарит веру в себя и веру в людей. В истории нашего города есть прекрасные страницы, когда преподавателями географии, истории, физики, начального образования и музыки были участники Великой Отечественной войны. Свою работу мы решили посвятить им.

Цель работы- изучить биографии учителей г. Бугульмы и Бугульминского района – участников Великой Отечественной войны.

Задачи:

- посетить городские музеи, проанализировать архивы местных газет с целью поиска информации об учителях-участниках Великой Отечественной войны;
- систематизировать и обобщить материалы об учителях-фронтовиках;
- создать Книгу памяти учителей г. Бугульмы – участников Великой Отечественной войны;
- провести Уроки мужества в техникуме и школах города.

Методы: анализ документов и изучение Наградных документов, интервью с родственниками учителей-фронтовиков, посещение музеев (краеведческого и музея МБОУ СОШ №8).

В результате исследовательской работы нам удалось найти информацию о 17 учителях-фронтовиках, среди них есть и истории работников системы профессионального образования. Позвольте рассказать о некоторых из них.

**Вера Васильевна Пеструхина** родилась в крестьянской семье в 1902 году в деревне Макаровка Мензелинского уезда Уфимской губернии (ныне Нижнекамского района РТ). В 1918 году окончила Мензелинскую гимназию. С 1918 по 1920 годы работала учителем начальных классов в родной деревне. С 1920 по 1938 годы продолжала педагогическую деятельность в разных районах Татарии.

В ноябре 1941 года назначена заведующей Акташским районным отделом народного образования. В сентябре 1951 года переведена на работу в Бугульминскую среднюю школу № 2 учителем русского языка и литературы. Неоднократно избиралась депутатом в сельские, районный и городской Советы.

Награждена орденами Ленина, Трудового Красного Знамени, медалями "За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.", "Ветеран труда", юбилейной медалью к 100-летию со дня рождения В.И. Ленина, медалью

"30 лет со дня Победы в Великой Отечественной войне", знаком "Отличник народного просвещения". В 1981 году ей присвоено звание "Почетный гражданин города Бугульмы".



**Кудряшов Василий Алексеевич** - учитель начальных классов и технологии.

В годы Великой Отечественной войны - капитан, старший адъютант первого стрелкового батальона Стрелковой Витебской дивизии. Воевал с декабря 1942 года. Призван Бугульминским РВК ТАССР 21.11.1941г..

Награждён орденом «Красная Звезда» (10.10.1943), орденом Великой Отечественной войны 2-ой степени (26.07.1944), орденом Великой Отечественной войны 1-ой степени (07.02.1945). Проявил себя в наступательных боях в Восточной Пруссии. Умело руководил подразделениями батальона, бесперебойно обеспечивал радиотелефонной связью командиров боевых подразделений. Обеспечил бесперебойный подвоз боеприпасов, питания для личного состава. В феврале 1945 в бою в районе города Лансберг, в трудные минуты боя, своим личным примером храбрости и отваги дважды поднимал бойцов в атаку. В числе первых прорвался в траншеи противника. Из своего пистолета уничтожил фашиста. Обеспечил успех операции.



**Кудряшов Герасим Павлович** (1910-1979) родился 14 марта 1910 года в деревне Кирсановка Северного района Оренбургской области, в семье крестьянина. Окончил Бугульминское педагогическое училище, работал учителем. Однако война прервала его мирный труд. В октябре 1941 года он был мобилизован и через несколько недель оказался на передовой. Стал командиром орудия артиллерийского дивизиона в составе 23-й гвардейской мотострелковой бригады 7-ого гвардейского танкового корпуса. Воевал на Первом Украинском фронте. Боевое крещение получил в 1941 году в районе Малых Вереек. Участвовал в боях под Сталинградом. Был контужен. В наградном листе от 23 января 1945 года отмечено, что он в составе штурмовой группы участвовал в форсировании реки Одер вблизи населённого пункта Грашовец, что в пяти километрах южнее города Ополе, в Польше. Из своего орудия Герасим Павлович Кудряшов уничтожил огневые точки противника, и этим способствовал успешной переправе стрелковых подразделений через реку Одер. Особо отличился он при отражении вражеских атак. В боях под Дрезденом был тяжело ранен.

За боевые подвиги ему было присвоено звание Героя Советского Союза. Это произошло 10 апреля 1945 года.

После войны Герасим Павлович вернулся в родное село, работал заведующим начальной школой, затем переехал в город Бугульму. Среди его наград ордена Ленина, Золотая Звезда Героя, орден Красной звезды и медали.

Умер 15 июля 1979 года. Память его увековечена в бюсте в аллее Героев. В его честь названа одна из улиц города. В 2005 году на ней установлена стела.

**Мамыкин Лифантий Антонович** (1923 – 2016), родился 31 декабря 1923 года в деревне Балахоновка Клявлинского района Самарской губернии. Родители – крестьяне-середняки. В 1927 году переехали в село Залесское. Оттуда ходил учиться за 15 км в Михайловку, где успешно закончил 7 классов. В 1941 году окончил Бугульминское педагогическое училище. Дальше судьбу диктовала война. Вольск. Военно-авиационная школа авиационных механиков, 6 месяцев стажировки и с 1 мая 1943 до окончания войны - 63-ий гвардейский истребительный авиационный полк в составе действующей армии. С 4 июля начались боевые действия, каждый день самолеты, которые он обслуживал, совершали по 5-6 вылетов. До конца войны он работал механиком, служил в полку, где воевал легендарный летчик Мересьев. У Лифантия Антоновича 12 медалей и Орден Отечественной войны второй степени.



Участвовал в Орловско - Курской операции, в операции «Багратион» по освобождению Белоруссии, в боях по освобождению Прибалтики, в боях по взятию Берлина.

С марта 1946 по май 1949 работал учителем в школах советских войск в Германии. Вернулся в Бугульму, работал в школе №2. Заочно окончил Казанский педагогический институт. В августе 1955 года назначен директором семилетней школы №8. В 1962 году Мамыкин Л.А, переведён директором в школу № 12. В восьмилетней школе №1 он работал заведующим по учебно-воспитательной работе и преподавал историю.

Всю свою жизнь Лифантий Антонович посвятил делу обучения и воспитания детей. Был строгим и требовательным руководителем, находил и сплачивал вокруг себя одарённых, талантливых учителей. Обеспечивал образовательное пространство для наилучшего обучения и воспитания школьников.

Умер Лифантий Антонович в марте 2016 года в возрасте 92 лет. У Лифантия Антоновича 12 медалей и Орден Отечественной войны второй степени.

**Логинов Михаил Логинович** (1909 – 1989). Место рождения - село Поповка. Мобилизован в 1943 году Бугульминским РВК. Командир стрелкового взвода, командир пулемётной роты, три года сражался на переднем крае. Ходил в разведку в тыл врага. Был ранен в ногу 16.10.1944г. Войну закончил в Латвии 8 мая 1944 года. Кавалер ордена Красной Звезды.

Преподаватель физики. Заслуженный учитель ТАССР. Работал в школе №8 г.Бугульмы с её основания (1954) до последних дней жизни (1988). Был Почётным пионером дружины им. Николая Островского.

По его инициативе в школе создан музей Николая Барышева (1975), именем героя-подпольщика названа одна из улиц подстанции, а 30 мая 1987 года торжественно открыт памятник, завершивший создание Мемориала Славы школы №8,- дань памяти всем участникам Великой Отечественной войны.



Михаил Логинович был человеком очень скромным. Сердце своё отдал детям. Всё своё свободное время он, не жалея, дарил детям: водил в походы, организовал туристический лагерь «Дружные ребята» на месте лагеря первых пионеров Бугульмы. Проводил замечательную настоящую «Зарницу».

